ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 7 (342)
ИЮЛЬ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

«БҮГЕНГЕ КӨН РИТМЫН ТОЯРГА ОМТЫЛАМ»

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

АЯК АСТЫНДАГЫ ЙОЛДЫЗЛАР

Казанның таш түшәлгән җәяүлеләр урамындагы бер урын бу юлы редакция кереш сүзе өчен тема булып куйды. Кайчандыр безнең Йолдызлар аллеясенә әйләндерелгән урын.

Анда, исегездә булса, танылган җырчылар – Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Мөнирә Булатова хөрмәтенә бакыр йолдызлар куелган... Нәкъ Голливудтагы кебек, тик болары – Казанда. Аяк астындагы йолдызлар да Американыкы түгел – үзебезнеке, күңелгә якыннар...

Бәлки, шуңа күрәдер Казанның зыялы халкы йолдызларга басмаска тырыша. Йөрәккә якын исемнәрне таптап йөрүне кабул итеп бетерә алмыйбыз без, нишлисең инде... Әллә демократия градусы АКШтагы дәрәҗәгә җитмәгәнме, әллә, киресенчә, күпкә артыбрак киткәнме шунда...

Шаяруларны читкә куеп торсак исә, безнең карашка, мәсьәлә күпкә гадирәк. Голливуд идеясен сукырларча «күчереп кую» аны тормышыбызның гадәти, көндәлек бер өлешенә әйләндерә алмады. Безгә бөек якташларыбызга карата хөрмәтле мөнәсәбәт геннар дәрәҗәсендә сеңгән. Шуңа күрә бу исемнәрне таптап йөрү, аларны хөрмәт итү булуы белән күңел һич тә килешә алмый. Безнең кичерешләребезне яраткан джинсылары урынына шотланд итәге кияргә мәҗбүр ителгән ковбойныкына тиңләргә мөмкин...

Әле шунысы да бар: кемнеңдер әсәрен файдаланып иҗат ителгән нәрсә һәрвакыт оригиналдан начаррак килеп чыга. Шулай икән, бәлки, сукырларча күчереп куюдан баш тарту урынлырактыр? Һәм чит илнеке кебек Йолдызлар аллеясе урынына үзебезнең Дан аллеясен ясаргадыр? Асфальтка батырылган йолдызлар рәвешендә түгел, ә, әйтик, истәлекле мәрмәр барельефлар белән.

Голливудның Йолдызлар аллеясендә таптанып торырга теләгәннәр әнә океан аръягына юл тота ала. Ә хөрмәт итә белгән тамашачы Татарстанга рәхим итсен! Сүз уңаеннан, үзебездә уйлап табылган кабатланмас нәрсәләр чит җилләр китергәнгә караганда күпкә артыграк та.

Һичнигә битараф калмаган редакциягез!

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Алёна Кутыркина,
Мөршидә Кыямова, Луиза Шарова
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Татарстанның халык артисты
Илдар Хәйруллин. Лилиана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-1648
Басарга кул куелды: 10.07.2020
Басмадан чыкты: 16.07.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА

WWW.PROTATARSTAN.RU

ДӨНЬЯДА БЕРЕНЧЕ ВИДЕОМАГНИТОФОН

Дөньяда беренче видеомагнитофонны уйлап табучы. «Оскар» һәм Emmy Awardsның башка күплэгэн бүләкләре иясе. Стенфорд университеты музеендагы даими экспозициясе герое … Бу легендар шәхес – безнең якташыбыз. Александр Понятов – Казаннан ерак түгел генә урнашкан Рус Әйшәсе авылында туып-үскән. Бөтен дөньяда билгеле һәм үз ягында бөтенләй билгеле түгел диярлек… Мөгаен, сәяси (ул вакытта совет) стройны кабул итмәү аркасындадыр. Бу аңлашыла да, чөнки аның талантларының берсе эшкуарлык була бит. АКШка эмиграциягә китеп, электроинженер Понятов үз фирмасына нигез сала – Ampex компаниясен оештырып җибәрә.

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Җиңү бәйрәме
Борис Кузнецовның 75 нче Җиңү парады

10. Үзизоляция дәресләре
Пандемия безне нәрсәләргә өйрәтте

12. Чит илләрдәге милләттәшләребез пандемия турында
Таякның ике башы…

игелекле эшләр

22. «Татарстан» мөхәррирләре
100 елдан соңгы очрашу

28. Кече Ватан патриотлары
Лотфулла Фәттахов иҗаты

34. Тормыш линиясе
Бездә кунакта – Илдар Хәйруллин

мәңгелек кыйммәтләр

40. Халкыбыз батырлыгы елъязмасы
Бөек Ватан сугышы музее

44. Веры Фигнердан алып Кукрыниксларга кадәр
Тәтеш өяз тарихы музее

48. Шагыйрь йөрәге
Петр Хузангай музее

52. Шәхси тарихлар,
яки Мәңгелек мәхәббәт сагышы

56. Тарих сәхифәләре
Мөхәммәтҗан Хөсәенов – беренче мөфти

70. Юкка чыга баручы авыллар
Кем – кая, без – Кузайкинога

82. Татар авыллары
Каракитә: Җирдәме, Марстамы?

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР



25.06

Владимир Путин, Россия Президенты, – ТАССР төзелүнең 100 еллыгы уңаеннан татарстанлыларга котлавында:

– Бүген Татарстан Республикасы хаклы рәвештә иң алдынгы төбәкләрнең берсе булып санала. Монда зур инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудырылган, сәнәгатьтә һәм авыл хуҗалыгында, энергетика һәм төзелеш комплексларында, социаль өлкәдә масштаблы инициативалар уңышлы тормышка ашырыла. Татарстанлыларның үз Ватанын ихлас яратуы, ата-бабаларының гореф-гадәтләрен, йолаларын ихтирам итүе, Бөек Ватан сугышы ветераннарының батырлыгына карата хөрмәт саклавы, бәйрәмдә дә, эштә дә, кайгыда да, шатлыкта да бергә була белүе, ярдәмгә һәм кайгыртуга мохтаҗ кешеләргә ярдәм итәргә омтылуы куандыра.

12.06

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Россия көне уңаеннан татарстанлыларга мөрәҗәгатендә:

– Быел без Татарстан АССР төзелүгә 100 ел тулуны бәйрәм итәбез, илебез тарихында аның гаять зур урын алып торуын билгеләп, республикабыз үсешенең шанлы сәхифәләрен хәтеребездә яңартабыз. Татарстанлыларның тырыш хезмәте, федераль үзәкнең һәм лидерыбыз Владимир Владимирович Путинның ярдәме казанышларыбызның нигезен тәшкил итә. Хәзерге Татарстан – икътисад өлкәсендә зур уңышларга ирешкән алдынгы төбәк, ул гражданнарның яшәү шартларын яхшырту, куәтле Россия төзү юнәлешендә алга атлый.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

25.06

Марат Хөснуллин, Россия Федерациясе вице-премьеры, – ТАССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты утырышында:

– Без Казанның һәм республикадагы башка шәһәрләрнең ничек үзгәрүен, яңаруын, заманча бина-корылмалар белән тарихи-мәдәни мирас объектларының үзара матур ярашуын күрәбез. ТАССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек чаралары да әлеге төбәкнең үсешенә үз өлешен кертте. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бу чаралар республика тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла, федераль бюджет акчалары җәлеп ителми диярлек.

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

акыллы гамәләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

75 нче Җиңү бәйрәме **ничек** үтте

Үзизоляция **нәрсәләргә** өйрәтте

Якташларыбыз чит илләрдә **ничек** яши

БУЫННАРНЫ БЕРЛӘШТЕРГӘН ҖИҢҮ МАРШЫ

2020 елның 24 июне, Казан. Ирек мәйданында чорларны иңләгән музыка – «Славянканың хушлашуы» яңгырый. Шушы маршны тыңлап, 700 мең татарстанлы фронтка киткән һәм аларның һәр икенчесе яу кырларында ятып калкан. Тормышларын аямыйча Ватан өчен көрәшкән каһарманнарның варислары бүген, Бөек Җиңүдән соң 75 ел узгач, шушы көйгә марш атлый. Илебез өчен, якыннарыбыз өчен, тынычлык өчен, киләчәк өчен, сезнең белән безнең өчен!

Фото: сайт Президента РТ (Марсель Бадыкшин)

Суворовчылар бәйрәм-парадка киелә торган ак кительләрдә марш атлый. Легендар Т-34 җитәкләгән танк колоннасы узып бара. 1941 елгы кебек хәрби форма кигән солдатлар үтеп китә... Хәрби сафта – бу Җиңүне безнең өчен яулаганнарның оныклары, онытларының балалары.



Легендар шәхес – Советлар Союзы Герое, 1945 елгы Җиңү парадында катнашкан Борис Кириллович Кузнецов, парадны күзәтеп, бармак очларын тантаналы рәвештә фуражкасына тидерә: так держать!

75
ПОБЕДА!

Аннан, бераз гына аксаклап, олы көзге алдына артсыз урындык китереп куйды да:

– Әйдә, кызым, чәчемне кисеп буя әле. Тик «фасонын» үзгәртмә, калдыр, миңа шулай ошый, – диде.

Куркып кына кулларыма кайчы алам:

– Мин бит чәч кисә белмим...

– Өйрәнерсең. Котлыйм, хәзер син – минем чәчтараш. Һәм әле табиб та, шәфкать туташы да.

Әбекәйгә каршы әйтмиләр...

Хәзер минем иртәләрем каһвә эчүдән түгел, ә тонометр кабартудан башлана. Кан басымы тотрыклы әнинең – 120 гә 84.

30 март

– Кызым, тыңла әле, телевизордан дүрт стена арасында акылдан шашмас өчен нишләргә дигән киңәшләр тыңладым: телефон яки видеоэлемтә аша якыннарыгыз белән аралашыгыз. Көн саен фотолар җибәрүләрен сорагыз, көннәрен ничек үткәрүләре, оныкларның ни белән шөгыльләнүе турында сөйләсеннәр... Дусларыгыз белән рецептлар, кызыклы күнегүләр, идеяләр алмашыгыз. Бергәләп фильмнар, китаплар турында сөйләшегез. Көнлек план төзегез... Күп итеп печенье пешерегез... Сәяхәтләрдән, балачактан күңелле хатирәләрне исегезгә төшерегез, рәхәтлек бирә торган вакыйгаларны хәтерләп, алар турында языгыз...

Менә шул, оныклар белән дә, туганнар белән дә телефоннан көн саен сөйләшеп торам, рецептлар бүлешер кешем юк – дус кызларым мәрхүм булдылар инде, ә печеньены төштән соң синең белән бергәләп пешерербез. Син менә миңа хатирәләремне язып бир әле, үзем начар күрәм.

Ул көнне без печеньены күп итеп пешердек – атна буена җитте. Ашап бетердек үзе. Чәй эчәргә утырган саен: «Тәмле бит?» – дигән булабыз. Диеталарга төкерсәк тә, тешләрне вата-вата ашасак та, килешкән булабыз.

Әбекәйгә каршы әйтмиләр...

БЕРЕНЧЕ ХАТИРӘ

– Кызым, ә син беләсеңме, Советлар Союзында кемнәр кулларын башкаларга караганда ешрак та, озаграк та юа иде? Әстерханлылар һәм кырымлылар. 70 нче елның җәендә котырынган ваба эпидемиясеннән соң, алар кулларын сабынлап, ашар алдыннан гына түгел, сәгать саен юып тора иде. Куркыныч бит – косып һәм эч китеп үләсе килми. Ул вакытта мин синең белән йөкле идем, ә әтиең эш белән Әстерханга китте. Хәтерем ялгышмаса, шәһәрне июль ахырында карантинга яптылар да берәүне дә чыгармадылар. Кыскасы, аңа кадәр ике көн кала әтиең кача-поса сукмаклар табып, көч-хәл белән аннан китә алган. Карантин зонасы мең чакрымнан да күбрәк булган, дия иде. Исән, сау-сәламәт кайтты. Шуннан бирле өйдә хлор исен яратмады. Ә мин аны тыңлап тормый идем – өйне җыештырырга кирәк бит. Күптән түгел ул чор турында кино төшергәннәр, диләр, исемен әйтә алмыйм. Әйдә, карыйк әле.

ӘНИЕМДӘ ҮТКӘН ӨЧ КӨН

Автор: Алсу Троицкая

Үзизоляция башлангач әнинең (без аны гаиләбездә әбекәй дип йөртәбез) әйткән иң беренче сүзе: «Тормыш дәвам итә! Ярый әле үз өебез белән яшибез, фатирда түгел, ишегалдына һава суларга чыгып йөри алабыз», – булды.

Фото: Алсу Троицкая

Кичебез күңелле үтә. Ирем белән Валерий Тодоровскийның «Одесса»сын өченче тапкыр карыйбыз: «Ирина Розанова бигрәк оста актриса инде, хәтта шушындый кыяфәтсез һәм шадра булганда да», – дигән сокланулы шәрехләүләр белән, әлбәттә.

Әбекәйгә каршы әйтмиләр...

6 апрель

– Йоклыйлар да йоклыйлар. Сәгать 7 бит инде. Кызым, кичтән үк сөйләшеп куйдык бит, иртә белән син минем «шикәр»не үлчисең дип, – дигән сукранулы тавыш ишетеп, күзләрне тырнап ачарга туры килә.

Глюкометрның бәләкәй экранына чыккан 5.6 саны минем өчен котылу чарасы – әбекәебезнең кәефе шунда ук күтәрелеп китә, хәтта төнлә явып киткән кар да боза алмый. Киресенчә әле.

ИКЕНЧЕ ХАТИРӘ

– Яратам да инде карны. Без бәләкәй чакта ул шундый күп ява иде, сезнең түшегезгә дә керми аның кадәр кар. Без таудан берьюлы җиде-ун кеше бәләкәй чанада түгел, ә ат чанасында шуып төшә идек! Авыл балалары өчен кыш – иң күңелле вакыт. Бигрәк тә Салкын Аландагы балалар йорты малайлары безнең мәктәпкә урман аша үтә торган сукмакны бүлеп куйганда. Мәктәпкә барырга дип чыгасың, ә сукмагыңа кар тавы өелгән. Урап та үтеп булмый, сикереп тә чыгарлык түгел. Нишлисең – борыласың да кайтып китәсең. Портфельләрне әти-әнисе соңга кадәр эшли торган берәрсенә ташлап калдырасың да тау шуарга китәсең. Бервакытны ике көн рәттән мәктәпкә шулай «бардык» без. Билгеле, инде, әнигә әйтеп тору юк... Бу хәлләр авылга класс җитәкчесе Хәмит абый Шәйхетдинов килгәч кенә беленде. Каты эләкте миңа. Ул вакытта иркәләп тормыйлар иде бит: берәр кырын эшең белендеме – эләгәсен көт тә тор.

Әнигә каршы әйтмиләр...

Мәктәп дигәннән. Балалар йортында тәрбияләнүчеләр дә безнең белән бер сыйныфта укый иде. Әй, кызыга идек без аларга! Алар матур киенә – яңа пальто, яңа каталардан, башлыклары да цигейка гына. Ә без нәрсә бар, шуннан йөрибез мәктәпкә – чабатадан, малайларның чалбарлары кыска, олы абыйларыннан калган була иде, кызларның күлмәкләре капчык кебек. Аларны әйбәт ашаталар. Мәктәпкә киләләр дә алма яки кишер белән кызыктыралар. Кемдер «карамыйча гына алмашабыз» дигән уен уйлап тапты. Шулай итеп, безнең кесәләрдә коры печенье яки хуш исле күмәч барлыкка килде, аларныкында – пешкән йомырка, авыл ипие яки пешкән бәрәңге. Соңгысын ятимнәр аеруча ярата иде – аларга андый «деликатес»лар эләкми иде.

Сугыштан соңгы хәерчелеккә карамастан, әни миңа яңа пальто сатып алды. Апрель аенда базарга ит алып барып сатып, шәһәрдән яңа кием алып кайтты. Мин аны икенче көнне үк кидем – ул көнне директор мине Сарманга комсомолга керергә алып

“

– Сугышны җиңдек, вабасын да, бу афәтне дә кичәрбез әле. Киләсе елга Пасхага йомырканы күп итеп буярбыз әле. Балаларга конфетны да өч килограммнан да ким алмассың. Тормыш дәвам итә!

барды. Эссе иде! Мин исә пальтомның төймәләрен генә ычкындырдым – җылы сөяк сындырмый...

19 апрель

– Менә. Әйттем бит, Пасхада кояш та башкача елмая дип. Берәү дә капканы ачып куймаганмыни? Балалар ничек керер соң? Әй, онытканмын лабаса, үзизоляция бит әле.

Борынын салындырып, әбекәй үзенә чәй ясап ала да өстәл янына барып утыра.

ӨЧЕНЧЕ ХАТИРӘ

– Мин бит катнаш авылда үстем. Баткак исемле. Хәзер ташландык авылга әйләнеп бара инде, без бәләкәй чакта анда тормыш кайный иде. Авылның яртысында – татарлар, икенче яртысында керәшеннәр яши. Мөселман бәйрәмнәрен дә, православларныкын да бергә үткәрәбез Июньдә – Сабантуй, июльдә – Питрау. 1945 елның Пасхасын бүгенгәчә хәтерлим әле. Алдагы көнне 5 майда әни миңа капчыктан букча текте. Шуны җилкә аша асып, иртәнге 4 тә урамга чыктым. Ә анда – урам тулы бала-чага. Барыбыз да яланаяк. Иртә белән җир салкынча әле, йөгерәбез генә. Берәр калкулыкка кадәр йөгерәбез дә аякларны җылытабыз һәм тагын чабабыз. Әй саен керәбез, татарлар дип тә, керәшеннәр дип тә тормыйбыз. Һәр өйдә тәмле әйбер көтә. Хуҗаларның да кәефе әйбәт. Соңыннан гына белдем ни өчен икәнен: Җиңү көненә таба булганга икән.

Әниемнең күзләреннән яшьләр ага, әмма ул аларны җәһәт кенә сөртеп ала да:

– Юк, юк, кызым. Сугышны җиңдек, вабасын да, бу афәтне дә кичәрбез әле. Киләсе елга Пасхага йомырканы күп итеп буярбыз әле. Балаларга конфетны да өч килограммнан да ким алмассың. Тормыш дәвам итә!

Әбекәйгә каршы әйтмиләр...

КӨН АРТЫ КӨН

Автор: Ольга Туманская

Безгә коронавирус «бүләк иткән» чикләүләрнең бер өлешен бетерү бер йотым саф һавага тиң булды. Тиздән барысы да җәйләнер һәм элеккеге – мәҗбүри киелергә тиешле битлекләрсез, тыюларсыз, карантинсыз тормышка әйләнеп кайтырбыз дигән өметне җылытып җибәрде. Икенче яктан, безнең һәркайсыбызга кагылган үзизоляция бәһаләп бетергесез тәҗрибә бирде.

МӘКТӘПКӘ ЙОКЫ КОСТЮМЫННАН ЙӨРМӘГЕЗ

«Онлайн-дәресләрдә кайбер әти-әниләр салмыш хәлдә эчке киемнән генә йөри дип зарлана укытучылар» – мәктәп турындагы мемнарның берсе бу. Әлбәттә, бу шаяруда дөреслек бар... Кыскасы, беренче апрельдә тормыш безнең белән әнә шулай итеп шаяртты. Тиз генә сальто ясап куйды: башта безнең фатирны – офис, аннан соң мәктәп итте.

Кызым беренче тапкыр интернет-класска кергәндә, анда үзенә бер җанлану хөкем сөрә иде. Ниһаять, (онлайн-сервиска рәхмәт!) балалар соңгы вакыйгалар аркасында күбрәк өйдә сак астында торуны хәтерләткән каникуллардан соң күрешеп, сөйләшә ала. Мәктәп ыгы-зыгысы безнең фатирга кереп тулды. Күршеләрнекенә дә бугай. Балаларның очрашу шатлыгын берәү дә тыеп булмый – тәртип таләп иткән укытучы да, качып кына монитор янына утырган ата-аналар да...

Менә шундый күңелле генә итеп, дулкын күтәрелеп килгәндә, безнең өскә техник туфан ишелеп төште – мәктәпнең гадәттән тыш зур йөкләнешкә күнекмәгән интернет-системасы өзелде дә куйды. Балалар онлайнда гына вотсап аша борчылдылар... Хәер, әти-әниләр дә бугай... Барыбызны да Мәгариф министрлыгы башлыгы Сергей Кравцов үзе тынычландырырга ашыкты, янәсе, ил дистанцияле укуукытуга әзер түгел иде. Дөресен генә әйткәндә, класс җитәкчесенең чатка язган кыска хәбәрләре аның нотыгына караганда, безгә көчлерәк тәэсир итте. Яшь кенә булса да, безнең укытучы әлеге техник хаос вакытында героик тынычлык саклады. Бәхеткә, тагын ике көннән соң, коллапс юкка чыкты, конференцэлемтәдән файдаланырга хәтта «элеккеге мәктәп» укытучылары да өйрәнде, һәм дәресләр челтәре, ниһаять тәртипкә керде.

Ә балалар бу вакытта аларга гына хас саклык чараларын кулланып, рөхсәт ителә торган әйберләрнең чикләрен капшауларын дәвам итте. Әгәр баштарак безнең кыз иртәнге сигезгә бөтен тәртибен туры китереп, монитор каршына килеп утыра торган булса, атна ахырына ул йокы аралаш бутербродын чәйни-чәйни ноутбук артына чумәшә башлады. Аның җилкәсе аша качып кына караган арада нәкъ шундый ук тузгыган сыйныфташларын күреп калдым. Тышкы кыяфәт чираттагы сыйныф сәгатенең темасы да булды хәтта, балаларга директорның катгый таләбе җиткерелде: караваттан мәктәпкә кадәр ара ярты гына метр булса да, йокы киеменнән уку тыела!

Сүз уңаеннан, урта мәктәпкә кадәр генә түгел иде ул ярты метр, ә музыка мәктәбенә дә, сәнгатьнекенә дә, биюнекенә дә, безнең кыз очрагында – спорт мәктәбенә кадәр дә! Әйе-әйе, бөтен укыту барышы онлайн-режимга күчте. Җиңел атлетика буенча тренер көн саен тренировкалар планын җибәрә, аны башкару – мәҗбүри. Әлеге өйгә эшләр нәтиҗәсендә, без ирем белән үзебезнең сүзлек запасын да баеттык (әйтик, без «бурпи»ның ниндирәк «хайван» икәнен белми идек әле), физик формабызны да ныгыттык. Балаларның ялкаулыкка хирыслыгын шәхси үрнәк аша гына җиңеп була, диләр бит!

– Кара әле, пресска күнегү – 400 тапкыр... Бәлки, монда бер ноль артыктыр? – Кызыбызга иптәшкә күнекмәләр ясарга алынган ирем шундый өмет белдерә.

Фото: Ольга Туманская



“

– Хикмәт шунда: минә берничә көн инде укытучылар көтелмәгән проблема белән көрәшә – балалар челтәрдәге дәресләргә берничек тә үз исемнәре белән керергә теләмиләр икән. Җор теллелектә ярышка чыкканнар, диярсең, алар үзләренә берсен-нән-берсе көлкелерәк никнеймнар уйлап чыгара.

– Нea! – дип, йөзенә җиңү шатлыгы чыгарып җавап бирә кызыбыз, җиңел генә икегә бөкләнеп.

Ни әйтсәң дә, безнең өчен бер ноле чыннан да артык иде... Ә иртәнгә эчебез спорт белән шөгыльләнүдән генә түгел, ә көлә-көлә дә авырта башлады. Хикмәт шунда: минә берничә көн инде укытучылар көтелмәгән проблема белән көрәшә – балалар челтәрдәге дәресләргә берничек тә үз исемнәре белән керергә теләмиләр икән. Җор теллелектә ярышка чыкканнар, диярсең, алар үзләренә берсеннән-берсе көлкелерәк никнеймнар уйлап чыгара.

– Тәк, иптәш Месье Колбасье, рәхим итеп, үзегез белән таныштырып үтегез! – дип таләп итә география укытучысы. Ә кырыс математика укытучысы шукларны бөтенләй «класстан» куып чыгару белән яный.

Дәрес саен арта барып, әлеге кайнап торган күңелле энергия техник яктан өстенлек белән дә кушылып (менә кайда балалар җиңел генә итеп үзләренең укытучыларын узып киттеләр!)физкультура дәресендә үзенең иң биек ноктасына җитте. Укытучы сикерүнең куркынычсызлыгы техникасы турында тәэсирле итеп сөйләгәндә, экранда аның башы урынына бөтенләй дә спортка катнашы булмаган кеше ясап куйганнар. Визуаль экзерсислар моның белән генә бетмәде әле. Миңа калса, үзенең аватарын танылган сәясәтче фонына куйган кыз баланыкы иң уңышлысы иде. «Ул бездә нишләп йөри?!» – дигән сораулар яуды мәктәп чатына. Җавап эчтәлекле иде: «Укый. Акыл туплый». Дөреслек балалар теле белән сөйли дигәнгә ничәнче кат инануым инде...

ЙӨЗ МЕТРЛЫК ИРЕК

Мин чиратта 52 нче. Коронавирус буенча «кайнар элемтә» белгеченә шалтыратмакчы булам. Ихтимал, минем аңа бирергә теләгән соравым сезгә сәер дә тоелыр. Хакимиятләр этне саф һавада йөртеп алып керер өчен билгеләгән әлеге дә баягы «йөз метр»ны ничек билгеләргә, дип кызыксынуым. «Тору урыны» дип билгеләнгән әлеге «төгәл» ориентир нәкъ менә кайдан башлана? Безнең микрорайонда күптән түгел генә булып киткән полицейскийлар подъезддан дип ышандыра. Безнең активлыкка ияләшкән яшь терьерыбыз моның белән килешмәде. Бу җәһәттән армия хезмәтен Б-413 дизельле су асты көймәсендә үтеп кайткан этинең сөйләгәне искә төште. Бу көймә белән мин Калининград музеенда танышкан, һәм дөресен әйтергә кирәк, андагы каюта һәм бүлемтәләрнең тарлыгына хәйран калган идем.

– Башта безне алдадылар, – дип сөйли эти. – «Малютка» дигән иң бәләкәй су асты көймәсенә алып килделәр – анда тураеп басып та булмый. Без еламыйбыз гына – шундый шартларда өч ел!

Мондый психологик алым армиягә яңа килгәннәргә бик көчле тәэсир итте, андыйдан соң Б-413 җәннәт булып тоела инде! Менә безнең эт өчен дә подъезддан саналган йөз метр «Малютка» булып тоелды, ә йорттан башлап саналганы инде – Б-413. Бәхеткә, «кайнар элемтә»дәге арыган тавыш безгә йорт янышнан дип рөхсәт итте. Без бәхеткә тиендек. Әйе, бөтен нәрсә чагыштыру аша белена.

Этебезнең төссезләнеп калган көннәренә күпмедер активлык һәм төрлелек кертү максатыннан, без аны тәрбияли башладык – трюклар, дог-фитнес, ноузворк ясатабыз... Ә моның өчен – дистәләрчә лекцияләр, вебинарлар, мастер-класслар, марафоннар. Кыскасы, интернетта тулы канлы эт тормышы! Хәзер менә безнең көйрыклы дустыбыз акыл ягыннан хуҗаларын узмаса ярар иде дип борчылабыз инде.

Сүз уңаеннан, үзизоляция эт асраучыларга көн саен диярлек яңа проблема китереп чыгарды. Кирәкле ризыгын каян сатып алырга? Якындагы зоокибеткә ничек барып җитәргә? Сезонлы груминг каралганнарга нишләргә? Зоосалоннар бикле бит. Киңәш-табыш белән боларның барысы да хәл ителде, әлеге дә баягы онлайн аша. Киңәшләр, бергә кушылып сатып алулар, әхлакый теләктәшлек һәм юмор ярдәмгә килде.

Дүртенче көнгә этләр төркемендә үзләренең дүрт аяклы дусларын «күршеләр саф һава суларга йөри алсын өчен» бер сәгатькә арендага бирергә хәл итүчеләр табылды. Бүгенге көндә популяр булып киткән анекдоттагы кебек: «Таныш булыгыз, бу Шарик – күпкатлы йорттагы берденбер эт. Ул бүген алтмыш тапкыр урамга чыгып керде». Кемдер хәтта сайтка игълан элде: бер сәгать йөреп керү – йөз сум, залогка паспортны калдырасы. Фотода мәһабәт кыяфәтле... стаффордшир терьеры. Иманым камил, теләк белдерүче табылмагандыр. Эт хуҗаларының күбесе мондый тәкъдимнәргә тискәре мөнәсәбәт белдерде – дусларны арендага бирү ярый торган эш түгел.

Кояшлы көннәрен балконда үткәрүче күршеләрне көнләштереп, без сукмакларда адымнарны үзебез санап йөрдек. Безнең шат күңелле җирән Ирландия кунагыбыз гына тормышының ни өчен шулай кинәт үзгәрүен аңламый иде: хуҗаларны хәзер өй тирәли генә йөртеп керәсе, өстәвенә муенчаклы бауда һәм катгый рәвештә борынчак кидереп (ах, гафу итегез, битлек!). ▪

ТАЯКНЫҢ ИКЕ БАШЫ...

Лондонда яшәүче милләттәшебез Лилия Сербан – Англиядәге яшәү рәвеше һәм пандемия тудырган вазгыять турында

– Күпләр чит ил тормышын әкияттәге кебек күзаллый. Әмма һәр нәрсәнең уңай гына түгел, тискәре ягы да бар...

Мин 15 ел инде Англиянең башкаласы Лондонда яшим. Булачак тормыш иптәшем Богдан белән бередә таныштым. Казан дәүләт университетының татар журналистикасы бүлегендә укып йөргән вакыт иде ул. Төркемдәшем Альбина белән махсус программа буенча эшкә – җиләк җыярга бардык. Бер уңайдан дөнья күрәсебез, инглиз телен дә өйрәнәсебез килде. Ә бер елдан, кулга диплом алгач, мин туры булачак ирем янына очтым. Без өйләнештек. Бүгенге көндә өч балабыз бар, улларыбыз – Данни, Джейсон, кызыбыз Джесика Сара. Кайнанам, кайнатам да безнең белән яши. Яшьләре олыгаю сәбәпле, сәламәтлекләре бик әйбәт түгел. Көн саен алар янына барып йөргәнче, дип, үзебезгә алып килүне кулайрак күрдек. Тумышлары белән алар Румыния якларыннан.

Берничә ел элек Лондон читеннән зур йорт сатып алдык. Бу минем күптәнге хыялым иде. Тумышым белән мин Лениногорск шәһәреннән. Җирдә казынып, үз йортыбызда үскән бала. Шуңа күрә җиргә тартылуым табигыйдер. Йортны үзем сайладым. Ирем өчен бу әллә ни мөһим түгел, дөресрәге, ул аның тәмен аңлап бетерми. Йортка күченгәч тә, иң беренче эш итеп, мунча салдык. Шуны әйтим – Англиядә бездәге кебек мунчалар юк. Алар өчен юыну урыны – душ, ванна. Ирем берничә тапкыр Татарстанга, минем туган ягыма кайтты. Мунча эшләүнең нечкәлекләрен өйрәнде. Хәзер ел саен ирем белән бергәләп төрле үләннәрдән себерке җыябыз. Күршеләр килеп-килеп карый, бу хәлгә шаккаталар.

Бакчага кыяр, помидор, җиләк-җимеш утырттым. Хәтта бәрәңге дә үстерәм. Шулай ук алма, груша, чия кебек агач-куаклар да бар. Шуңа күрә үземне Англиядә түгел, ә гади бер бистәдә яшәгән кебек сизәм. Дөрес, күршедә, татарлар, руслар да юк. Ана телемдә интернет аша бары дәү әнием, әнием белән генә аралашам. Ә балалар татарча аерым сүзләрне генә белә. Өйдә гел инглизчә аралашкач, аларны татарчага өйрәтү шактый авыр.

Ул-кызлар турында сүз чыккач, Россия белән чагыштырганда, биредә балаларны яклауга кагылышлы кануннарның төгәл эшләвен дә әйтим. Тагын мәктәп укучыларына чит илгә бару мөмкинлеге бар. Мисал өчен, улыбыз Данни узган ел Кытайда һәм Ирландиядә булып кайтты. Әлбәттә, бу түләүле. Ләкин әллә ни зур сумма түгел, биредә яшәүче гаиләләрнең күбесе моны күтәрә ала. Мондый тәҗрибә нәрсәгә кирәкме? Беренчедән, бала чит телләр өйрәнә, икенчедән, мөстәкыйльлеге арта.

Уку системасы Россиядән бик нык аерыла. Англиядә җәйге каникуллар алты атна гына. Биредә алты ел укыганнан соң, балалар бүтән мәктәпкә күчә – профиль буенча бүленәләр. Монда соңгы кыңгырау бәйрәме юк. Шулай да хушлашу көне бар. Алты ел бергә укыган сыйныфташлар, бер-берсенең киемнәренә телефон номерларын, теләкләр язалар. Елап аерылышучы дуслар да бар. Англиядә югары уку йортлары түләүле. Һәм ул өч ел гына. Дәүләт булачак студентка кредит бирә һәм, эшкә урнашкач, яшь белгеч дәүләткә әкрен аз-азлап кайтара.

Олы улыбыз Данни алтынчы сыйныфны тәмамлагач, төгәл фәннәр буенча китте. Математика һәм информатиканы тирәнтен өйрәнә. **Бездә дә быелгы уку елы онлайн рәвештә төгәлләнде. Минемчә, мондый уку мәктәпкә барып белем алудан күпкә калыша. Яңа уку елы да онлайн башланыр дип уйлыйбыз. Үзизоляция яңа елга кадәр барачак, дип тә әйтәләр.** Тик бу рәсми мәгълүмат түгел. Авыруларга килгәндә, хәл хәзер тотрыклы, әмма чир әлеге чигенмәде. Үлүчеләр бик күп.

Пандемия шартларында Англиядә дә җиңел түгел. Күп оешмаларның эшчеләре инде дүрт айга якын өйдә утыра. Аларга хезмәт хакының 80 процентын түлиләр. Бездә пенсионерлар җәмәгать транспортында бушка йөри. Пандемия чорында, өлкәннәрне өйдә утырту максатыннан, җәмәгать транспортын алар өчен түләүле ясадылар. Ә менә балалы гаиләләргә, пандемия чорында дәүләт өстәмә акча түли башлады: беренче балага – 21 фунт, калганнарына – 14 фунт. Бу – атна саен.

Бездә дә шул ук хәл: битлек, перчаткалар урамга чыкканда мәҗбүри санала. Кешеләр бер-берсенә бер метрдан якынрак килергә тиеш түгел. Сырхауханәләргә эләгеп булмый, пандемия аркасында алар ябык. Түләүле клиникаларга да эләгү авыр, чират зур. Бәяләре дә артты.

Яхшы хәбәрләргә килгәндә, июнь аенда кайбер сәүдә үзәкләрен ачтылар. Тик безнең әле анда барганыбыз юк, чир ияртүдән куркабыз. Кибетләрдә чиратлар зур диләр. Спортзаллар, башка күңел ачу үзәкләре дә эшләми. Спортзалга абонемент алган кешеләрнең карталары бүтән айларга чигерелде. Банклар кредит түләүне дә «катырды», тик бу вакытлыча гына.

Миннән еш кына: «Туган ягыңны сагынасыңмы?» – дип сорыйлар. Бик сагынам. Шуңа да өйдә гел милли ризыклар – өчпочмак, гөбәдия, токмачлы аш пешерәм. (Ирем, кайнанам белән кайнатам да бу ризыкларны бик ярата). Түгәрәк өстәл артына җыелышып ашыйбыз. Өйгә кайткандай булам... Быел гаиләм белән Татарстанга җыенган идек, тик пандемия аркасында булмый. Әни дә килә алмый, сорашкан идем, билетлар ике тапкырга арткан. Әле ярый интернет эшли, якыннарымның йөзен күреп сөйләшү мөмкинлеге бар. Англиянең табигате матур, һавасы чиста. Мин әлегә эшләмим. Ирем тәэмин итә һәм бу безгә җитә. Менә шулай яшәп ятыш. «Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган җир», диләр бит. Мин дә туган ягымны, якыннарымны бик сагынам. Англиядә яшәүнең иң зур минусы – сагыну әчеседер. Калганы рәхәт.

Әзерләде: Руфия Фазылова

КАБАТ ИСКӘ ТӨШЕРЕРГӘ ҺӘМ ҖИҢӘРГӘ

Инна Веселова, антрополог, – гомуми кризисларны җиңүнең без барыбыз да белгән, әмма онытқан ысуллары турында.

Инна Веселова (1971) – фольклорчы, антрополог, филология фәннәре кандидаты, Санкт-Петербург дәүләт университетының рус әдәбияты тарихы кафедрасы доценты.

Бүген, коронавирус пандемиясе башланып берничә ай үткәннән соң, без төрле дәрәҗәдәге һәм төрдәге – халыкарадан алып гаиләнекенә кадәр, икътисадый сикерешләрдән алып психикадагы үзгәрешләргә кадәр – кризисларны күзәтәбез. Хәер, кешелек тарихында афәт һәм бәла-казалардан соңгы кыенлыкларны җиңеп чыгу буенча шактый гына тәҗрибә тупланган инде. Әлеге тәҗрибә гореф-гадәтләр һәм йолалар сыйфатында сакланган, аларның кайберләре хәзергә кадәр файдаланыла.

Бүгенге Италияне алыйк. Биредә XXI гасыр чумасы белән көрәшүче табибларны гына алкышлап калмыйлар. Йөзләрчә ел элек уннарча мең кешенең гомерен өзгән чумадан котылу хөрмәтенә Венециядә июльнең өченче якшәмбесендә XVI гасырдан бирле Фестадель Реденторе бәйрәм ителә. Җирле халык иртән чиркәүгә мессага бара, ә туристлар кичен гаять күркәм фейерверкны көтеп ала.

Германиядәге Шварцвальдта исә кайчандыр булган бәла-казалар һәм һәлакәтләр истәлегенә карнавал оештырыла. Кичерелгән эпидемияләр һәм афәтләр хакында һәркайсы махсус стильдә киенгән карнавал бригадалары хәтергә төшерә. Карнавал костюмнары буыннан буынга тапшырыла һәм андый критик вакытлар булуын, тик аларның үтүен, шуңа да карамастан, аларга һәрвакыт әзер булырга кирәклеген искәртә. Әлеге йөреш дәүләт парадлары сыман пафослы түгел, бәйрәмдә һәркем үз ихтыярынча катнаша ала. Шул рәвешле шәхси аң күмәк аңга кушыла, үз-үзеңне оештыру сәләте көчәя.

Хәзерге Россиядә җәмгатьчелекнең бу кизүгә реакциясе Европаның күпчелек илләрендә күзәтелгәннән аерыла. Аның диапазоны искиткеч киң. Бер полюста – ковид-диссидентлык, икенчесендә – паникалы өянәкләр. Беренчесендә – югары әхлакый җаваплылык, икенчесендә – тәкъдиргә ышану…

Феста дель Реденторе.

Үзеңне оештыруга һәм белгечләр киңәшенә карата ихтирам белән карау мәсьәләсендә килеп туган кыенлыклар, минемчә, теләсә кайсы хакимияткә ышанмау, афәт-һәлакәтләр хакындагы локаль һәм гаилә хәтерен югалту белән бәйле. Җитмәсә, Россия мәдәни тәҗрибәсендә кайчандыр мондый хәтерне бергәләп саклаганнар. Янгын, су басу һәм эпидемияләр хатирәсе итеп көндәлек (иртә таңнан кояш баеганчы бер көндә өмә белән төзелгән) кәшәнәләр (часовнялар) салганнар яки сөлгә тукыганнар, шул рәвешле афәтнең юлын томаламакчы булганнар. Аннары кәшәнәләр урынында таш гыйбадәтханәләр төзегәннәр һәм бәла-казадан котылу көнен ел саен шунда билгеләп үткәннәр, тирә-күршеләр бергә җыелып табын корган, эшләү катгый тыелган.

Рус авылларында «нәзер» бәйрәмнәре һәм бурычлары гадәте булган – гомуми яки шәхси бәла-каза очраклары өчен индивидуаль яки күмәк дини практикалар һәм йолалар башкарылган. Менә шуңа коллегаларым белән Вологда өлкәсендә язып алган бер мисал: «Было раньше пад скотины – вот эти заветные праздники и сделали. Всё-всё и прикончилось. Иконку на носилках носили: у нас была большая. Это в заветные. И лучше было: весь пад и решился... Иконка Троерушная, так названа. А у нас, на Фофанове, – Казанская праздник. Это заветные всё. А на Устье – Диюшко заветный праздник. Была у них часовня – все сломали».[1]

Безнең әңгәмәдәшебез совет дәверендә җимерелгән кәшәнә хакында аның дин корылмасы буларак юкка чыгарылуына гына түгел, шул катлаулы чордагы афәт һәм аның тәмамлануы турындагы хатирәнең дә бергә югалуына хафалана иде. Нәзер көне белән бергә бәла каршында берләшү, уртак табын кору һәм өмә үткәрү, килешеп эшләү күнекмәсе дә сакланган бит.

Советлар Союзында бәйрәмнәрне күмәкләштерү һәм национальләштерү безне шәхси катнашкан бәйрәмнәребездән, локаль хәтердән һәм күрше-тирәнең үзара ярдәмләшеп яшәү кебек үзенчәлекле тәҗрибәсеннән мәхрүм итте. Кайбер очракларда алар бердәнбер диярлек чын көчкә әйләнә – мәсәлән, Дагыстанда коронавирус таралу вазгыятендәге кебек.

Хәер, халык хәтереннән бөтен нәрсә дә җуелып бетмәгән әле. Мәсәлән, «кара көндә» үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Авылларда хәзергә кадәр сакланып калган иске әйберләрдән яңаны туку һәм үрү гадәте – кабат эшкәртү күнекмәләре ул. Тикшеренүчеләр аны XX гасырның 20 нче елларында ук теркәгән инде. Өйдә тукылган келәмнәрдән кием теккәннәр, ягъни бу икенче, йә булмаса өченче тапкыр яңартылу боҗрасының торгызыла торган ресурсы булган. Беренче Бөтендөнья сугышыннан соңгы елларда солдат шинеле эш киемен генә алмаштырып калмый, бәлки еш кына хатын-кыз пальтосына да әйләнә бит.

Шул рәвешле, озакка сузылган кризис көндәлек көнкүрешне уннарча елга үзгәртә. Минем бабамның әтисе, Казанда үз йортында торса һәм фабрикада эшләсә дә, сугыштан соң озак вакыт бүе абзарында терлек асраган, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстергән, әбиемнең әнисе эрли-бәйли белгән. Үз-үзеңне тәэмин итү күнекмәләре – россиялеләрнең нәселдән килгән хәтерендә. Мартта күпләрнең запаска азык-төлек сатып алуы да – шуның нәтиҗәсе...

Гореф-гадәтләр һәм бәйрәмнәрнең максаты шунда ки, алар гомуми чынбарлыкны яшәтә. Әлеге бергәлек уртак эш һәм шәфкатьлелек күнекмәләре белән бергә тудырыла. Әйтик, мәсәлән, бик үк бай булмаган гаилә запасларыннан да мохтаҗларга өлеш чыгару. Сугыштан соң әбиләрнең әсир немецларны алма яки икмәк белән сыйлавын искә төшерик. Һәм бүген дә без аерым мисалларда шуны күрәбез – дәүләттән тыш үзара ярдәм һәм кайгырту системасы рациональ чаралар эшли алырлык мохитне тудыра: табибларга рәхәтләнеп эшләү һәм ял итү урыннары хәстәрләнә, зәгыйфь, мохтаҗ күршеләргә ярдәм оештырыла һ.б.

Шунысы кызык, традицион культураларда һәлакәт йолаларын үтәү фаҗига кичергән аеруча абруйлы «белгечләргә» (революциягә кадәрге Россиядә – тол хатыннарга, солдаткаларга, ятимнәргә) йөкләнә. Биредә параллельләр үткәреп була. Куркыныч янәшәсендәге ритуал вакытында (мәсәлән, хатын-кызның дога укып янгын урынын әйләнеп йөрүе яки бүгенге табибларның кызыл зонада эшләве) гомумкыйммәтләр һәм хәвефләр кайгыртыла. Куркыныч зонада булучы киңәш бирергә хокуклы: әгәр бүген кемнеңдер киңәше ышандыргыч икән, бу төрледән-төрле комитет вәкилләренеке түгел, бәлки нәкъ менә авыруларга турыдан-туры ярдәм итүче табибларның тәкъдимнәре булыр.

Ничек кенә сәер тоелмасын, үзчикләү дә – шул ук йола алымы. Ул инициация – бер социаль статустан икенчесенә күчү (мәсәлән, монахлыкка кабул ителү) йолаларында файдаланыла, күп кенә культураларда исә афәт ритуалларында да бар. Ритуаль чикләнү вакытында зыян күрүчеләр үзләренә башка күзлектән карый һәм шуның белән эгоцентрик позициядән читләшә, бу исә яңа экзистенциаль чикләргә юл ача.

«Әхлакый бурычка нигезләнгән кыйммәтләр системасы булганда, рациональ чаралар мәдәни һәм социаль яңарышның күп гамәли проблемаларын хәл итәргә булышачак»,[2] – дип язган XX гасырның бик күп куркыныч афәтен – Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышларын, Гражданнар сугышын, Октябрь революциясен, аннан соңгы ачлыкны, тиф һәм испанка эпидемияләрен үз башыннан кичергән Россия һәм Америка социологы Питирим Сорокин.

Ул әхлакый кыйммәтләр хакындагы гомуми килешүне яңарту кризисны җиңеп чыгуның бердәнбер мөмкинлеге дип санаган. Безнең җәмгыять бүген нәкъ менә шундый килешү төзи ала. Аз кешеле коллективлар дәрәҗәсендә генә булса да килешү төзелсә, рациональ гамәлләр уңышлы була алыр иде.

Төрле культуралардагы афәт ритуалларының максаты – кризистан соң индивидны һәм җәмгыятьне аякка бастыру өчен шәхси тырышлыкны гомум мәнфәгатьләрдә берләштерү. «Әлеге яңарыш шул рәвешле булырга тиеш ки, яңа система хисләр дөньясының бөтен шәп кыйммәтләрен генә түгел, иң мөһиме, әхлакый бурыч кыйммәтләрен дә үз эченә алырга тиеш», – ди Сорокин. Биредә әхлакый бурыч – тантаналы мәрасимнәр түгел, бәлки үзара ярдәмләшү, хәзер күп кешегә нәкъ менә шул җитми.

[1] Бел18-148, 95-07-08, Вологодская обл., Белозёрский р-н, Артюшинский с/с, Устье, Чаева Авдотья Кирилловна, 1901. Зап. Веселова И. С., Карпов Н. А.

[2] Сорокин П. Человек и общество в условиях бедствий...

МАКСАТКА ОМТЫЛЫШ

Безнең һәркайсыбыз үз шәһәрен, үз ватанын, үз өен ярата һәм республика төзүчеләре күтәргән заманча корылмаларга соклана. Төзелешнең югары сыйфаты, объектларны тиз арада тапшыру, ышанычлылык һәм күркәм дизайн Газинур Әхмәтовның «Ак таш» компаниясен республиканың төзелеш өлкәсендәге алдынгылар дәрәҗәсенә күтәрде.

2007 елда оешкан компания кечкенә предприятиедән алып төзелештә генераль подрядчы булып чыгыш ясарлык эре оешмага кадәр катлаулы һәм кызыклы үсеш юлы үтә. Иннополис, «Бәләкәч» балалар бакчалары, Универсиаданың спорт корылмалары, Качалов театры, «Салават күпере» торак комплексы – болар соңгы елларда «Ак таш» ҖЧҖ төзегән объектларның тулы исемлеге түгел дә әле хәтта. Әлеге ышанычлы компанияне сайлап, заказчылар торак яки сәнәгать төзелеше өлкәсендә төзү эшләренең тулы спектрын башкаручыга ия була. «Ак таш» гаиләләрне социаль ипотека буенча сыйфатлы торак белән тәэмин итә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы белән партнерлыкта зур-зур дәүләт проектларын гамәлгә ашыра. Үз эшләре белән республика җитәкчелегенең ышанычын яулап, Газинур Әхмәтов командасы яңа мәсьәләне хәл итәргә алынды – йогышлы авырулар хастаханәсенең яңа корпусын оператив рәвештә төзергә кереште. Медицина блогы универсаль булачак: анда балаларны да, өлкәннәрне дә дәвалый алачаклар.

ОЕШМАНЫҢ БҮЛӘКЛӘРЕ АРАСЫНДА – РФ Президенты Владимир Путинның Грамотасы, компания директоры Газинур Әхмәтовка ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Рәхмәт хатлары, ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Мактау грамотасы һәм республика муниципалитетларыннан бик күп рәхмәт хатлары.

– 15 августта Казанда яңа, заманча хастаханә – лаборатория корпусы булган, 232 ятакка исәпләнгән, ятаклар санын 504 кә кадәр арттыру мөмкинлеге каралган йогышлы авырулар хастаханәсе эшли башлаячак, – дип хәбәр итте ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Мәгариф учреждениеләрен модернизацияләү һәм, гомумән, үсеп килүче буын өчен компания тарафыннан күп нәрсә эшләнә. «Арт Сити» торак комплексында 1500 балага исәпләнгән мәктәп – ике бассейны, спорт заллары булган, балаларның һәрьяклап үсеше өчен өр-яңа җиһазлар куелачак заманча белем бирү үзәге төзелә. Мондый могҗиза мәктәпләрдә балалар белем туплау белән бергә сәламәт, культуралы булырга да, матурлыкны бәяли, үз талантларын күрсәтә белергә дә өйрәнәчәк. Нәҗип Җиһанов урамында 1224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү мәктәбен төзү, Алабугада полилингваль мәктәп төзелеше дә дәвам итә. Бу объектлар көндәлек гадәти нәрсәләрне дә сәнгать әсәренә әверелдерергә сәләтле «Ак таш» төзүчеләренең искиткеч осталык үрнәге булып тора.

Башкарыла торган хезмәтләрнең югары сыйфаты, инновацияле технологияләр кертү әлеге төзелеш компаниясен башкалардан аерып тора. Ул Казанда һәм республика районнарында торак йортлар, күп катлы паркинглар һәм коммерция объектлары төзи. Үз бурычларыңа намуслы мөнәсәбәт һәм төзүчеләр хезмәтенең кешеләр өчен мөһимлеген аңлау Газинур Әхмәтовның уңыш фәлсәфәсенә әйләнде.

– Безнең өчен кулланучыларның өметен аклау мөһим, чөнки күпчелек кеше өчен торак сатып алу – тормышындагы төп вакыйга. Социаль җаваплылык – хезмәттә мөһим ярдәм. Проектларны гамәлгә ашыруга намуслы мөнәсәбәт компаниянең нигез шигаренә әйләнде, – дип билгеле компания башлыгы.

Тәҗрибәле һәм җаваплы белгечләрдән гыйбарәт зур, бердәм коллектив уңышлы эшнең нигезе булып тора. Анда 1800 гә якын кеше исәпләнә. Яңа кадрлар килеп торуның мөһимлеген аңлап, компания җитәкчесе яшьләргә һәм перспективага йөз тота. Газинур Әхмәтов профильле югары уку йортлары студентларын җитештерү практикасына чакыра һәм WorldSkills хәрәкәтенә актив булыша: 2014 һәм 2015 елларда эшче һөнәрләр чемпионатында катнашучы студентлар өчен бәясе 5 млн сумнан артык булган җиһазлар сатып алынган.

Бүген «Ак таш» – Татарстанның тотрыклы үсештәге республика буларак имиджын һәм тышкы йөзен булдыручыларның берсе. Компаниянең бу уңышын, үз язмышын төзелешкә багышлап, әлеге тармакта иң танылган идарәчеләрнең берсенә әйләнгән җитәкче шәхесе белән дә турыдан-туры бәйлиләр.

Һөнәри бәйрәмнәре – Төзүчеләр көне алдыннан редакциябез компаниягә Татарстанның үсеше, чәчәк атуы өчен башкарган мөһим эшендә киләчәктә дә уңышлар теле!

Реклама. Фото «Ак Таш» ҖЧҖ тарафыннан бирелде

Компаниянең һич тел тидермәслек, мактауга лаеклы хезмәте өчен алган күпсанлы бүләкләре һәм рәхмәт сүзләре сыйфатлы төзелешнең иң яхшы дәлиле булып тора.

УҢЫШ ПРИНЦИПЛАРЫ

«Татарстан төзүчеләре» – республиканың ышанычлы һәм танылган төзелеш компанияләре турында сөйли торган проект. Шундыйларның берсе – «ЕвроТехСтрой+» ЖЧЖ. Ул бөтен Россия буенча төрле максатлардагы сыйфатлы объектлар төзү өлкәсендә бай тәҗрибәгә ия. Компания директоры Нариман Зәйнетдинов безгә үз эшләренең төп принциплары турында сөйләде.

«ЕВРОТЕХСТРОЙ+» ЖЧЖ – сыйфатлы һәм сертификацияләнгән материаллар, заманча технологияләр һәм сыналган ысул-алымнар куллану, һәр заказчының шәхси теләкләрен искә алу, клиентка йөз тотып эш йөртү, шулай ук кулланыла торган материалларның тиешле сертификатларын һәм җиһазларның сыйфат паспортларын үз эченә алган барлык башкарма-техник документларның тулы исемлеге дигән сүз ул.

Коммерцияле күчемсез милек төзү һәм реконструкцияләү, биналар һәм корылмалар төзү – ширкәт эшчәнлегенең төп юнәлешен тәшкил итә. Компания тулы цикллы проектларны тормышка ашыра, барлык нормаларның һәм куркынычсызлык техникасы таләпләренең мәҗбүри рәвештә үтәлешенә игътибар биреп, һәр төзелеш этабының ышанычлылыгын тәэмин итә. Казан компаниясенең эш географиясе гаять киң – Казан, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе, Сургут, Уфа, Оренбург, Ижау аның хезмәтләренең югары сыйфатын бәяләргә өлгерде инде. Мондый зур эш ареалына гаҗәпләнәсе дә юк, чөнки кирәкле корылманы сыйфатлы һәм тиз арада төзергә әзер профессиональ төзүчеләр һәркемгә кирәк. Чыннан да, әлеге фирманың эшлекле абруе күпләргә мәгълүм – ул үзен ышанычлы төзүче буларак таныпты. Оешма сертификацияләү процедурасын да уңышлы үтте һәм инде 2010 елдан бирле җитештерү эшчәнлеген «ТР Төзүчеләр бердәмлеге» үзкөйләүле оешмасы ассоциациясе таныклыгы нигезендә башкара.

Азык-төлек кибетләре төзелешен компаниянең иң мөһим казанышларыннан берсе дип санарга мөмкин. «Евротехстрой+» ЖЧЖ компаниясе төзегән кибетләрдә һәркайсыбызның күп тапкыр булганы бар дип һич шикләнми әйтергә мөмкин. Әйтик, «Пятерочка», «Верный», «Карусель», «Перекресток», «Магнит» сәүдә челтәрләре оешманың партнерлары булып тора. Тулаем алганда, 100 гә якын кешедән гыйбарәт әлеге Казан ширкәте тарафыннан 260 объект төзелгән. Хәзер компания торак төзелеше сегментын актив үстерә. Бу җәһәттән «ЕвроТехСтрой+» берничә мөһим өстенлек белән аерылып тора. Болар – объектларны билгеләнгән вакытка тапшыру, башкарылган эшләрнең сыйфатын гарантияләү, комплекслы эш алып бару. Фирма эшчәнлеге биналар һәм корылмалар төзү процессын, проектны сайлап алудан башлап, төзелеш объектын тулысынча әзер хәлдә файдалануга тапшыруга кадәр тулысынча тәэмин итүне күздә тота. Биналар һәм корылмалар күтәргәндә төзелеш-монтаж эшләренә ихтыяҗ туганда, «ЕвроТехСтрой+» ЖЧЖ барлык төр проекткача һәм проектлау эшләрен башкарачак.

– «ЕвроТехСтрой+» ЖЧЖ төзелеш базарындагы теләсә нинди катлаулы мәсьәләләрне инде 15 ел дәвамында уңышлы хәл итеп килә, – ди компания директоры Нариман Зәйнетдинов. – Туплаган тәҗрибәбез ярдәмендә без үз эшебезне ничек яхшырак итеп башкарырга икәнлеген төгәл беләбез. Безгә мөрәҗәгать иткәндә, сез матурлау-бизәкләү эшләреннән алып яңа биналар төзүгә кадәр ремонт-төзелеш хезмәтләренең тулы җыелмасын да аласыз, бу исә вакытыгызны һәм башка подрядчыларны эзләүгә китәчәк чыгымнарны янга калдырырга мөмкинлек бирә. Эш-мәсьәләләрегезне безнең белгечләргә ышанып тапшырып, үзегезгә кирәкле һәм гарантияләнгән нәтиҗәгә ирешәчәксез.

ЕВРОТЕХСТРОЙ+

Реклама. Фото ООО «ЕвроТехСтрой+» ЖЧЖ тарафыннан бирелде

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
Подписка!
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Фәйзи Йосыпов – татар сүз сәнгате генералы
Кече Ватан патриотлары
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
07 июля 2020
03 июля 2020
02 июля 2020
Әбрар Кәримуллин: китап һәм милләт сагында
Кече ватан патриотлары
2020 елгы китаплар, яки бүләккә нәрсә кулай
«Яңа инфекцияләр киләчәктә кабатланып торачак»
Реклама 16+

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр /

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

100 елдан соң мөхәррирләр ничек очрашты

Лотфулла Фәттахов гомере буе нәрсәдән курыккан

Илдар Хәйруллин кемнәрнең сүзенә колак сала

100 «ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА ЯШЬ

ИҢ *беренче* ИҢ *зирәк* ИҢ *креатив*

1920 елдан 2020 елга кадәр тәүге йөзьеллыкта «Татарстан» иҗтимагый-сәяси журналы белән 20 баш мөхәррир җитәкчелек итә. Һәр баш мөхәррир (әүвәл бу вазыйфа җаваплы мөхәррир дип атала) каршына республика җитәкчелеге аерым максатлар һәм бурычлар куя. Бу бурычларны ничек тормышка ашырырга кирәклеге турында һәр мөхәррирнең үз карашы була. Шулай ук куелган максат-бурычларга ярашлы рәвештә – журналны кызыклы һәм укылышлы итәрлек журналистлар һәм штаттан тыш авторлар командасы да.

Кайчак, бигрәк тә сугышка кадәрге чорда, алар максатка ирешә алмый һәм баш мөхәррирләр репрессияләр дулкынына эләгә, алар хәтта атып та үтерелә. Сугышка кадәр журнал белән җитәкчелек итеп, репрессияләнгән беренче дистә редактордан «Татарстан»ның ИҢ БЕРЕНЧЕ баш мөхәррире Александр Петрович Таняев кына атылмыйча кала. Дөньяга чыккан тәүге ае – 1920 елның декабрендә – журнал «РКП(б) ның Татар өлкә комитеты хәбәрләре» дип атала.



«ТАТАРСТАН»НЫҢ БАШ МӨХӘРРИРЛӘРЕ

ИҢ *беренче*

«Вестник Татарского областного комитета РКП(б) » журналының (булачак – «Татарстан») беренче санын 1920 елның декабрендә басмага Александр Таняев – Мәскәүдә Октябрь коралллы күтәрелешләрендә катнашкан, РКП(б) ның Татар өлкә комитетының иң беренче секретаре (1920 елның августында – ред. иск.), тәҗрибәле журналист – кул куеп җибәрә. 22 яшьлек егет өчен – искиткеч хезмәт дәфтәре.

КОНТРРЕВОЛЮЦИЯ ЙОКЛАМЫЙ

«Тыштан караганда яшь кенә күренгән Таняев гади, сөйкемле, кешеләр белән уртак тел табып сөйләшә, аннан да бигрәк тыңлый белә. Яхшы оратор санала» – беренче мөхәррир турында замандашлары шундый хатирәләр теркәп калдырган. Александр кешеләр белән аралаша белеп кенә калмый, ә большевистик идеяләрне кәгазьгә дә аңлашыла торган итеп төшерә белә. Партия башлыгы һәм Мәскәү университетының физика-математика факультетында берничә ел белем алган студентның язмалары даими рәвештә республика газеталарында басылып тора. Аның иҗатының бер үрнәге – «Контрреволюция йокламый» дигән мәкалә. «Совет власте өчен көрәш хакына берләшкән рус һәм татар хезмәтчәннәре, – дип яза автор, – почмаклардан китереп сукканга да, арттан килеп сукканга да совет хакимияте тирәсенә тагын да ныграк берләшү белән җавап бирәчәк, милли ызгышлар чыгаручыларга карата алар рус һәм татар хезмәт кешеләре массаларының тагын да тыгызрак берләшүе белән җавап кайтарачак».

Журнал белән җитәкчелек итүгә күчкәч тә, Александр Таняев республика дәүләт хакимиятенең иң югары органы Татар ҮБК Президиумы әгъзасы булып кала, ләкин бу аның мөхәррирлек тормышын җиңеләйткәндер дип булмый: журналист кадрлар җитми. Шуңа карамастан, басманы айга ике тапкыр өчәр мең данә чыгару эше җайга салына. Бирәдә рәсми күрсәтмәләр һәм циркулярлардан тыш, иҗтимагый-сәяси характердагы материаллар да басыла, гомумпартия бәхәсләре дә, партоешмаларның эшчәнлеге дә яктыртыла...



Александр Таняев бер елдан азрак вакыт кына мөхәррир була. 1921 елда РКП(б) Үзәк Комитеты аны Урта Азиягә командировкага җибәрә. Аннан соң Мәскәүдә Кызыл профессура институты, докторлык диссертациясен яклау, Урал ВКП(б) өлкә комитетында, РСФСРның мәгариф халык комиссариатында эшләү, 1937 елда кулга алыну... ГУЛАГта 19 ел үткәргәннән соң, 1956 елда, ниһаять, ирекка чыгу.

ПАРТИЯ ТАРИХЫ ИНСТИТУТЫ ПРОФЕССОРЫ

...1965 елда КПСС ҮК каршындагы Партия тарихы институты профессоры Александр Таняев Казанда да була. Баумандагы Матбугат йортында, Тукай клубында, журналистлар белән очрашулары үтә. «Мин, әлбәттә, Татариянең уңышлары, бөтен илдәге кебек, искиткеч зур икәнлегенә ышанган идем. Якыннанрак танышкач, биредәге үзгәрешләрне күреп таң калдым... – дип, күргәннәреннән тәэссоратлары белән уртаклаша ул. – Ләкин безнең үткәннәрне онытырга хакыбыз юк. Үткәннәребез безгә ирешкәнне бәһаләргә, узган юлыбызны тулырак күзалларга мөмкинлек бирә».



«Мин баш тарттым, чөнки партиядән күңелем кайтып, аннан чыккан идем инде. Ә менә журнал башкачарак аталса, әйтик, «Татарстан» дип, уйлап карармын, дидем». Әлеге мәсьәләне бюрога куялар. Һәм 1991 елдан башлап, журнал «Татарстан» дип атала башлый. Мостафин берничә ел дәвамында басманы яңа идеологик рельсларга бастыру өчен бөтен көчен куя. 1991 елдан 1998 елга кадәр журналга җитәкчелек иткән иң зирәк мөхәррирдән безгә ядкәр булып аның акыллы фикерләре калды.

ИҢ *зирәк*

Язмышка шулай язылгандыр: журналның исемен чираттагы мәртәбә күренекле язучы һәм публицист Рафаэль Мостафинга алыштырырга туры килә. 1990 елда аны КПСС өлкә комитетына чакырып алалар һәм идеологик төймәләргә ныклап төймәләнгән партия басмасын үзгәртеп кору рельсларына күчерү максаты белән «Татарстан коммунисты» журналын җитәкләргә тәкъдим итәләр.

«Мин совет чорында үстем һәм рухи тәрбия алдым. Революцион идеалларга һәм коммунизмның алсу таңы атачагына чын күңелемнән ышана идем. Ә аннан соң торган саен күзем ачыла төшеп, мин дә әлеге инануларымнан арындым.

Журналистиканың асылы һәм мәгънәсе дөньяны аз гына булса да яхшырту, кешеләрнең сулышларын киңәйтүдә чагыла. Мин каләм әһеле буларак, үз бурычымны ничек булса да җәмгатьчелекнең фикеренә тәэсир итү, дип күзаллыйм. Мәсәлән, табигатькә карата саксыл мөнәсәбәт тәрбияләү. Үз вакытында мин Кабан күленең проблемалары хакында китап язуга гына түгел, ә күлне күп гасырлык ләмнән чистарттыруга да ирештем...

Интернет – менә дигән нәрсә. Әмма һәр нәрсәнеке кебек, аның да тискәре яклары бар. Интернет белән артык мавыгу аңгыралыкка китерә (бигрәк тә балаларда), китап укудан биздерә һәм сәламәтлеккә зыян сала. Бу – утны ачкан кебек. Утта ашарга пешереп, өйне җылытып була, әмма янгында һәлак булуың да бар.

Тормышымда куркыныч хәлләр булды. Сугыш елларында Ленинградтан эвакуацияләнгән вакытта бомбалар астында да калгаладым. Мотороллерымда һәлакәткә дә очрадым... Бандитлар да бер генә тапкыр ябырылмады... Миңа тугыз яшь булганда мәктәптән ташландык җир аркылы кайта идем. Юлда яшүсмер-башкисәрләр очрап, өр-яңа күн башлыгымны салдыр-

Казан шәһәренең 55 нче мәктәбе. Яшь җәлилчеләр белән очрашу.

макчылар. Әмма башлык аяк астына чияләп бәйләнгән, өстәвенә, үзем дә җан көчемә каршылык күрсәттем. Һәм хулиганнар, ачулары килеп, мине күпер астына ыргытты. Мин суга түгел, яр буендагы ләмле пычракка килеп төштем. Шулай исән калдым.

Ун сыйныф тәмамлап, Казан университетына укырга керергә барганда, бабаем миңа мондый нәсихәт бирде: «Улым, тормыш иткәндә кирәк булган өч кагыйдәне исеңдә тот: аракы эчмә, судлашма һәм хатыныңнан аерылма. Аракы эчкән кеше үз язмышына үзе хуҗа түгел, ә аракы колы. Мостафиннар ыруына тап төшермәссең, дип ышанам». Аннан соң ул нәселебездә берәүнең дә хилаф гамәл кылмавын һәм суд юлында йөрмәвен әйтте. Һәм, ахыр килеп, беркайчан да аерылмаска киңәш бирде. «Икенче бер, тагын да яхшырак хатын-кызны таба алырсың, ләкин балаларыңның әниләрен таба алмассың. Безнең ыруда берәү дә беркайчан да аерылмады һәм балаларын ташлап китмәде». Гомерем буена әлеге гади, шул ук вакытта катлаулы кагыйдәләр белән яшәдем.

Балаларның һәм оныкларның барлык борчу-хәсрәтләренә үзеңнекенә караганда күбрәк көенәсең икән. Аларның шатлыклары өчен шатланасың, аларның бәхетләре белән бәхетлесең.

Иң катлаулысы миңа булачак һөнәремне сайлау булды. Мәктәп елларында әле математика, әле астрономия белән мавыктым. «Мәктәптә математика» журналындагы иң катлаулы мәсьәләләрне дә бик җиңел генә чишеп ташлый идем. Баш күтәрми галәм хакында китаплар укыйм. Туганнан туган абыем ул чакта университетның геофагында укый һәм мине дә геолог булырга кодалады. Әмма әдәбият укытучым Андрей Степанович Голубничий мине әдәбият факультетына барырга күндерде. Менә монысын сайлау бик авыр булса да, ул иң дөресе булып чыкты.

Үзем шөгыльләнергә мәҗбүр булган эшләрне яратып башкарырга тырышам. Ул чагында эшләве дә күңеллерәк, һәм эшне мәҗбүр булганлыктан гына эшләгәндәге ару, ачу килү дә юк.

Җирдә казынырга, җиләк-җимеш яисә яшелчә бакчасында эшләргә яратам. Гомумән физик эш эшләү миңа ошый һәм физкультура турында да онытмыйм.

Акча бик кирәкле инде, кием-салым, торак, азык-төлек шикелле. Алардан башка яшәп булмый. Әмма ул үзмаксат була алмый, ә бары тик тормыш итү чарасы гына.

Комарлы уеннардан баш тартам. Ә менә иҗади эштә азартсыз булмый.

Мин компьютерларга кадәрге дәвердә үстем һәм тәрбияләндем. Компьютерны әле дә язу машинкасы сыйфатында гына кулланам.

Холкым белән мин тыныч, төпле, лирикага битараф булмаган кеше, ләкин фәнни мәсьәләләр белән дә һәрдаим кызыксынып торам. Галәмне өйрәнү өлкәсендәге яңалыкларны игътибар белән күзәтәм.

Минем барыннан да битәр ялкаулыктан котыласым килә, вакыт-вакыт аның өянәге кузгалгалый. Телевизорны азрак карарга, буш детективлар укымаска тырышам. Ахыры-чиге булмаган сериалларны бөтенләй дә карамыйм.

Уңыш – ул җәмгыяви танылу. Минем бабам гел кабатларга ярата иде: берәүне йөз кеше мактый икән, ул үзе йөз кешегә тора.

Гомернең кыска булуына уфтанам, уйланганнарның барысын да тормышка ашырып өлгерә алмам, дип куркам».

«ТАТАРСТАН»НЫҢ БАШ МӨХӘРРИРЛӘРЕ

БАБАЙ КАНЫ

– Мин «Татарстан» журналына ялтыравыклы басмалардан килдем һәм башта бу күпләрне сагайта калды. Тик шикләре һич тә юкка иде, тиздән алар моңа үзләре дә инанды. Чөнки Татарстан Республикасы үсеше кебек үк, иҗтимагый-сәяси журналның үсеше дә миңа ят түгел, ни дисәң дә, миндә бабам каны ага. Ә ул – бик билгеле шәхес, республиканы төзегән кешеләрнең берсе. Шамил Әсгать улы Мостаев җаваплы вазыйфалардагы хезмәт юлын Апас районы җитәкчесе буларак башлый, аннары 15 елга якын ТАССРның финанс министры булып эшли, ә 1986 елдан 1990 елга кадәр Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Рәисе була. Шуңа бәйле рәвештә, мин үскән гаиләдә «Татарстан» сүзе республиканы искә алу гына түгел, ә бөтен сәяси вакыйгаларга баштанаяк чумуны белдерә иде. Өйдә дәүләт дәрәҗәсендәге мөһим проблемалар турында гел сөйләшеп-гәпләшеп торалар. Мин шул иҗтимагый-сәяси казанда кайнап үстем…

ЯЛТЫРАВЫК ЖУРНАЛЛАР КЫЗЫ

Мин хезмәт юлымның башында ук дәүләт органнарында – казначылыкта эшли башладым. Аннары маркетинг һәм реклама проектларына киттем һәм нәшрият эшчәнлеге белән таныштым. «Абак-пресс» нәшриятының ялтыравык тышлыклы журналларын чыгардым, «Бизнес и жизнь», «Собака.ru», "Дороже денег" журналлары исә инде төрле кыйммәтләр, битараф булмаган кешеләрне рухландыру, кызыксындыру юнәлешендә дөнья күргән басмаларым иде.

ИҢ *креатив*

Диләрә Байчурина «Татарстан» баш мөхәррирләренең ир-атлардан гыйбарәт нык сафына хатын-кызларга хас ягымлылык элементын кертеп җибәрде. Һәм «Татарстан»ны матур, заманча, ялтырап торган журналга әйләндерде – инглиз сүзе белән әйткәндә, ребрендинг үткәрде. Диләрә ханым басма белән 2009 елдан 2012 елга кадәр җитәкчелек итте.

ЯҢА СУЛЫШ

«Татарстан» журналындагы эшемне аерым бер җылылык белән искә алам. Мине ул чакта «Татмедиа» республика агентлыгы җитәкчесе вазыйфасын башкарган Марат Моратов чакырды һәм журналга ребрендинг үткәрергә тәкъдим итте. Моңа өстәп, «Татмедиа» кул астындагы 90, 80, 70 әр ел чыгып килгән журналларга да – аларның һәркайсы команданы башкача формалаштыруны һәм бүтән ысул-алымнарны таләп итте. Республика тормышын яңа форматта чагылдыру бурычы куелды.

Моңа ирешә алдык. Хәер, искелек белән көрәшмичә генә булмады. «Татарстан» редакциясенә эшкә килгәндә, штат расписаниесенә ул чор өчен искергән һөнәрләр кергән иде: компьютер версткасы операторы, җыючы… Материаллар башта кулдан языла, аннары компьютерда җыела, кәгазьдә корректура ясала һәм тагын компьютерга кертелә… Бу, әлбәттә, эшне катлауландыра, озынга суза. Техникадан алып эш алымнарына кадәр – һәр нәрсәне яңарттык. Мин элеккеге коллективка, безгә кушылып, яңалыкларны бишкуллап кабул итүчеләргә бик рәхмәтле. Күп еллар элек журналның баш мөхәррир вазыйфасын башкарган Рафаэль Әхмәт улы Мостафин беренчеләрдән булып үзен үзгәртергә алынды. Компьютер нигезләрен үзләштерде, яңа формат

таләп иткәнчә яза башлады. Җитди киртәләр булмады, чөнки вакыт ягы бик тыгыз, эшне кичектереп булмый – басмаларга язылу чоры бара. Без беренче номерны ерып чыктык, аннары исә эш җайга салынды. Бөтен процессны яңадан тәртипләп бүлдек, ул технологик яктан яхшырды, тизләнде һәм җайланды. Чыганак материалларга, фотографияләр сыйфатына, басмага тапшыру алды әзерлегенең сыйфатына карата таләпләр яңартылды. Типографиядә беренче номерны бастырган чакта билгеле бер стандартларда эшләргә өйрәндек. Типография станогы янында башыннан ахырына кадәр басып тордым дияргә дә була, һәр сәхифәне – кара нокталарны, манджента төсен оригинал белән чагыштырдым... Төсләр җете, янып-тартып торырга тиеш иде. Тышлыкка карата да таләпләр үзгәрде – һәркемгә якын теманы җәлеп итәрлек итеп ачып бирә торган башисем булырга тиеш. Журнал җитәкчелегенең өстәлендә генә ятып калмасын, аны иң югары вазыйфадагыларның да, кече һәм урта бизнес вәкилләренең дә укыйсы килсен. Журналда уку өчен җиңел язмалар да урын алсын, ләкин алары да җәлеп итеп, үзенә алып кереп китәрлек булсын. Әнә шул рәвешле «Авыллар буйлап сәяхәт» рубрикасы барлыкка килде, бу сәхифәдән баш тартмагансыз, моңа бик шатмын. Шулай итеп, кызыклы проектлар, зур фотографияләр пәйда булды.

2010 ЕЛГЫ ЧИТТӘН ТОРЫП ЭШЛӘҮ

Бу зур үзгәртеп корулар вакыты иде. Барлык техник база гына яңартылып калмады, ә «Татмедиа» бинасы да ремонтланды. Мин ул чорны бөтен яңалыкны актив кертү чоры буларак искә алам. Хәтта редакцияне open space-киңлек (бер зур бүлмә) рәвешендә формалаштыру да яңалык иде. Ул чакта бу – гайре табигый нәрсә, әмма оперативлык өчен бик шәп булды. Кызганыч, махсус верстка программасы «Татарстан»да гына калды. Ул – читтән торып эшләү өчен идеаль формат, бигрәк тә хәзерге шартларда.

Минем фикер сөрешем читтән торып эшләүгә пандемиягә кадәр күпкә алданрак әзер иде, ниндидер бер билгеләнгән вакытка офиска барырга яратмаганыма күрәдер, мөгаен... Әлбәттә, текст язу өчен вакыйга урынына бару таләп ителә, ләкин эшнең зур өлеше, бигрәк тә верстка, өйдә утырган килеш тә бик уңышлы башкарыла.

90 ЕЛЛЫККА ЯШӘРТТЕК

Озын сүзнең кыскасы, 2010 елның декабрендә билгеләп үтелергә тиешле 90 еллыкка без журналны яшәрттек. Аның айпад-версиясе, үз сайты барлыкка килде. Девиз шундый иде: ул картаймый, ул яшәрә, ул һәрчак югарыда. Ягъни ул – республикадагы динамиканы чагылдыра торган журнал. Ә Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов җитәкчелегендәге республикабыз – динамик үсештәге төбәк, шуңа күрә күпләрдән алда бара да.

Хәзер исә, журналист материалларын кабул итүнең төр-вариантлары геометрик прогрессиядә арта башлаган чорда, журналистлар универсаль солдат булырга тиеш. Кеше универсальрәк булган саен, аның һөнәри дәрәҗәсе дә шулкадәр югарырак. Ул глобаль һәм кызыклы текстны ничек итеп кечкенә һәм кызыклы язмага әйләндерергә, социаль челтәрләргә нинди фикерләрне чыгарырга икәнлеген аңларга, ышандыру өчен каядыр һәвәскәр видео да кушып җибәрә белергә тиеш... Журналист чын профессионал икән, ул, лонгрид та, «Твиттер»га куярлык шот та эшли ала. Бу сүзләр фотографларга да кагыла. Һәм минем бурычым әнә шуннан гыйбарәт тә иде – сөрсегән сазлыкны кузгатып, кешеләрне уятып җибәрү.

Ә аны уяту, селкетү бик авыр иде, чөнки барысы да – суперхөрмәтле бөек язучылар. Кабул итү бүлмәмдә андыйлар һәрчак бер кочак утырды. Кемдер бер җитәкче тормышы турында, кемдер үзен дәвалаган табиб турында бөек китап язган һәм башка шуның ишеләр... Менә шул мәшһүр исемнәрнең авыр язмаларыннан котыласы килде. Бер предприятие җитәкчесе яки түрә дә әлеге язучыны кем һәм ничек дәвалавы турында табак-табак текст-отчетларны укырга атлыгып тормый. Журналда текстлар халыкчан, кызыклы, укылышлы булырга тиеш. Баш мөхәррир басманың дәрәҗәсен тотарга, «бу безгә туры килми!» дип әйтә белергә тиеш.

ЯШЬЛЕГЕБЕЗ КОМАНДАСЫ

«Татарстан»дагы үз командамны рәхмәт хисе белән искә алам. Гадел Хәеров мине юмор һәм, өлешчә, экиятилеге белән әсир итте. Лев Жаржевский аз язды, әмма аның материаллары һәрвакыт иң югары дәрәҗәдә иде. Әле тагын Владимир Шевчук та бар иде – теләсә кайсы темага үзенчәлекле караш-фикерле, иң кирәклесен эләктереп ала белә торган якты шәхес. Мин спорт корреспондентыбыз Җәүдәт Абдуллинның тынычлыгына соклана идем. Николай Коновалов әдәби мөхәррир буларак шәп белгеч, тиз отып, тоеп алучан. Юра Николаев мине репортажлык осталыгы, стиленең җиңеллеге, юмор хисе белән әсәрләндерде. Ул бик йорт җанлы булды, чәй янына берәр тәм-том алып килә иде. Журналның татар редакциясе бик ышанычлы булды – Нияз Әхмәдуллин, Фәридә Әхмәтҗанова...

Безнең бер колумнистыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев үзе иде. «Ә чираттагы номерга нәрсә язабыз?» – дип сорый иде ул гел. Әгәр кирәк икән, үз материалын һәрвакыт үзе кыскарта. Һәм һәрчак вакытында тапшырып килде – моның өчен рәхмәт аңа!

Юрий Алаевны яхшы сүзләр белән искә алмый булдыра алмыйм, аны безнең Познер дип атарга да мөмкин иде, шундый ук саллы, затлы... Без бервакыт аның белән Минтимер Шәрипович янына әңгәмә корырга бардык... Хәтерлим әле, Татарстанның беренче Президентына шул чакта: «Хатын-кызның республика президенты булу мөмкинлеге бармы?» – дип сорау бирдем. Журнал өчен түгел, ә болай гына, үзем өчен генә сорадым. «Алла сакласын!» – дип җавап бирде ул. Һәм миңа түтәлләреннән лалә чәчәкләре өзеп бирде – иҗтимагый-сәяси журналдагы хатын-кыз баш мөхәррирнең көндәлек эшендә күңелле мизгелләр әнә шундый.

ТОРМЫШНЫ ЯРАТЫП ЯШӘСӘҢ...

Автор: Мөршидә Кыямова

Татарның атаклы кылкаләм остасы Лотфулла Фәттаховның язмышы күпмедер дәрәҗәдә Михаил Ломоносовныкын хәтерләтә. Унөч яшьлек Лотфулла да белем алу, рәссамлыкка укыр өчен, Сергачтан Казанга җәяүләп килә.

БЕЛЕШМӘ:

Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Лотфулла Фәттахов** 1918 елда Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районындагы Анда авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Аларның нәселе – йомышлы татарлар. Әтисе Габделмән Гражданнар сугышында һәлак була. Әнисе Шаһидә 1926 елгы ачлык вакытында дөнья куя.

Яңа Татар Бистәсенең җиде еллык татар мәктәбендә укый. Аннары Казан сәнгать училищесына укырга керә, анда 5 нче курска кадәр белем ала. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 елдан Татарстан сәнгать фондында эшли башлый. 1960–1968 нче елларда РСФСР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы һәм аның сәркатибе итеп сайлана.

Лотфулла Фәттаховның «В.И. Ленин Татарстан АССРны төзү турындагы декретка кул куя» (Х.Якупов белән бергә) картинасы 1951 елда СССРның Сталин исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Лотфулла Фәттахов көтмәгәндә, 63 яшендә, иҗатының чәчәк аткан чагында, бакыйлыкка күчә. «Язгы буяулар» дигән зур картинаны да язып өлгерә алмый кала. Казанның бер урамы Лотфулла Фәттахов исемен йөртә. Рәссамнар йорты диварында мемориаль такта куелган.

Фотолар гаилә архивыннан

Фәттаховлар гаиләсе (сулдан уңга): Суфия, Рәшит, Фәридә, Шамил, Лотфулла. 1960 ел.

МАКСАТ... КАЗАНГА ИЛТӘ!

Үз-үзеңә ничек юл ярырга, дигәндә, аның тормышын үрнәк итеп китерергә мөмкин. Аягында бау белән бәйләнгән резин галош, аркасында – буш биштәр. Бер тиен акчасыз, таныш булмаган рус, чуваш, татар авыллары аша ул Казанга шактый озак атлый. Ә зур башкалада аның белгән бердәнбер урыны – 13 нче мәктәп кенә. Сигез яшеннән ятим калган малайның бар юанычы рәсем ясау булган бит. Кәгазь юк, шуңа күрә агарткан мич, стеналар да кечкенә рәссамның киндере ролен үтәгән. Күңелендә иҗат чаткылары йөрткән малай кечкенә хикәяләр, шигырьләр язып юанган. Шулардагы образларны сурәт итеп кәгазьгә төшерергә дә маһир булган ул.

Шулай көннәрдән бер көнне аларны Казанда нәшер ителә торган «Пионер каләме» газетасына җибәреп карый. Газета битләрендә үз рәсемнәрен күрү Лотфуллага кыюлык өстәп җибәрә. Үзе кебек иҗатка омтылган татар балаларының 13 нче мәктәптә укулары хакында да ул «Пионер каләме» газетасыннан укып белә. Мәктәпкә укырга алуларын үтенеп хат язган була. Шунлыктан Казанга килгәч тә, Лотфулла туп-туры мәктәпкә юнәлә. Харис Якупов укый торган сыйныфта белем ала башлый. Беренче мәлләрдә аңа сыйныф бүлмәсендә йокларга да рөхсәт бирәләр.

Сыйныфташлары үз истәлекләрендә: «Лотфулла 6 сыйныфта безнең белән укый башлады, аның бернәрсәсе дә юк иде», – дип искә ала. Сөйләмендә мишәр акценты чагылганга, авыл малаеннан көлүчеләр дә табыла. Үсмер Лотфулланың исә, мондый мөнәсәбәткә исе китми, чөнки ул белем алырга, кеше булырга омтыла. Тиздән ул үзенең сыйныфташы – Харис Якупов белән дуслашып, аларның күп балалы гаиләсендә яши башлый. Харисның әти-әнисе Габдрахман белән Маһикамал ятим малай турында белгәч, аны үз гаиләләренә сигезенче кеше итеп алырга карар кыла. Дусларны белемгә омтылыш берләштерә – икесе дә бик яхшы укучылар, рәсем ясау белән мавыгалар һәм рәссам булырга хыялланалар. Харисовларның зур, тату гаиләсендә Лотфулла үзен бәхетле хис итә. Соңрак (сугыштан соң да Лотфулла Фәттахов дусты гаиләсенә кайта – М.К) әлеге дуслык туганлык җепләре белән ныгытыла. Биредә ул кияү дә булып куя. Лотфулланың хатыны Суфия – Харис Якуповның сеңлесе. Алар яшьтән үк ахирәтләр. Тора-бара дуслыктан кайнар хисләр бөреләнә. Гаилә җанлы иптәшен Лотфулла гомер буе ярата. Суфия медицина училищесын тәмамлый, ләкин абыйсы Харис белән Лотфулла аны соңгы имтиханга җибәрмиләр, юлына аркылы төшеп диярлек: «Суфия, сиңа медик булырга ярамый, чөнки тагын сугыш чыга калса, сине фронтка алачаклар, ә анда бик куркыныч!» – дип киңәш бирәләр. Татарстанның баш рәссамы Харис Якупов белән Лотфулла Фәттаховның дуслыгы әнә шул үсмерлек чорыннан башлана. Ике мәшһүр рәссам гомер-гомергә бер-берсенә терәк, аркадаш, фикердәш булып иҗат итәләр.

Лотфулла Фәттахов укыган 13 нче мәктәпнең даны бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Биредә балалар өчен төрле иҗади мөмкинлекләр тудырылган була. Һади Такташ, Фатих Кәрим җитәкләгән шигырь түгәрәкләрендә укучылар сүз тәмен тоярга өйрәнә. Мәктәп укучылары иҗаты балалар басмасында еш яктыртыла. Лотфулла да шушы иҗади мохиткә килеп эләгә. Ә соңыннан рәсем белән җитдирәк шөгыльләнә башлый, шулай да язуын да ташламый. Сирәгрәк булса да, гомер буе яза, төрле аудиторияләрдә чыгыш ясый, тәҗрибәсе белән уртаклаша.

СЫНАУЛАРДА СЫНМАГАН РУХ

1939 елгы фин сугышында Лотфулланың хәрби тормышы башлана. 1940 елның гыйнварында 21 яшьлек Лотфулланы – кече командирлар полк мәктәбе курсантын – 86 нчы укчы дивизиягә озаталар (ул мәктәп Бресттан төньяктарак урнашкан була. – М.К.). Сугышның әүвәлге көннәрендә фашистлар, Лотфулла Фәттахов хезмәт иткән дивизияне – Гродно өлкәсенең Слоним районында «Белосток казаны» буларак мәгълүм урында кысрыклап, камалышка алып, бик хәтәр утка тоталар. Көнбатыш аерым хәрби округының 3 нче, 10 нчы һәм 4 нче армия частьләре дә шушы «казан» аша чыгып котылырга омтыла. Әлеге каты бәрелешләрдә Лотфулла контузияләнеп, дошман кулына эләгә. Өч айга сөйләшү-ишетү сәләтен югалта.

Венгрия. 1945 ел.

«В.И. Ленин Татарстан АССРны төзү турындагы декретка кул куя» (Х.Якупов белән бергә) картинасы. 1951 ел.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрен фронтовик болай дип искә ала торган була: «1941 елның 22 июне ял көне булгач, кәеф яхшы иде. Ләкин аның безнең өчен «канлы якшәмбе»гә әйләнәсен беркем дә белми иде шул. Кичтән волейбол уйнадык, кемдер өенә хат язып утырды. «Николай Щорс» киносын карадык та, дию йокысы белән йоклап киткәнбез. Һич көтмәгәндә полк территориясендә туплар шартлый, снарядлар ярыла башлады. Самолетлар гүләве, бомбаларның үзәк өзгеч чинавы, аларның колак тондыргыч шартлаулары... Бөтен гарнизонны хәрби тревога белән уятып, канлы бәрелеш купты. Без сугыш башланганын белми идек әле. Германия белән СССР арасында килешү төзелгән иде бит! Көнбатыштан һөҗүм иткәч, провокация генәдер дип уйладык. Казармалар, комсостав өйләре дөрләп яна. Сугышчылар арасында паника башланды. Безнең ротадан берничә солдат, винтовкаларыбызны тотып, дөрләп янып яткан арыш кырына килеп чыктык. Төтеннән тын кысыла. Алай да дошман ягына төбәп ут ачтык. Ике көннән немецлар безнең эзгә төште. Алга таба ачы һәм коточкыч көннәр башланды – без әсирлеккә эләккән идек...»

Лотфуллага күп мәртәбәләр солдат иптәшләрен этләр ботарлап-чәйнәп үтергәнен күрергә туры килә. Кайбер әсирләр, газапларга түзә алмыйча, атып үтермәсләрме дип, үзләре үк фашистлар алдына ташлана торган була. «Әти сугыш турында бер дә сөйләргә яратмады һәм хәрби киноларны карамады, – дип искә ала кызы Фәридә Шәрифуллина. – Без, балалар, белән телевизор каршында бер генә тапкыр утырды ул. Очучылар турындагы «Нормандия-Неман» фильмын күрсәткәндә генә».

Мөгаен, газап чиккән солдат чакларын хәтерендә яңартырга теләмәгәндер. Фәридә ханым әлеге фикерне куәтләп, янә бер вакыйганы бәян итте:

– Берзаман овчарка ияртеп безгә энемнең дусты килде. Әти, этне күрүгә, һушын югалтып егылды. Гомер буе овчарка асраган кешеләрне аңламады. «Ничек инде бу явыз эт белән бер өйдә яшәмәк кирәк? Бу овчарка бер секундта кешене тетеп ташларга мөмкин!» – дип әйтә торган иде. Дошман әсирлегендә этләр үзгәнә үткән аның. Рәссамнар безгә җыелып күңелләрен йомшарткан вакытларда гына әти сугыш хатирәләрен искә төшереп алгалый иде. «Лотфулла, син бигрәк ябык инде, азрак тазарырга тырыш», – дигән сүзләренә: «Ә сез нигә соң шундый юаннар?» – дияр иде. «Табигатебез шундый», – дигәннәргә: «Табигатьтән түгел ул, концлагерьга эләккәндә без барыбыз да төрле кешеләр идек, ә инде 2–3 ай узгач, бөтенебез бертөрле булып, 40 килограммга калдык» – дип, тегеләрнең авызын ябып куя. Әти мәрхүм чандыр гәүдәле, озын буйлы кеше иде. Аның һәрвакыт мольберт янында эшләп утырганы истә. Без иртән торганда да, кичен йокларга ятканда да, кулыннан пумаласы төшмәде. Остаханәләр бирелгәч, анда да кичкә хәтле картиналар ясады. «Бер көн дә иҗатсыз узмасын», – дия-дия эшләде, – дип сөйләде Фәридә ханым.

Лотфулла дошман әсирлегендә дүрт ел газап чигә. Тоткыннарны чираттагы хәрби лагерьгә күчергәндә, Фәттахов Ленинград егете Андрей Кучеренко белән качарга карар кыла. Поезд барган шәпкә вагонның агач идәнен сүтеп тимер юл шпалына ятып калалар. Качапоса бара торгач, Франциягә җитеп, Каршылык хәрәкәтенә кушылалар. Сугыш беткәч тә Лотфулла Будапештта хезмәт итә. 1946 елда гына демобизацияләнә. Туган иленә исән-имин кайткач та, совет власте аны колач җәеп каршы алмый, билгеле. Озак еллар сорау алуларга йөртеп, теңкәсенә тияләр. Лотфулланның туган иле каршында гаебе булмагач, сынауларны ул егетләрчә уза. Рәссам сугыш чорында да блокнот, кәгазь кисәкләренә

карандаш белән рәсем төшергәли. Бөек Ватан сугышы беткәннән соң, ясалган беренче картинасы – «Иван Калитин портреты». Картина 1945 елда немец киндерендә Польшада төшерелгән була. Лотфулла Фәттахов аны «сугыштан соң кулым пумала тотуны онытмадымы икән» дип башкарып караган.

Яшь рәссам тыныч тормышта аякка басып иҗат итәрлек көч таба. Аңа зур проектларны да ышанып тапшыралар. Татарстанның 30 еллыгына, мәсәлән, алар Харис Якупов белән «В.И.Ленин Татарстан АССРны төзү турындагы декретка кул куя» дип аталган зур картина иҗат итәләр. Алардан соң гына башка республикаларда да декретка кул куюга багышланган әсәрләр туа башлый. Лотфулла Фәттахов 1950–1980 нче елларда Татарстанның иң дәрәҗәле сәнгать остасы булып таныла. Татар авыллары тормышын чагылдырган көнкүреш жанрындагы, шулай ук тарихи-революцион темаларга караган картиналар, портретлар һәм пейзажлар ясый.

Замандашлары Лотфулланы юмор яратучы, тормышта фәкать позитив кына күрүче буларак искә ала. «Аның белән аралашу бик җиңел иде, ул низаглар ятратмады, тыныч тормышның кадерен белеп, һәрвакыт иҗатта булды», – диләр. Башка рәссамнардан аермалы буларак, үзенең пөхтәлеге белән аерылып торганын да искә алалар. Иҗат әспабларын һәрвакыт чиста, тәртиптә тоткан. Гаиләсендә татар теленең сафлыгын да кайгыртып яшәгән. Хатыны белән алар өч бала үстерәләр. Олы улы Рәшит әтисе сукмагын сайлаган (былтыр ул да бакыйлыкка күчте). Тәрбия мәсьәләләре башлыча Суфия ханым җилкәсендә булса да, Лотфулла ага да балаларының үз телләрен камил дәрәҗәдә белүен таләп иткән.

– Әти белән сөйләшкәндә, бер генә рус сүзе кыстырып җибәрсәң дә, ачулана торган иде. «Мин аңламыйм, татарча әйт!» – дип кисәтә торган булды. Балаларына гына түгел, әниебезгә дә шул таләпне куя. Әни бит – Казан кызы, сөйләменә рус сүзләре кергәләгәндер инде. Тора-бара шулай гадәтләнеп киттек: рус мәктәбендә укысак та, гаиләдә татарча гына сөйләшә идек. Моның өчен әтиемә мең рәхмәтлемен. Әти мәрхүм татарлыкны бик яратты, – ди Фәридә ханым, истәлекләрен яңартып.

Фәридә Шәрифуллина тарихчы-этнограф булып китүендә дә әтисенең роле зур, дип саный. Ата кеше балаларында телгә генә түгел, тарихыбызга карата да мәхәббәт уяткан, татарның шанлы тарихы турында гел бәйнә-бәйнә сөйләгән. Өйләрендә һәрвакыт тарихи китаплар тоткан. Кече улы Шамил журналист һөнәрен сайлый, ул да рәссамның мирасын барлауга зур көч куя. Интернетта әтисенең махсус сәхифәсен алып бара. Алай гына да түгел, Лотфулла агайның туганнарын барлау юнәлешендә дә җиң сызганып эшли. Мәсәлән, әтисенең абыйсы, Бөек Ватан сугышында башын салган Мәкъсинә Фәттаховның Чехословакиядәге каберен эзләп тапкан. Мәкъсинә заманында туган авыллары Анданың иң оста скрипкачысы саналган, авыл туйлары, мәҗлесләр аннан башка һич узмаган. Сугышка кадәр ул Казанга энесе янына да килгәләп йөргән.

«Без, художниклар, кайвакытта мирасыбыз, традицияләребез юк, дип зарланабыз. Чыннан да шулай, ләкин безнең культурабыз зур, әдәбиятыбыз бай. Музыкабызның тарихы бай, гомумән, халкыбызның мәдәнияты бик әүвәлге, ерак гасырларга киткән. Менә шушы культура нигезендә безгә, татар художникларына революциядән соң үсү артык кыен булмады. Сәнгать эшендә җиңеллек булмый инде ул. Сугыш елларыннан соң бөтен Союз күләмендә, аннан соң бөтен федерация күләмендә Татарстанда бик күп күргәзмәләр оештырылды. Татар художниклары, бер милләттән дә калышмыйча, үз эшләрен алып баралар. Күргәзмәләрдә

«Сабан туе». 1957 ел.

«Яңа буралар». 1959 ел.

үзләрен лаеклы таныталар». (Рәссамның Дәүләт радио комитетындагы чыгышыннан, 1967 ел).

ИҖАТ ҮЗӘГЕНДӘ – АВЫЛ

«Рәссам Лотфулла Фәттахов гомеренең күп өлешен Казанда үткәрде, – ди тарихчы, журналист Марат Сәфәров. – Нәкъ менә Казанда аңа иҗади уңыш килә, биредә ул гаилә кора, тугры дуслар таба. Ләкин ул үзенең кече Ватаны – Горький (хәзерге Түбән Новгород) өлкәсенең Сергач районы Анда авылы белән элемтәсен югалтмый: этюдлар ясарга йөри, якын дусты Харис Якуповны кунакка алып кайта, авылдашларының кайгы-хәсрәтләре белән бергә шатлыкларын да уртаклашып яши. Фәттахов Һади Такташның шигъриятен бик тә үз итә торган була. Казанда, заман рухында, ул вакытта Такташ җитәкләгән әдәби түгәрәк төзелә. Түгәрәккә Түбән Новгородтан килгән Лотфулла Фәттахов та йөри. Такташ – бер буын татар яшьләренең кумиры, мишәр диалектында сөйләшкән талантлы егетләрдә ул аеруча зур кызыксыну уяткан».

Халык рәссамы иҗатындагы төп тема – авыл тормышы. Бу – аның иң көчле ягы. Авылга, колхоз кешеләренә багышланган иң яхшы картиналарында авторның җир хезмәтчәннәренә ихтирамы зур икәне күренә. Моны без останың күп кенә әсәрләрендә тоябыз. «Сабан туе», «Тынгысыз яшьлек», «Тургайлар», «Яңа буралар», «Райком секретаре иртәсе», «Юллар-юллар» һ.б. эшләре аны татар авылының җырчысы буларак раслый. Якты, онытылмас «Сабан туе» исә – рәссамның иң матур, шатлыклы, тормыш тантанасын гәүдәләндергән иҗат җимеше була.

Лотфулла Фәттаховның иҗат юнәлешләренең берсе – китап графикасы. Аны әлеге юнәлешкә әдәбиятка хирыслыгы этәргән, күрәсең. Иҗатында балалар темасы да киң урын биләп тора. Аны балалар картиналарын хасиятләп ясаучы тиңсез кылкаләм остасы, диләр. Мөгаен, сабыйлык чорының тәмен тулысынча татый алмаган рәссам шулай балалык елларында җитмәгән ата-ана назын тулыландырырга омтылгандыр. «Бәләкәй булышчы», «Әни күрмәгәндә» һ.б. әсәрләрендә ул шаян балаларны үзенчә җылылык белән сурәтли.

Рәссам чын тормышны күзәтә белүе белән башкалардан аерылып тора да. «Хезмәтем буенча мин бик күп художниклар белән очрашам. Эшләре белән танышам, кайвакыт киңәшләр дә бирергә туры килә. Бүген мин рәсем сәнгате белән кызыксынучы иптәшләргә бер-ике киңәш әйтәсем килә. Үзешчән художникларның, гадәттә, ике ялгышы була: беренчесе, журналда, китапта, открыткада яисә аерым репродукция итеп эшләнгән рәсемне күчереп ясау. Бу зарарлы эш белән күп кеше мавыга. Мәсәлән, Иван Шишкинның урмандагы аю балалары төшерелгән саргаеп беткән открыткасын, үзешчән художник таба да, шуны бик тырышып күчерә. Бу алым сәнгать кешесенең үзенә дә зур зарар китерә. Табигатьнең матурлыгын табигатьтән, тормышның кызыклыгын тормыштан эзләгез! Шуларны кәгазьдә яки киндердә чагылдырырга тырышыгыз». (Дәүләт радио комитетындагы чыгышыннан, 1971 ел).

Шунысы да куанычлы: Фәттаховның нәселе көчле, араларында бабаларының эшен дәвам иттерүчеләр үсә, дизайнерлар да бар. Ә дүртенче сыйныфта укучы оныгы Камиләнең бабасы кебек үк табигать, тормыш матурлыгын тоемлау сәләте үзен нык сиздерә икән. Камиләгә Фәттаховлар зур өмет баглый.

Якташлары һәм күпсанлы туганнары татарның атаклы рәссамын даими искә алып тора. Аның иҗатын һәм мирасын киләчәк буыннарга җиткерү юнәлешендә дә зур эшчәнлек алып баралар. Асия Фәттахова (Лотфулла Фәттаховның абыйсы Абдулланың килене) тырышлыгы белән Анда авылы клубында музей оештырылган. Биредә үз тырышлыгы, таланты аша зур мәртәбәләргә ирешкән кылкаләм остасы хакында этрафлы мәгълүмат тупланган. Төрле җирләрдә сибелеп яшәүче Фәттаховлар 2018 елда, атаклы останың 100 еллыгы уңаеннан, Сабан туе да уздырганнар. Һәркем анда үз хатирәләре белән бүлешкән.

Халык рәссамының иң күп картиналары Сынлы сәнгать музеенда саклана. Балалары Фәридә һәм Шамил

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

Харис Якупов, Россиянең халык рәссамы:
– Лотфулла сугыш башлануга диярлек әсир ителгән. Әле бездә торганда да аны еш кына Черек күлдәге оешмага чакыртып интектерәләр иде… 1950 елны икебез эшләгән әсәребез, Мәскәүдәге күргәзмәдән соң, Сталин премиясенә тәкъдим ителгән булган, ә без аны белмәдек тә. Бер төнне мине Өлкә комитетына чакырттылар. Өлкә комитет секретаре Рәхмәтуллин болай ди: «Менә әле генә партиянең Үзәк Комитеты белән сүз булды, премияне сиңа бирәчәкләр, ә Фәттаховка юк, чөнки ул пленда булган. Син шуңа нәрсә әйтерсең?..» – ди. Мин, күп уйлап тормыйча: «Аңар бирмәсәләр, миңа да бирмәсеннәр», – дип ычкындырдым. Ул, күзләрен шар ачып, миңа карап тора. Шунда кинәт башыма барып җитте: юк сүз әйттем булса кирәк. Чыннан да, әле Сталин исән иде, нинди җүләр шундый зур бүләктән баш тарта, ди?! Ул бит инде республикабызның да сәнгатен тану дигән сүз… Хаҗи Баязитович икенче бүлмәгә кереп китте, кабат Үзәк Комитет кешесе белән сөйләшә башлады. Ярты сәгатьләп сөйләшкәч, елмаеп, чыгып килә. Әүвәл мине тәбрикләде дә, Дәүләт бүләгенең икебезгә дә биреләсен әйтте. Ә теге хәлне мин бер кешегә дә сөйләмәдем, хәтта Лотфуллага да әйтмәдем. Дуслык шулай булырга тиеш, дип уйладым.

РӘССАМ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова, сәнгать белгече:
– Рәссамның югары сәнгать осталыгы аның колоритны нечкә тоемлавында чагыла. Аның эшләрендә төсләр балкышы сокландыра, ул картиналарга форма бирә, идея эчтәлеген тулы итеп ача. Сынлы сәнгать остасының иң күренекле эшләреннән берсе – татар сынлы сәнгатенең алтын фондына кергән «Сабан туе» картинасы. Ул аны 1957 елда иҗат иткән. 1950–1960 нчы елларда татар сынлы сәнгатендәге яңа агым һәм рухи күтәренкелек символы булган «Яңа буралар» картинасы да шундый ук дәрәҗәгә ия. «Сабан туе» картинасында рәссам бәйрәмнең иң мавыктыргыч мизгелен – милли көрәшне тасвирлаган. Көрәшчеләрнең берсе икенчесен җирдән күтәргән, тамашачылар бәйгенең ахырын көтеп тынып калганнар. Картина бәйрәм күтәренкелеген чынбарлыктагыча тулы һәм ышанырлык итеп чагылдыра. Бәйрәмнең үзәгендә – авыл кешеләре һәм кунаклар. Картина персонажларының күтәренке кәефе, халык бәйрәменең тантанасы сиңа да күчә, татар халкының милли бәйрәме өчен сөенеп-горурланып куясың. Типик татар ягы пейзажы Сабан туе символы – сөлгеләр бәйләнгән озын колга белән көчәйтеп җибәрелгән. Әсәрдәге бәйрәм рухын, тантаналы күтәренкелекне табигый чиста төсләр – яшел, зәңгәр, охра, ак җирлектәге кызыл төсләр – тулысынча тасвирлап бирә. Картина төсләргә гимн булып яңгырый, чөнки төсләр байлыгы – татарларның дөньяга сәнгатьчә карашының аерылгысыз бер үзенчәлеге ул.

Шамил Фәттахов, Лотфулла Фәттаховның улы, журналист:
– Әти балык тотарга ярата иде, безне дә гел үзе белән алып йөрде. Иртән балыкка чыгып китәбез, өчебезнең дә кармагы бар. Хәтерлим, беренче балык Рәшит кармагына капты. Әти балыкны Рәшитнең кулына салды, балык Рәшитнең беләгә буе. Әти һәр елны: «Улым, синең беренче балыгың никадәр иде әле?», – дип сорый. Рәшит күрсәтә, беләк үскән саен, балык та ел саен шулай «үсә» бара, ә без көлешәбез… Балыкка барганда, миңа чикерткәләр тотып, шешәгә тутырырга кушалар. Георгий Зяблицев белән балык тотып утыралар бервакыт. Миңа «Лорд – хранитель кузнечиков» дигән исем бирделәр. Аларны кармакка элгәндә, миңа: «Лорд-хранитель, бер чикерткә бирегезче», – дип дәшәләр. Кечкенә малайга күңелле була инде. Әти гаять пөхтә кеше иде. Карандашларны пәкеләр белән очлап утыруы да сәнгать әсәре кебек башкарыла. Очлы карандашларына сокланып карап тора идем.

Рәссамнар арасында бик җылы мөнәсәбәт хөкем сөрде, алар үзара бик тату яши иде. Һәр ел саен әти безне табигатькә алып чыга. Ул вакытта бакчаларыбыз юк әле. Рәссамнар берлегендәге кылкаләм осталарының гаиләләре белән бергә 50–60 кеше җәй көне өч айга табигатькә чыга идек. Баштагы мәлләрдә хәрби палаткаларда яши идек, һәрбер чатырда якынча унлап кеше тора. Иртән балык тоталар, кичен, учак ягып, балык, бәрәңге пешерәбез. Төрле кызыклы хәлләр турында гәп куерталар. Гитара уйнап җырлар башкаралар. Шул чор фотоларын еш карыйм, анда балалар үз әтиәниләре янында түгел, ә башка ата-аналар янында утыра. Коммуна, уртак балалар шикелле. Соңыннан рәссамнар өчен «Крутушка»да агач йортлар төзелде. Һәрбер гаиләгә фанер йорт бирелә башлады. Аннан Кордонга күчтек, берничә ел шунда йөрдек. Монда инде шәп, зур йортлар салдылар. Әти, анда яшәгәндә, балыкка иртәнге 4 тә торып китә торган иде. 7–8 ләргә көймәсенә корбан балыгы тутырып, кайтып та керә. Без ул балыкны бөтен рәссамнарга таратып йөри идек.

Әтине соңгы күрүем хастаханәдә булды. Бик күңелле итеп ярты сәгать төрле темаларга сөйләшеп утырдык. Мин аның яныннан күтәренке рухта «пока» дип чыгып киткән идем…

Үзе исән чагында гаять бай архивын һәрвакыт чистартып, тәртипләп, барлап торган. Берзаман Рәшит белән өйгә кайтып барабыз, чүплек янында буяу белән ясаган таныш картиналары ята, без аларны качырып кына өйгә алып кереп, яшереп куйдык. Әти аларны сыйфатсыз дип ташлаган, ә безгә ул әсәрләр бик яхшы тоелды. (Әти вафат булгач кына яшергән җирдән чыгардык). Үзенә карата бик таләпчән иде шул. Әти дә, әни дә кешеләрдә һәрвакыт яхшы сыйфатларны гына күрә белделәр. Дөньяда начар кеше булмый – алар икесе дә моңа инанган иде…

ИЛДАР ХӘЙРУЛЛИННЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Фото: Лилиана Вәлитова

Автор: Руфия Фазылова

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Илдар Хәйруллин
(1950 елның 6 июнендә Казан шәһәрендә туган) Татарстанның халык артисты, РФның һәм ТАССРның атказанган артисты.

1970 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Татар дәүләт Академия театрында эшли башлый. 1975 елда үзе укыган училищеда актерлык осталыгы буенча дәресләр бирә. Бүген дә остазлык эшен алып бара. Үзен режиссер ролендә дә сынап карый.

Аның рольләре: Таймораз – «Борчылма, әнием» (Н. Думбадзе), Алим – «Әңгер-меңгер» (А. Гыйләҗев), Исмәгыйль – «Диләфрүзгә дүрт кияү», – «Ат карагы», Лауренсио – Григорий «Җүләр кыз» (Лопе де Вега), Таһир – «Мәхәббәтең чын булса» (Х. Вахит), Абдулич – «Һиҗрәт» (Н. Исәнбәт), Шагыйрь – «Моңлы бер җыр», Хәбир – «Сөяркә» (Т. Миңнуллин), Карандышев – «Бирнәсез кыз», Худобаев – «Җимерелгән бәхет» (А. Островский), Кияү – «Кияү белән кәләш» (М. Байҗиев), Ильяс – «Казан сөлгесе», Исмәгыйль – «Сүнгән йолдызлар» (К. Тинчурин), Максим – «Һаваларда йолдыз» (М. Горький буенча), Труффальдино – «Ике хуҗаның хезмәтчесе» (К. Гольдони), Җанбай – «Идегәй» (Ю. Сафиуллин), Карак – «Карак» (З. Хәким), Инсаф – «Әни килде» (Ш. Хөсәенов), Пеппино – «Гаугалы гаилә» (Эд. де Филиппо), Закир – «Мәхәббәт хатирәсе» (Ф. Бүләков), Тамерлан – «Исәнмесез» (М. Гыйләҗев) һ.б.

Йолдызнамәләргә ышанам. Мәсәлән, мин Игезәкләр йолдызлыгында туганмын. Үземдә чынлап та ике кеше яшәгәнен сизәм. Әйтерсең яртыга бүленгәнмен... Үзгәрүчәнлек хас. Миндә генә алай түгел икән, менә, мәсәлән, Фирая Әкбәрова да Игезәкләр йолдызлыгында туган. Ул да, башка коллегаларым да шулай ди. Тагын Игезәкләрне берьюлы өч эшне эшли ала, диләр. Дөрес бу. Мин телевизордан яңалыклар карыйм, пьеса укыйм, шул ук вакытта пьесага конспект та төзи алам. Яки берьюлы өч концерт әзерлим, берничә тапкыр шулай булды.

Тик утыра алмыйм. Ике-өч көн дәвамында, эш кушып шалтыратмасалар, борчылам. «Мин әллә беркемгә дә кирәкмимме соң?» – дип уйлап йөри башлыйм. Эшсез, рольсез тору иҗат кешесе өчен иң авыры...

Безнең һөнәрнең тагын бер тискәре ягы бар – эмоциональ яктан янасың. Шуңа да нервларны саклау бик мөһим.

Минем өчен актерлык һәм остазлык эше аерылгысыз. Бер юнәлешнең ике тармагы ул. Тегендә дә – иҗат, монда да. Укыту сәләте бөтен кешегә дә бирелмәгән, мин шуңа инандым. Күп кеше укытырга алынып карады, ләкин булдыра алмады. Моның сәбәбен төгәл генә әйтү авыр. Яшьләрне тоемларга кирәк, димме. Студентлар белән эшләү рәхәт, анда энергетика алмашы, дәрт ташып тора. Алар арасында булгач, син үзеңне дә тиешле югарылыкта тотарга тырышасың. Алар еш кына: «Илдар абый, болай киенмиләр бит, мондый музыка тыңламыйлар», – дип киңәш тә бирә. Ә мин бүгенге көннең ритмын тоярга телим икән, һичшиксез, аларга колак салырга тиешмен.

Спектакльдә эшләү бүтәнчә, укытуга караганда җиңелрәк кебек тоела. Спектакльнең технологиясе инде репетицияләрдә табылган. Шул юнәлештә уйныйсың. Ә студентларга белем биргәндә, һәр дәрес – яңалык. Алар яныннан җир сөргән кебек арып, талчыгып чыгасың, ләкин рәхәт бер ләззәт тоясың. Әлбәттә, студентлар әзерләнеп килсәләр, бирелеп эшләсәләр. Миңа эшнең нәтиҗәсен күрү зарур.

Театр училищесында беренче курсларны алгач, бер ел дәвамында аларны сәхнәгә чыгып исәнләшергә өйрәтәм. Артист тамашачыны күрергә, тоярга тиеш. Ул бик зур, четерекле эш. Аның үзенең технологиясе бар. Иң мөһиме – каушаудан качарга өйрәтү.

Каушаудан качуның берничә юлы бар. Шуның беренчесе – эчке һәм тышкы ирек булсын, ягъни яшь артистны эчтән бернәрсә дә зынҗырлап тормасын. Тышкы ирек дигәнем – буыннар катмасын, диюем. Аның өчен артист булачак кеше үзенең психологиясе, тәне белән идарә итә белергә тиеш. Артистка үзен тою кирәк: сәхнәдә ничек басып тора, ничек хәрәкәт итә һ.б. Тагын бер бик мөһим нәрсә: яшь артистка игътибарын тупларга кирәк. Мисал өчен, спектакль куясы көнне мин иртәдән шуның белән яшим. Яшьрәк чакта, күп уйнаган вакытта, кичен зур спектакль бар икән, театр училищесында дәресләрне дә кичектерә идем.

Рольгә керү дигәннән. Андый чакта башка энергетика белән яшисең. Моны миңа улым Искәндәр сөйләде. Ул данлыклы «Кара чикмән»дә этне уйнады бит. Зур спектакль, бик бирелеп уйнарга кирәк. Искәндәр әйтә: «Эти, ышанасыңмы, «Кара чикмән»не уйнарга барырга чыкканда, ишек алдындагы этләр минем янга җыела. Һәм мине капкага кадәр озатып баралар. Бүтән көнне алар мине күрми дә. Спектакльдән кайтканда каршы алалар. Мин башта моңа игътибар итмәдем. Кат-кат тикшереп карагач кына инандым». Моның сәбәбе бик гади – Искәндәр ул көнне башка рухта яши, ә этләр – табигать балалары, моны тоя...

> “
>
> – Минем өчен актерлык һәм остазлык эше аерылгысыз. Бер юнәлешнең ике тармагы ул. Тегендә дә – иҗат, монда да. Укыту сәләте бөтен кешегә дә бирелмәгән, мин шуңа инандым. Күп кеше укытырга алынып карады, ләкин булдыра алмады. Моның сәбәбен төгәл генә әйтү авыр. Яшьләрне тоемларга кирәк, димме...

Театр тарихын карасак, Хәлил Әбҗәлилов – Хуҗа Насретдин, Шәүкәт Биктимеров – Әлмәндәр, Равил Шәрәфиев – Әҗәл, ә мин Мырау Батыр булып истә калдым. Мин моңа уңай карыйм, кызык бит. «Мырау Батыр»да уйнау минем өчен зур яңалык иде. Халык белгән әкият, күпсерияле фильм итеп төшерелде. «Мырау Батыр»га кадәр музыкаль телесериал төшерелгәне булмады бит. Ул чакта аның төгәл ничек эшләнәсен берәү дә белми иде. Композитор Рәшит Абдуллин төнлә белән җырларны иҗат итә дә, без аны иртән студиягә килеп тыңлыйбыз. Һәм шунда ук яздырабыз да. Ә уникедән соң, Композиторлар йортына барып, фильм төшерәбез. Бик кызык тәҗрибә булды ул. Үзенә күрә бик бирелеп, шаярып та эшләдек.

Хикмәт тискәре яки уңай рольне уйнауда түгел, хикмәт – драматургиядә.

Студентларны чыгарганда: «Мин сезгә күп яки зур рольләр теләмим, мин сезгә үз режиссерыгызны табуыгызны телим. Сез аңа, ул сезгә ышана торган кеше булсын», – дип әйтәм. Шунда гына иҗат була. Режиссер белән актер бер-берсен тоеп хезмәт итә икән, әйбәт нәтиҗә чыга. Мисалга, уңай рольне алыйк. Матур кыяфәтле, һәйбәт тавышлы артист сәхнәгә чыкты, ди. Ә ул истә калмый. Аның энергетикасы да, харизмасы да юк. Шунда ук тамашачы алдына кечкенә генә, кәкре аяклы артист чыга, аның роле дә зур түгел, тик ул бөтен сәхнәне дер селкетә. Әйтәм бит, хикмәт актерның сәләтендә, аның энергетикасында.

Кеше гел начарлыктан, яки яхшылыктан гына тормый. Константин Станиславский әйткән: «Яхшы кешедә, геройда тискәре сыйфатларны эзлә, ә тискәре кешедә уңай сыйфатларны эзлә». Кеше күпкырлы була. Бу табигатьнең зур бер сере. Карап йөрисең, бик яхшы кебек, аны барысы да мактый. Үзе дә мактана. Ә бервакыт әшәкелек эшли һәм син аның ни дәрәҗәдә пычрак икәнлеген күрәсең. Мисал өчен, исерекләр, тәртипсез тормыш рәвеше алып баручылар бар. Аларны сүгәләр, бөтен начарлыкта гаеплиләр. Ә бит алар арасында да яхшы күңелле, изгелек эшләүчеләр байтак. Тик алар ул турыда кычкырып йөрми. Кызганыч, кешенең эчке дөньясын бар тирәнлегендә аңлап, күреп бетереп булмый.

Марсель Сәлимҗанов кулына мин уналты яшемдә килеп эләктем. Театр училищесына укырга кергәч булды ул. Мин әллә нинди зур шәхесләр белән аралашып үсмәдем. Островский урамында яшәгән гади шәһәр малае идем. Студент булгач, театрга йөри башладык. Шуның белән бергә зур шәхесләрнең өендә дә булырга туры килде. Әлбәттә, аларның иң зурысы Марсель абый иде. Сер түгел, һәр шәкерт үзенең укытучысына мөкиббән була. Аннан курка да, ярата да, хөрмәт тә итә. Миндә дә шулай булды ул. Өстәвенә, Марсель абый бик белемле дә иде, университетның юридик факультетында укыган бит. Атаклы артистлар гаиләсендә тәрбияләнгән кеше буларак та, ул безгә бик күп сабак бирде.

Театр училищесында дүрт ел укыганнан соң, Марсель абый безне театрга эшкә алды. Биш елдан соң ул мине үзенә ассистент итеп укытырга чакырды. Студентларга белем бирергә өйрәтте. Шулай башланган дуслыгыбыз гомергә дәвам итте. Күп еллар буена җәйге ялларны бергә уздырдык. Өйләнгәч, минем гаиләне дә үз канаты астына алды. Алсуны да бик яратты.

«Килька консервасы» ашап, гастрольләргә өчәр көн барырга туры килде. Ләкин ул сәяхәтләр шундый күңелле булып истә калган. Әлеге дә баягы, монда да Марсель абыйның өлеше зур. Уңай шартлар эзләп, беркайчан самолетта очмады. Безнең белән плацкарт вагонда, пешкән күкәй ашап, кызык хәлләр сөйләп бара иде. Ул бит театрда үскән малай. Сугыштан соң булган сәхнә тормышын күргән, татарның атаклы артистлары белән аралашкан кеше. Шуннан соң башкалар да истәлекләре белән уртаклаша башлый, уен-көлке китә. Менә шуңа күрә юлда йөрү бер дә авыр, озын кебек тоелмый иде. Марсель абый рух тудыра белде. Камал театрында традицияләрне саклауда, коллективны туплауда да аның өлеше әйтеп бетергесез зур.

Театрда Марсель абыйга дәвам булырдай кеше табылды. Фәрит Бикчәнтәев Марсель абыйның мәктәбен узган режиссер. Фәриткә Марсель абый юл ачты.

Бездә бит актерлар бик сизгер: хөрмәт булмаса, аны эшләтмәсләр иде. Ә Фәрит ихтирамга лаек. Туры килүен кара: Фәрит тә Марсель абый кебек театрда үскән егет. Аның кухнясын тирәннән белә. Шулай булгач, Камал театрында эстафета дәвам итә.

Туфан абый киткәч, татар драматургиясе саекты. Сәнгатьтә кемгәдер охшарга ярамый, һәр кеше бүтәннәрдән аерылып торырга тиеш. Туфан Миңнуллин шундый иде – бүтәннәрне кабатламады. Дүрт елга бер тапкыр курс чыгарам. Аларга диплом спектакле куйганда, пьесалар эзли башлыйм. Берсе аның – татар классикасы, икенчесе заманча булырга тиеш. Соңгысына мин еш кына Туфан Миңнуллинны сайлыйм. Бөтен татар драматургиясен актарам һәм бер нәтиҗәгә киләм: «Ярый безнең Туфан абыебыз булган икән». Югыйсә алтмышынчы еллардан бирле драматургиябез бик аксар иде. Ул үзенең иҗаты белән безне баеткан һәм бүтән язучыларга да ниндидер этәргеч биргән талантлы каләм иясе.

Өметле бер кеше бар әле – Илгиз Зәйниев. Фәрит укучысы. Һәм ул яшьләргә дөрес юнәлеш бирә.

Студент вакытыннан хәтерлим, кайчан карасаң да, Илгизнең кулында китап булыр иде. Нәрсә укый, дисәм, драматургия икән. Илгиз, Шекспирдан башлап, бөтен пьесаларны укып чыкты. Шул рәвешле драматургиянең нигезен, структурасын аңлады. Ни кызганыч, күп язучылар ул әйберләрне күрергә дә теләми.

Берсендә бер язучы пьеса алып килгән. Укып чыктым.

– Начар, – мин әйтәм.
– Ничек инде начар? – ди.
– Бөтен дөнья драматургиясен укымыйча, яхшы әсәр иҗат итеп булмый, – дим.
– Университетта укыдым, – ди.
– Кемне беләсең? – дим.
– Таҗи Гыйззәт әсәрләрен яхшы беләм...

Ләкин бит Таҗи Гыйззәт Шекспир да, Лопе де Вега да түгел. Ни кызганыч, драматургияне белүебез Таҗи Гыйззәт, Кәрим Тинчуриннарда гына туктала. Алары да, һичшиксез, кирәк, әмма бит дөньяныкын да белү зарур.

“

– Туфан абый киткәч, татар драматургиясе саекты. Сәнгатьтә кемгәдер охшарга ярамый, һәр кеше бүтәннәрдән аерылып торырга тиеш. Туфан Миңнуллин шундый иде – бүтәннәрне кабатламады.

Бала тәрбияләүгә килгәндә... махсус рәвештә шөгыльләндем дия алмыйм. Шунда бергә, өй белән театр арасында кайнаганбыз. Искәндәр сәхнә артында үсте. Шөкер, проблема, борчу китергәнен хәтерләмим. Әдәпле, тыныч бала булды ул. Шулай да миңа ошамаган нәрсәдер эшләсә, бер генә карап ала идем. Кеше алдында баланы сүгеп утырып булмый бит. Ә бездә, артистларда, мимика көчле. Бер карап алу да җитә.

Мин үз-үземә гел тәнкыйть белән карыйм. Шуңа күрә үземне бик әйбәт эти булдым дип әйтә алмыйм. Ничек бар, шулай инде. Аллага шөкер, Искәндәр йөзебезгә кызыллык китермәде.

Дәү әти белән дәү әни оныкларны ярата, иркәли, бу табигый күренеш. Монда да, Аллага шөкер, дим, Искәндәр аларга яхшы йогынты ясый. Миңа караганда да, балаларын әйбәтрәк тәрбияли кебек тоела.

Хәтергә бер вакыйга кереп калды. Искәндәр тәмәке тарта иде. Онықка өч яшьләр тирәсе булгандыр. Карасам, бала кәгазьне түгәрәкләгән дә, тәмәке формасы ясап, аны авызына кабып йөри. Искәндәргә әйтәм: «Күрдеңме, сине кабатлый ул!» Сөбханалла, улым икенче көнне үк тәмәкесен ташлады. Бала тәрбияләгәндә күп сүз кирәк түгел, ул синең арттан иярә генә.

Тәрбия исәнләшүдән башлана. Мин студентларны сүкмим. Алар бит әле күпне белми, бүтән дөньядан киләләр. Беренче дәрестә әдәп-әхлак турында сөйлим. «Училищега килеп кергәч тә, иң беренче эш итеп, исәнләшегез. Кеше белән сөйләшкәндә елмаеп сөйләшегез», – дим. Мин хәтта үзем укытмаган студентларны да исәнләшергә өйрәтәм. Мисал өчен, рус төркемнәрендә укучылар янәшәдән исәнләшми узып китә. Алар янына киләм дә: «Исәнмесез», – дим. «Ә без сезне белмибез», – диләр. «Ә сез монда чит кешеләр йөри дип уйлыйсызмы?» – дим. Шуннан соң минем белән әллә кайдан күреп исәнләшә башлыйлар.

Унике ел «Татар җыры»н сәхнәгә куйдым. Марат Гәрәев чакыргач, бу эшкә бик кызыксынып, яратып алынган идем. Баштарак юнәлешен эзләдек, фикер алышулар, эзләнүләр күп булды. Өч тапкыр минем белән хушлаштылар, өчесендә дә яңадан чакыртып алдылар. Әйбәт эшләдек дип саныйм. Иң мөһиме – без аның драматургиясен таптык. Ә аннан соң... бертөрлелектән качу булдымы, туеп китүме, проекттан баш тарттым. Узган ел фестивальнең егерме еллыгын оештырганда, бүләк бирергә мине дә чакырдылар. Сәхнәдән карап утырганда бер фикер туды: «Татар җыры» җыр бәйрәме булудан туктады. Гадәти концертка кайтып калды.

Еш кына әйтәм: «Ни өчен эстрада концертларыннан шедеврлар көтәсез?» Яңалык түгел бит – эстрада җиңел жанр. Мисал өчен, кичен кәефем начар иде, җиңел генә музыка тыңларга дип концертка килдем. Проблема вакытлыча онытылып торды. Әгәр җитди җырлар тыңлыйсың килсә, романс кичәсенә бар. Әнә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе елына ничә шундый концерт оештыра. Әгәр дә татар халык җырларына ихтыяҗ бар икән, Айдар Фәйзрахмановның фольклор группасы чыгышын карарга кил. Без бит азык-төлек кибетенә кергәч, казылык алганда, башта аның этикеткасын карыйбыз. Концерт белән дә шул хәл, тамашачы башта афишаны укысын. Җырчы ошамаса, бармасын гына. Барысы да эстрада артистларын сүгә, ә заллар тулы бит. Дәррәү кубып алкышлап утыралар. Кайтканда... шуны сүгәләр. Начар булгач, залдан чык та кит. Белдер үзеңнең ризасызлыгыңны! Ник болай булды, дип уйлансын артист! Җырчылар әллә кайдан килми, алар җәмгыятьнең бүгенге халәтен күрсәтә. Әгәр дә бүген Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Сәхәбиев кебек җырчылар юк икән, димәк, андыйларга ихтыяҗ юк.

Мин үзем классик карашлы, кешеләр арасында булган гадәти мөнәсәбәтләрне яратам. Шул исәптән театрда да.

Бүгенге яшьләр фантастик элементлар булган мифологик театрга басым ясый. Ни өчен шулай соң? Беренчедән, юньле драматургия, пьеса юк. Икенчедән, куюы җиңелрәк. Анда күп әйбер аңлашылмый. Алар өчен эчтәлек түгел, форма беренче урында. Русларда да Европага ияру, үзебезнең классик театрдан китү күзәтелә. «Эх-хе... Ой!!!» – дия-дия, сәхнәдә сикерәләр. Аның бит мәгънәсе юк. Берәү кулларын болгап, караңгылыктан килеп чыкты, ул да түгел икенчесе атылып чыкты... Мондый спектакльгә басым ясаучыларның максаты – кешечә булмасын. Мин моның серен яшь режиссерлардан сораганым бар. «Яңа сурәтләү чараларын эзлим», – диләр. Соң, җаныем, син башта искеләрен өйрән, аларны аңла. Аннан соң, үзеңнең таләбең буенча, яңа формалар эзләрсең. Мисалга, музыка сәнгатен алыйк. Музыкант эшне ноталар өйрәнүдән башлый, аннан кечкенә пьесалар уйнап карый. Шуннан соң классикага күчә. Һәм аннан соң гына джазга, симфониягә китә.

Кеше татар телендә сөйләшсен өчен, әти-әнисенең татар телендә сөйләгәнен ишетеп үсәргә тиеш. Әби-бабасының да аның белән татарча сөйләшүе мәҗбүри. Сөйләшү генә түгел, бала милли рухта тәрбияләнергә тиеш. Эш бу кыйммәтләрне аңлатудан башлана. Ә без иренәбез. Еш кына ата-аналар: «Бакчада яки мәктәптә рус телендә сөйләшәләр бит», – диләр. Ярар, анда сөйләшсеннәр. Тик, өйгә кайткач та, ата-ана баласын төзәтми, чөнки иренә. Ата-ана өйдә татарча сөйләшүне төп таләп итеп куйса, бала ана телен беләчәк!

Болай булсак, әдәбиятыбыз белән ни булып бетәр соң? Мисал өчен, язучыны алыйк. Аңа филология кануннарын белмичә ярамый. Аларны белми торып ничек язсын ул? Ә болар мәктәптә, югары уку йортында укытылмаса, аны каян беләсең? Егерме, утыз елдан кем безгә яңа әсәрләр язар?! Дөресен әйтим, бүгенге вазгыять уйландыра, куркыта...

“

– Еш кына әйтәм: «Ни өчен эстрада концертларыннан шедеврлар көтәсез?» Яңалык түгел бит – эстрада җиңел жанр. Мисал өчен, кичен кәефем начар иде, җиңел генә музыка тыңларга дип концертка килдем. Проблема вакытлыча онытылып торды. Әгәр җитди җырлар тыңлыйсың килсә, романс кичәсенә бар.

70 яшьтә дә егетләр егәрлеге сизәм. Моның сәбәбе – тискәре энергетиканы үземә алмау. Әйе, үпкәлисең дә, рәнҗисең дә. Тик аннан соң кул селтим: «Әй, кадалып китсен», – дим. Үземне эчтән ашамыйм, бу яктан бәхетлемен. Тормыш иптәшем Алсу да мине шушы сыйфатым өчен мактый.

Яшәү рәвешенә килгәндә, сигез ел инде көн саен йөзәм. Хәтта спектакль беткәч тә ашыга-ашыга бассейнга барам. Башта әле йөгерә идем дә, хәзер авыррак була башлады. Йөзү шулхәтле рәхәт, су бөтен аруны, начар энергетиканы ала. Моны мин генә түгел, белгечләр дә әйтә. Йөзгәндә кеше уйламый, барлык проблемалары читләшеп тора икән. Шул рәвешле организм тулысынча тернәкләнә.

Яраткан һөнәрем, гаиләм – барысы да яшәү көче бирә, Аллага шөкер!

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘРҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

**Безнең Инстаграмда –
«Татарстан»ның йөрәге!**

Мәңгелек кыйммәтләр/

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Тәтеш музеенда **ни өчен** кызыклы тарихлар күп

Бер якташ **ничек** икенче якташының музеен төзегән

Музейдагы мәхәббәт тарихлары **ничек** яңара

Россиядә беренче мөфти **кем** булган

Югалып баручы авыллар **кай** яклары белән үзләренә тарта

Каракитә авылы **ничек** яши

Автор: Михаил Рябинин

1941–1945 НЧЕ ЕЛЛАРДАГЫ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ МУЗЕЙ-МЕМОРИАЛЫ

ИҢ БӨЕК

Кара репродуктор-тәлинкә, «Ватан-Ана чакыра!» дигән җанөшеткеч плакат һәм Левитанның боздай салкын тавышы. Аны ишеткәч, бүген дә каз тәннәре чыга: «Советлар Союзы гражданнары! Бүген иртәнге сәгать 4 тә, сугыш игълан итмичә, Германия кораллы көчләре Советлар Союзы чикләренә һөҗүм ясады. Совет халкының немец-фашист илбасарларына каршы Бөек Ватан сугышы башланды...»

Музей залларында тупланган предметлар, документлар, сугыш чоры фотографияләре, баксаң, зур тәэсир итү көченә сәләтле икән. Көтмәгәндә, син гомереңһәм үлемең бер сүз – сугыш белән генә билгеләнгән кансыз заманга эләгәсең. Нәкъ шул вакыт турында соңыннан шагыйрь: «Ярды җаннарга тирән яра кырып, кертте меңнәрне вакытсыз гүрләргә, үтсә дә егерме ел, утыз, кырык, исәннәр ышанмый үзләре исән икәнгә...»

ҺӘР ИКЕНЧЕ КЕШЕ ӘЙЛӘНЕП КАЙТМАДЫ

Снарядлар сызгыруы, бомбалар шартлавы, сугыш гөрелтесе... Яктылык һәм тавыш эффектлары белән тулыландырылган образлы-сәнгати музей композицияләре татарстанлыларның Бөек Ватан сугышы фронтларында ничек көрәшүе турында сөйли. Ә зур диварда – фаҗигале югалтулар картасы. 1941 елда башкаланы яклаганда, 1943 елда Сталинградны саклаганда, 1943 елда Курск дугасында сугышканда, Украинаның уң як яр буен азат иткәндә, Берлинга һөҗүм иткәндә күпме якташыбыз башын салганын күрсәткән аяусыз саннар. Фронтка киткән җиде йөз мең татарстанлының яртысы гына өйләренә әйләнеп кайта...

Аяныч статистика бу сугышта җиңүнең илгә нинди югалтулар бәрабәренә бирелүен барыннан да яхшырак аңлата. Янәшә экспозициядә, сугышның бер нәтиҗәсе буларак, Рейхстаг өстенә кадалган Җиңү байрагының күчермәсе урын алган. Шунда ук – 146 нчы укчы дивизиясенең 608 нче укчы полкы байрагы. Казанда оешкан бу дивизия Берлин штурмында катнаша.

Музей раритетлары арасында 1945 елның 9 маенда Казанда бәйрәм итүне чагылдырган уникаль фоторәсемнәр дә бар. Сурәтләрдә – Бауман урамында бәйрәм итүче халык төркеме, әйләнә-әйләнә биюче парлар, бәхеттән балкып торган һәм үкси-үкси елап шешенгән йөзләр. Шатлык-тантана һәм күз яшьләре, сөенеч һәм хәсрәт – барысы бергә...

ТЫЛДА – СУГЫШТАГЫ КЕБЕК

Атаклы төнге У-2 бомбардировщиклары, пикега керергә сәләтле Пе-2 бомбардировщиклары һәм бронекатерлар, снарядлар, мәңгелек солдат «кирзач»лары – безнекеләрнең аягында Берлинга кадәр барып җиткән итекләр... Болар барысы да һәм тагын башка бик күп нәрсәләр сугыш елларында Татарстанда эшләнә. «Тылфронт» экспозициясе шул хакта сөйли. Хатын-кызлар-

БЕЛЕШМӘ:
Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы Казан Кремлендә 2005 елда Җиңүнең 60 еллыгына ачылды. Экспозициядә ТР Милли музее, «Кар десанты» һәм «Ватан» оешмалары, «Хәтер китабы» редакциясе, Бөек Ватан сугышы ветераннарының республика оешмалары коллекцияләре тәкъдим ителә. Сугышта катнашучыларның шәхси архивларыннан тупланган ядкәрләр музейның нигезен тәшкил итә.

ның, әниләрнең һәм балаларның батырлыгы турында ул. Тәүлекләр буе хәрби заводларда станоклар артында басып торган, икмәк үстергән, танк колонналары һәм авиаэскадрильяләр ясауга соңгы акчаларын биргән ярымач каһарман хатын-кызлар хакында. Янә саннар: сугыш вакытында Татарстанга 70 тән артык предприятие эвакуацияләнә, алар фронт өчен 600 дән артык төр продукция җитештерә.

Сугыш елларында Бөек Җиңү өчен Казанда мәшһүр галимнәребез дә хезмәт куя әле. Физик Игорь Курчатов биредә танк бронясын саклауның яңа ысулларын эшли һәм асылда атом-төш проектын гамәлгә ашыруга керешә. Космик корабларның булачак баш конструкторы Сергей Королев арестантлар «алачыгы» нда бомбардировщиклар өчен ракета тизләткечләрен ясый һәм сыный. Физик Петр Капица, химик Александр Арбузов, хирург Александр Вишневский... – аларның Казанда ясаган ачышлары һәм тикшеренүләре Җиңүне якынайта.

МӘҢГЕЛЕК КАҺАРМАННАР

Музей экспозициясенең иң дулкынландыргыч өлеше – ул, әлбәттә, якташларыбыз турында бәян кылганнары, кеше язмышлары турында сөйләгәннәре. Кечкенә Ләйләнең, бераз язарга өйрәнүгә үк, фронттагы әтисенә басма хәрефләр белән хат сырлаган кәгазь кисәген күргәч, тамакка төер тыгыла, күзләргә яшь килә. Хат сакланып калган, ә кыз әтисе белән очраша алмаган. Танылган татар шагыйре, саперлар взводы командиры Фатих Кәрим 1945 елның 19 февралендә Кенигсберг тирәләрендә һәлак була.

Ә Советлар Союзы Герое Михаил Девятаевка багышланган экспозиция үлемгә хөкем ителгән тоткыннарның Узедом утравындагы яшерен ракета базасыннан немец самолетын урлап качып китүләре турында гына түгел, асылда. Легендар очучыга гаделлек өчен никадәр озак вакыт көрәшергә туры килүе хакында да. Ничәмә-ничә дошман самолетын бәреп төшергән, үлем лагере аша узган каһарманны, әсирлектә булу сәбәпле, беркая да эшкә алмаулары һәм хәтта хыянәтче ярлыгы тагып куярга маташулары турындагы хакыйкатьне дә ачып бирә ул күргәзмә...

Тагын бер экспозиция – һәм янә бөек батырлык, фаҗигале язмыш. Бу – Брест крепостенең соңгы саклаучысы, Әлбәден авылында туып-үскән Советлар Союзы Герое Петр Гаврилов тарихы. «Аны әсирлеккә алган һәм лагерьга алып кайткан немец солдатлары, бер сәгать элек крепостьның бер казематында тәнендә җан әсәре генә калган бу кешегә юлыккач, аның ялгыз килеш сугышка күтәрелгәнен, гранаталар ыргытканын, пистолеттан атканын, шул рәвешле берничә гитлерчыны үтергәнен һәм яралаганын табибларга сөйләп бирә», – Петр Гавриловның ничек әсирлеккә эләгүе турында табибларның әнә шундый документаль истәлекләре Сергей Смирновның «Брест крепосте» китабында китерелә...

Музейның «Якташ геройларыбыз йолдызлыгы» залында символик «Каһарманнар стенасы» бар. Анда татарстанлы 185 Советлар Союзы Героеның фотосурәте куелган. Һәркемнең язмышы – батырлык һәм үз-үзеңне корбан итү үрнәге. ■

ТӨСЛӘРГӘ ИҢ БАЙ

Автор: Алсу Троицкая

МӨСЛИМНЕҢ ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ

Һәр туган якны өйрәнү музееның үз төсмере, үзенчәлеге бар. Мөслимдә гореф-гадәтләргә, миллилеккә басым ясала...

Бүген аның экспозицияләре мирасханәнең үзендә һәм район мәдәният йортында урнашкан. Безне **Венера Мирхаҗиянова** музейда каршы ала, сәяхәтебезне башлыйбыз. Экскурсовод Мөслим төбәгендәге археологик тикшеренүләр турында сөйли. Җирдә казынсаң, ни генә тапмассың! Ә казу эшләре урынына эләксәң, кайчандыр, бәлки, нәкъ менә синең ата-бабаларың утырган ташларны капшап-тотып карый аласың... Шуңа күрә дә, 2015 елда туган якны өйрәнү белән бәйле тарихи тикшеренүләрдә катнашырга теләгән җирле халыкның иге-чиге булмый. Ул вакытта бирегә Татарстан Фәннәр академиясе Тарих институтының Альберт Борһанов җитәкчелегендәге фәнни отряды килә. Бу тикшеренүләр беренче тапкыр гына түгел, бирердә казу эшләре 70 нче елларда да алып барыла, ләкин шулкадәр киң колачлы булмыйлар.

— Районда таш, бронза чор, тимер дәвер башларыннан алып урта гасыр ахырларына кадәр караган уннарча объект табыла, — дип дәвам итә Венера Мирхаҗиева. — Алар, нигездә, Ык елгасы һәм аның кушылдыклары бассейнында урнашкан. Борынгы торакларның эзләренә Рус Шуганы, Олы Чакмак, Мәҗын, Табын, Мәллләтамак, Тәмьян авыллары янында юлыгалар... Су юлын гел үзгәртеп, Ык борынгы урдалар, каберлекләр, курганнар һәм шәһәрчекләрнең калдыкларын җимерә һәм юып алып китә. Җирле халык еш кына тимер, балчык, сөяк һәм таштан ясалган төрле кабатланмас әйберләрне хәзерге көнгә кадәр табып тора. Аларның бер өлешен мөслимлеләр безнең коллекциягә тапшыра.

— Ә болар барысы да — урман-кырларда һәм тауларда яши торган җанварлар. Сүз уңаеннан, бүген безнең якларда кабаннар күп яши. Ә менә аюларны инде очратуыбыз икеле, — дип елмая гидыбыз һәм табигать залы буйлап экскурсияне тәмамлый да безне этнография экспо-

зициясенә дәшә. — Шул безнең музейда булса гына инде. Аның каравы, бурсык, төлке, куян, кондызлар һәм төрле кош-корт күп…

МОНДА БАРЫСЫ ДА ҮЗЕНЧӘ, АЕРЫЛЫП ТОРА

Музейчылар әйтүенчә, мөслимлеләрнең кабатланмас чигү техникасы бар. Аңа әнә шул рәвешле «Мөслим каракатицасы» дигән исем дә бирелгән. Андый бизәк белән чигелгән әйберләр күркәмрәк килеп чыга, монысы — бәхәссез. Бу төбәк йортларының борынгы бизәлешендә үзенчәлекле чигүләр күзгә бәрелеп торган урында булган. Туган якны өйрәнү музеендагы пәрдәләргә, мендәрләргә, япма-җәймәләргә бүген дә җирле осталарның тамбур җөе белән чигелгән җете бизәкләре төшерелгән. Ә кунакчыл татар йортында, гадәт буенча, табынны самавыр, чәкчәк, өчпочмак һәм бәлеш бизи.

Күбрәк яшьләрне кызыксындыра торган почмак та бар биредә. Ул никах тәртипләре, гаилә традицияләре һәм канунннары турында сөйли.

— Безнең якларда үзенчәлекле йола бар иде. Туй алдыннан кәләш үзенең дус кызлары белән җыелып, бергә бирнә сандыгы тутыра, — ди Венера Мирхаҗиянова. — Ә бу бирнәне әни кеше яңа туган кызына 40 көн тулуга ук җыя башлый торган була. Күз алдыгызга китерегез әле, кайгыртучан әни бу вакыт эчендә бирнә сандыгына күпме әйбер җыя алган икән?

ТАЛАНТЛАР МУЗЕЕ

Туган якны өйрәнү музее фондларында барлыгы җиде меңгә якын экспонат саклана. Мөслимнең соңгы еллардагы үсеш-үзгәреше турында музейның ике яңа залы сөйли, ә мирасханәнең мәдәният йортындагы филиалына әдәби-музыкаль салон дигән бәяләмә бик туры килә. Биредә язучылар, шагыйрьләр һәм музыкантлар белән очрашулар уза. Төп ният — җирле әдипләр, шагыйрьләр, журналистлар, музыкантлар һәм актерлар тормышындагы иң әһәмиятле мизгелләрне картиналар, фотографияләр, документлар, хатлар рәвешендә туплау… Аларның барысы да ияләре тарафыннан музейга иң кыйммәтле ядкәр буларак бүләк ителгән.

Мәдәният йортының беренче катында — искиткеч манзара. Кешеләрнең һәм хайваннарның агач сыннары шулкадәр тере сыман! Менә биш улын югалтып, елаудан сукырайган ана йөзе. Шултиклем тәэсирләнәсең ки, тамакка төер утыра, күз яшьләрен тыеп тору кыенлаша. Сүз уңаеннан, автор — Илисәй Имамовның иң яраткан эшләреннән берсе ул. Сынчы үзе яши торган Баланлы авылы үзәгендә күкрәгенә кыз баланы кысып кочкан совет солдатына һәйкәл куелган. Монысы да — аның эше. Әллә ничә дистә ел машина йөртүче булып эшләгән һәм гап-гади агачтан шундый шедеврлар уеп ясый торган кешене асылташ дими ни дисең!

Гомумән, Мөслим җире талантларга бай. Сугыш вакытында җырлары белән солдатларны елата торган булган Зифа Басыйрова. Халык арасында Мөслим Шолоховы дип аталган Фоат Садриев. 70 нче елларда «академик хор» исеменә лаек булган бердәнбер авыл хоры… Болар барысы да, чын мәгънәсендә, Мөслим төбәге музее. Һәм аның үзенчәлекле бай төсләре…

АПТЕКА ТЕТЮШСКАГО ЗЕМСТВА
КАЗАНСКОЙ ГУБЕРНІИ

Автор: Катерина Котова

ТӘТЕШ ТӨБӘГЕ ТАРИХЫ МУЗЕЕ

ИҢ STORY*-СЛЫ

Тәтеш төбәге тарихы музеена быел йөз яшь. Безнең журналыбызның яшьтәше! Әмма безне әле яшьтәш булуыбыз гына туганлаштырмый. Әлеге музей тарих тулы сандык икән. Мондый тупланма белән башкала музейларының да бик азы гына мактана ала! Сезне кызыктырыр өчен, шуларның берничәсен тәкъдим итәбез.

ГОМЕРЛӘРЕ ӨЧЕН БУРЫЧЛЫ

Чума, ваба, чәчәк, тиф – узган гасыр башында илдә бөтен җирдә эпидемияләр котырынган. Тәтеш боларның барысы аша да узган, барысын да җиңгән! Күп очракта җирле энтузиаст-табиблар, медицина даһилары тырышлыгы белән. Аларга багышланган музей экспозициясендә шул чактагы медицина кораллары, авыруларның карточкалары, дәвалаучыларның һәм үзе дә шуларның берсе булган Тәтеш өяз хастаханәсе мөдире Аркадий Михайлович Боголюбовның шәхси әйберләре саклана. Ул ярты гасырдан артык кизүләргә каршы көрәшкән, профилактика белән шөгыльләнгән, хирургия һәм офтальмологияне үстергән.

– Күз алдыгызга китерегез әле, нинди шартларда эшләргә туры килгән бит аларга: коточкыч юлсызлык, үтеп булмаслык Тәтеш балчыгы – авыру янына атта алып китсәләр, бәхет саналган, – дип сөйли музей директоры Наталья Понедельникова. – Ул замандагы эпидемиология белешмәләреннән күренгәнчә, кизү кызган мәлдә авылларда үлем-китем атнасына өчәр йөз кешегә җиткән!

Боголюбов Казан губернасында беренчеләрдән булып трахомага каршы көрәшә башлаган. Сүз уңаеннан, сукырайта торган әлеге чиргә бәйле вазгыять Тәтеш өязендә аеруча кискен булган. Сәбәбе – көнкүреш шартларының начарлыгы һәм ачлы-туклы яшәү. XIX гасыр азагындагы табиб язмаларыннан мондый юлларны укырга була: тизәк белән ягыла торган йортларда тончыктыргыч ис, кысанлык, кешеләр һәм хайваннар бер бинада яши, өстәлләр һәм савыт-саба юк... Җитмәсә, табибларга ышанмаганнар һәм еш кына дәваланудан баш тартканнар, янәсе, «докторлар бернәрсә дә белми һәм шундый дару бирергә мөмкин, аңардан бернинди вабасыз да үлеп китәчәксең».

Ә хәзер күз алдыгызга китерегез – 1908 ел, Боголюбов җитәкчелегендә бер төркем медик авылга офтальмологик ярдәм күрсәтергә китә. Өч ай буена эшлиләр. Кыр шартларында. Пациентлар саны мең ярымнан арта! Боголюбов һәм аның командасы мондый командировкаларга күп тапкырлар барачак әле. Аның даны Мәскәүдән алып Әстерханга кадәр таралачак – уникаль операцияләр ясаячак ул. «Безнең бөтен гаиләбез гомере өчен аңа бурычлы» – әлеге гаҗәеп табиб турында шундый хатирәләр бихисап.

Фото: Олеся Бондаревская

* Story – инглизчәдән «тарих» дип тәрҗемә ителә.

ТАБИБ СОКОЛОВЛАР ур.
ул. ВРАЧЕЙ СОКОЛОВЫХ

КУ...

1923 елгы фотосурәттә ул... Максим Галкинны хәтерләтә. Бераз көлемсерәп карый торган күзләр, маңгаенда – чәч бөдрәләре. Һәм ике сатирикның охшашлыгы шуның белән бетә бугай. Михаил Куприянов – карикатурачы рәссамнарның «Кукрыниксылар» легендар берләшмәсеннән беренче КУ – глобаль фигура. Ленин, Дәүләт һәм биш тапкыр Сталин премиясе лауреаты – әйе, бу ул. Балачагында дуслары белән су коенган, кояшта кызынган һәм – әлбәттә инде! – балык тоткан Идел дә шул. Су аның стихиясенә әйләнә, һәм бу аның соңгы картиналарында ачык күренәчәк.

Беренче тапкыр уңыш казанганда Миша Куприяновка нибары уналты яшь була. Туган Тәтешендә уза бу вакыйга. Ул чакта аның акварель пейзажы үзешчән рәссамнар күргәзмәсендә беренче урынны ала. Аннары ул ачлыктан «кача» – товар поезды түбәсендә дә, пароход эскәмиясе астында да билетсыз килеш озын юл үтә. Ташкенттагы рәсем остаханәсенә илткән әлеге «бөек» юл аның өчен тормыш мәктәбенә әйләнә, хәер, анда күңелле чаклар да, гомер буе искә алырлык вакыйгалар да шактый була. Соңрак ул юлда ясаган рәсемнәрен ВХУТЕИН (Югары сәнгать-техника институты) мөгаллимнәренә күрсәтәчәк һәм укырга имтиханнарсыз кабул ителәчәк. Нәкъ менә шунда үзенең «гомерлек» дуслары – икенче КРЫ (Порфирий Крылов) һәм өченче НИКС (Николай Смирнов) белән танышачак. Алар алтмыш елдан артыграк бергә эшләячәк һәм иң кискен темаларга үзләренең коллектив сәнгать җәүһәрләрен тудырачак – совет шәһәрләрен фашистлардан азат итү булсынмы ул, Нюрнберг процессы яки салкын сугышмы. Хәер, Куприянов иҗатының башка ягы да була – лирик пейзажлар яза ул. Аларда исә әллә нигә бер булса да Идел дә, Тәтешнең калкулыклы ярлары да чагылып киткәли.

«БӨГЕЛМИ ТОРГАН ЗАТЛАР БУЛА...»

«Үземнең мәдәни азчылыктан булуым хакында борчулы идея миндә көне-төне физик хезмәткә чумган һәм цивилизация казанышларыннан мәхрүм ителгән затларга карата җаваплы булуым турындагы фикерне уята иде» – дворяннар нәселеннән чыккан атаклы революционер, террорчы, эсер, император Александр II гә каршы оештырылган кыю һөҗүмдә катнашучы Вера Фигнер үзенең суд процессындагы чыгышын шулай башлый. Аның ватаны – Тәтеш өязенең Никифорово авылы. Музейда аңа тулы бер стенд багышланган.

– Вера Фигнер – каршылыклы шәхес. Әмма без сәясәт турында түгел, кешелеклелек хакында сөйләшәбез! – дип басым ясый Наталья Понедельникова. – Уйлап кына карагыз әле: дворян гаиләсендә яшәү, чит илдә менә дигән медицина белеме алу – аңа бөтен юллар ачык! – һәм кинәт үлемгә барырга карар кылу. Әйе, ул моны бик яхшы аңлап эшләгән!

Бар уңайлыклары булган тормыштан үз теләгең белән баш тарту, язмышыңны кешеләргә багышлау – шулай ук фәлсәфә. «Бөгелми торган затлар була, аларны сындырып, үтереп кенә була, тик җиргә иеп булмый», – дип язган аның турында публицист һәм революционер Сергей Иванов. Бик гүзәл Фигнерны әле тагын «Верочка – Топни ножкой» дип тә йөрткәннәр. Әйе-әйе, бу да аның холеннән килгән. Үз идеалларына ихластан ышанган «сокландыргыч агитатор» Вера искиткеч инандыру куәтенә дә ия булган.

Александр II не үтерү хакындагы хәбәр Вераны куандыра. Шул көнне ул: «Бу минут, без түккән патша каны бөтен нәрсәне аклый, безнең иңнәрдән авыр йөк төште, реакция бетәргә, Россия яңара башларга тиеш иде», – дип язып куячак. Һәм менә ул, бөтен гаеплеләр арасыннан тотылмый калган бердәнбер кеше, үзенең дусларын җәзалап үтергән көнне шуны хозур кылган халык белән күзгә-күз очраша. Һәм бу гавам йөзендә «бернинди уйлану да, хәсрәтләнү чаткыларын да» күрми...

Ә соңыннан аны кулга алачаклар. Алда – егерме елга сузылган тоткынлык һәм өметсезлек: «Без үзебез хыялланган революция өчен көрәшмәгәнбез»...

ТӘТЕШ ЧЕМПИОННАРЫ

Тәтешне балыктан башка күз алдына да китереп булмый. Һәм тагын... ату мәктәбеннән башка! Татарстанның стендка ату спортындагы данлыклы җиңүләре традициясе нәкъ менә биредә пәйда булган. Сүз уңаеннан, әлеге батырлыкларга музейда тулы бер спорт даны залы багышланган, ул легендар Солтан Яруллиннан башлана.

Моннан алтмыш елга якын элек Бөек Ватан сугышында катнашучы, аучы Яруллин армиядән соң Тәтешкә кайтып төшә. Тормышны да, эшчәнлекне дә «буш урында, нульдән» башларга туры килә. Эш шунда ки, подполковник Солтан Яруллинның спорт мәктәбе оештыру хыялын (гәрчә бу җирләрдә аучылык һәрвакыт мактаулы һөнәр саналса да) күпләр озак вакыт буе сәерлеккә саный. «Хәер, аучылык – бер хәл, ә менә тәлинкәгә ату – бөтенләй башка бит», – дип искә ала ул елларны Россиянең атказанган тренеры Сергей Демин.

Әмма, кем әйтмешли, эш остадан курка, ә Яруллин осталарның тренеры була! Тиз арада Тәтештә ату мәйданчыгы, корал складлары, ә иң мөһиме – атаклы «Яруллин» мәктәбе пәйда була. Хәтта күп еллар үткәч тә, шәкертләре тренерларының алымнарын яхшы хәтерли. Шулардан берсе – өченче тапкыр тидермәүгә кадәр ату: Яруллин күнекмәләр вакытында да бик игътибарлы булырга, һәр патронның кадерен белергә өйрәткән. Ул оештырган мәктәптә дистәләрчә чемпион үсеп чыккан. Иң танылганы – Олимпия уеннарының көмеш медале иясе, стендка ату буенча дүрт тапкыр дөнья чемпионы Светлана Демина.

Русский Дом
Притяжение Родины

ИҢ ИХЛАС

СИХТЕРМӘ-ХУЗАНГАЙ АВЫЛЫНДАГЫ (ӘЛКИ РАЙОНЫ) ПЕТР ХУЗАНГАЙ МУЗЕЕ

Автор:
Татьяна Вафина

«Татарстан» журналын Петр Хузангай музеена «ТАССРга 100 ел» сайтында уздырылган иң атаклы якташ өчен тавыш бирү нәтиҗәләре алып килде. Әлки районында яшәүчеләрнең якташы тиз арада беренче урынга чыкты – аның өчен Әлки кешеләре генә түгел, дөньядагы бөтен чувашлар да тавыш биргән диярсең. Чыннан да, шагыйрь Петр Хузангай иҗатын яратучылар арасында төрле милләт кешеләрен очратырга була, аның шигырьләре 25 телгә тәрҗемә ителгән бит!

ТӨГӘЛ ВАКЫТ

– Ничә минутлык экскурсия кирәк сезгә? Биш минутлыкмы? Әллә унмы?.. Бәлки ярты сәгатьлектер? – дип каршылый кунакларны Хузангай музее директоры Олег Мурзин. Һәм безнең аптырап калганны күреп аңлатып китте:

– Килүчеләр төрле бит. Кемдер бик ашыга, бигрәк тә дәрәҗәле кунакларның вакыты санаулы. Кемнеңдер исә рәхәтләнеп йөрерлек вакыты бар…

– Ничек соң? Билгеле вакытка сыешасызмы?

– Әлбәттә! Саный башлагыз, әйдә, – дип сәгатькә күрсәтә директор. – Дөрес, кызыксынып китеп, безнең музейда билгеләнгән вакыттан озаграк булучылар күбрәк. Мәсәлән, Минтимер Шәймиевкә 5, иң күбе 7 минут вакыт бүлгәннәр иде. Ул район үзәгебез Базарлы Матакта үткән Бөтенроссия авыл хуҗалыгы киңәшмәсенә килгән чакта… Музейга керде дә, 1 сәгать 17 минут йөрде!

Егерме минутка килешеп, Хузангайның шул авыл музеена сыйган кадәр дөньясы буйлап сәяхәткә кузгалабыз – башта авыл өенә килеп эләгәбез. Анда безгә авылдашы Сергей Теребилов язган портретлардан шагыйрь үзе һәм аның әнисе карап тора. Аннары шагыйрьнең кабинетына үтәбез – Чебоксардагы фатирында ул нәкъ менә шул әйберләр арасында иҗат иткән.

ЯКТАШЛАР ХЫЯЛЫ

Һәр авыл музее диярлек оешуы белән үз ватанының фидаиләренә бурычлы. Олег Мурзин – нәкъ менә шундый патриотларның берсе. Ул туган авылының язмышын үзенеке дип кабул итә. Атаклы якташларының музеен булдыру – аның гомерлек хыялы, башка авылдашлары да шул турыда хыялллана. 2002 елда музей ачылганчыга кадәр, Мурзин булачак экспозицияләр өчен материаллар туплый, музейның концепциясен эшли һәм шул вакыттан хәзерге көнгә кадәр яраткан музеенда хезмәт куя.

Кагыйдә буларак, экскурсияне ул Татарстанда танылган менә бу шигырь юлларыннан башлый:

Фото: Александр Гайнетдинов

Якташ шагыйренең шигырен Олег Мурзин тәрҗемәдә дә, оригиналда да укый.

Живём среди татар в ладу и мире.
Два языка мы знаем, третий – наш…
В соседних памятных селеньях
Татарин, русский и чуваш
Зовут друг друга с уваженьем
Иптәш, товарищ иль юлдаш.

ПОЛИГЛОТЛЫК – ЧУВАШ ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Якташ шагыйренең шигырен Олег Мурзин тәрҗемәдә дә, оригиналда да укый. Экскурсияләрне дә өч телдә үткәрә ала: татарларга – татарча, русларга – русча, чуашларга – чувашча… Гомумән алганда, Хузангайча. Шагыйрь совет әдәбиятында иң яхшы тәрҗемәчеләрдән була бит. Төрле милләттән булган 187 шагыйрьне тәрҗемә итә ул. Сүзгә-сүз, подстрочниктан башка. Татар шагыйрьләреннән – Тукайны, Җәлилне, Такташны, Ренат Харисны тәрҗемә итә, чөнки татарча бик шәп белә. Мостай Кәримне башкортчадан тәрҗемә итә, чөнки башкортча да бик оста сөйләшә. Рәсүл Гамзатовны – аварчадан, Давид Көгелтиновны – калмыкчадан. Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган баһадир»ын тәрҗемә итәр өчен, үләренә ел ярым кала грузинча өйрәнә.

ПЁТР ПЕТРОВИЧ ӨЕНӘ КАЙТТЫ

Атаклы шагыйрь хөрмәтенә ачылган музей авылга яңа сулыш өрә. Күп кенә совет авыллары кебек үк, Иске Сихтермә 1980 нче елларга бөтенләй ташландык хәлгә килә яза, үзенең элеккеге данын җуя. Ә бит биредә, Иске Сихтермәдә, районның иң борынгы мәктәбе урнашкан – данлыклы уку йорты чуваш мәгърифәтчесе Иван Яковлев һәм Сембер губернасы халык училищелары директоры Илья Ульяновның (Ленинның әтисе) турыдан-туры катнашында 1875 елда ачылган була, 1935 елда исә ТАССРның үрнәк булырлык мәктәбе дип танылa. Биредәге хастаханә дә – ул чактагы Спас өязендә иң борынгылардан, анда бөтен әйләнә-тирә авылларның халкы дәваланган. Табиблар арасында хәтта Пирогов укуларына чакырылучылар да булган… Иске Сихтермә колхозлары белән дә дан тоткан, алар бөтен Советлар Союзында иң яңгыравык исемнәрне йөрткән – Ленин исемендәге, XXII партсъезд исемендәге көмәк хуҗалыклар гөрләп эшләгән!

БҮЛӘК ИТЕЛГӘН ФАМИЛИЯ

Хузангай туган авылына үз фамилиясен «бүләк иткән», һәм Иске Сихтермә Хузангай дип йөртелә башлаган. Аннары, тарихи атамасын да саклап калырга теләп, авылны Сихтермә-Хузангайга әйләндергәннәр. Ә музей үзе исә шулкадәр популярлашкан ки, былтыр гына да анда Россиянең 16 төбәгеннән өч меңнән артыграк кунак булган. Әлки халкы фикеренчә, музейга килүчеләрне анда халык шагыйренең тормышы һәм иҗатына багышланган бик күп чын экспонатлар саклану җәлеп итә. Шагыйрьнең тол калган хатыны, СССРның, РСФСРның һәм Чуваш Республикасының халык артисты Вера Кузьмина, музейны карагач: «Ниһаять, минем җаным тыныч: Петр Петрович өенә кайтты», – дигән.

Музей экспозициясе шагыйрьнең ватанына кайткач язган шигырендәге юллар белән аталган: «Туган авылымдагы якташларым янына кайттым…» – ди ул анда.

ШАГЫЙРЬ ЙӨРӘГЕ

Музейда кызыклы экспонатлар күп. Менә җирле Николай-Чудотворец чиркәвеннән бәләкәй Хузангай чукындырылган икона-тәре. Әдип шигырьләрен баскан язу машинкасы – Олег Витальевичның яраткан экспонатларыннан берсе. Шагыйрьнең эшләпәсе…

Әмма барыбер иң зур кызыксыну уяткан нәрсә… шагыйрьнең йөрәге. Юк-юк! Ул биредә түгел, Чуваш дәүләт университетының анатомия музеенда саклана. Биредә йөрәкнең фотосурәте генә куелган. Әмма нәкъ менә шуның янында һәркем туктап кала һәм экскурсия уздыручыны өчләтә игътибар белән тыңлый башлый:

– Петр Хузангай яман шештән үлеп киткән. Үләчәген алдан белгән һәм исән чагында ук йөрәген үз халкына васыять иткән, – дип сөйли Олег Витальевич. – Шагыйрь: «Бөтен казанышларым өчен мин үз туган халкыма бурычлы. Үзем үлгәч тә, йөрәгемнең чуваш халкына хезмәт итүен телим», – дип язып калдырган.

Без дә, чуваш халкы исән икән, Хузангайның йөрәге дә исән, дип саныйбыз. Хузангай йөрәге исән икән – чуваш халкы да исән.

Хузангай вафаты алдыннан әнисен һәм хатынын болай дип юаткан:

Не надо плакать, рук ломать не надо,
Земное в землю-и всему свой срок.
Я тут любим, и будет мне отрадой
Тобой взращённый надо мной дубок…

МУЗЕЙЛАРДА КАЛГАН МӘХӘББӘТ ТАРИХЛАРЫ

Мәхәббәт, гаилә һәм тугрылык көнендә «Татарстан» Петр белән Феврониянең Казанда Чистай урамын бизәп торан һәйкәле архитекторларын гына искә алып алмый, ә Татарстан музейларындагы вакытлар узу белән саргайган фотоларда, кипкән чәчәкләрдә, уалырга торган яфракларда, күз яшьләренә манчылган хатларда саклана торган олы, якты һәм дулкынландыргыч мәхәббәт тарихларын да искә ала...
Шушы юлларны укыгыз да сурәтләрдәге йөзләргә игътибар белән карагыз: мәхәббәтнең һәрвакытта да җиңеп чыгуына янә бер инанырсыз. Юкка гына мәхәббәткә һәм аның геройларына җырлар багышламыйлар, китаплар язмыйлар һәм һәйкәлләр куймыйлар икән.

БЕРЕНЧЕ ТАРИХ
тәураттагыча диярлек

ИКЕНЧЕ ТАРИХ
эпистоляр

ӨЧЕНЧЕ ТАРИХ
мистик

БЕРЕНЧЕ ТАРИХ
тәураттагыча диярлек...

Автор: Олеся Бондаревская

Казанның Евгений Боратынский музеенда Лев Толстойның портреты саклана. Аны Ксения Боратынская бөек язучының үлеменә берничә ел кала ясаган. Әлеге сурәткә Тәураттагыча диярлек мәхәббәт тарихы салынган. Аның уты шагыйрьнең варислары кичәргә мәҗбүр булган караңгылыкны яктырта...

Алар икесенә дә 23 яшь вакытта очраша. Берсе – Ксения, шагыйрь Боратынскийның оныгы, икенчесе – Архип Алексеев, белем алырга хыялланган гади крестьян малае. Ул чакта – 1900 елда – бу икәү арасындагы никахны күз алдына да китереп булмый, һәм моңа социаль аерма гына да сәбәпче түгел.

Ксениянең әнисе, Көнчыгышны өйрәнүче галим Али Казембекның кызы, балаларын иң югары гуманизм рухында тәрбияли, һәм алар җәмгыятькә хезмәт итүдән тыш, үзләренә башка язмышны юрамыйлар да. Ксения халыкка файда китерү, мөгаллимлек итү турында хыяллана һәм бөтен яшьлеген шуңа әзерләнүгә багышлый. Бервакыт, аның беренче балы алдыннан, әтисе кызына йөз сум акча бүләк итә. Ксения бу акчага крестьяннар мәктәбенә нәрсәләр алырга икән дип баш вата башлый – ул бит мәктәп ачу турында хыяллана. Ә ул акча балга кия торган күлмәк алыр өчен булып чыга... Ксения, елап, бүлмәсенә йөгерә.

Архип Алексеев Шушарыдагы Боратынскийлар утарына (хәзерге Татарстанның Биектау районында) әлеге гаиләнең авыл балалары өчен мәктәп ачуы турында ишетеп килә. Туган авылы Бөреледән үк җәяү килә ул. Аягында – чабата, кулында – бер төргәк китап, белемгә сусап, укытучы булырга хыялланып кузгалуы. Боратынскийлар сәләтле укучыны тиз күреп алалар. Күпмедер вакыттан соң, Архип белеме буенча үзе белән бергә шөгыльләнгән Ксенияне узып китә һәм Казан университетына филология бүлегенә укырга керә. Әмма бер-берсенә карата уянган кайнар хисләр яшьләрнең икесен дә куркуга сала.

«Нигә әле мин сезне яратам, эзләгәнемне таптым, димәскә. Әмма күз алдына гына китерегез әле, коточкыч бит: ярым укымышлы пролетарий – нинди тотнаксызлык...» – дип яза көндәлегенә Архип. «Мин үземне шушы вак бәхетем өчен кызганам, ягъни шушы вак бәхетне теләвем өчен. Без, кызлар, барыбыз да бер үк кармакка эләгәбез, һәм бу шундый тапталган күренеш инде, әмма шул ук вакытта минем бөтен җаным әлеге тойгыларда; моннан котылырга кирәк һәм үземне эшкә багышларга... газап, мәңгелек газап...» – дип яза Ксения. Шушы бәргәләнүләр, тилмерүләр белән җиде ел үтеп китә.

Бервакыт Архип Шушарыга хәбәр алып килә: аны Саратовка укытучы итеп билгелиләр. Ксения, кияүгә чыгып, аның белән китәргә ризамы? Ксения баш тартмакчы була, әмма... ризалаша. Барысы да үз урынында кебек, инде туйга әзерләнә башлыйлар. Әмма кәләшнең күңелен шик корты кимерә. Мөгаллимлеген гаилә аркасында ташларга ярыймы? Үз бурыч-вазыйфасыннан баш тартырга хакы бармы? Ксения киңәш сорап... Ясная Полянага үзе табынган һәм аның өйрәтүләрен барысыннан да югары куйган Лев Толстой янына китә.

Язучы кунакны илтифат белән каршы ала. Әңгәмә барышында Ксения үзенең альбомына остазының портретын төшерә. «Нәрсә инде мәктәп, башка кешеләр дә табылыр, ә сез гаиләгезгә мәктәпкә караганда ныграк кирәк булырсыз, билгеле, балаларыгыз булса», – дип нәтиҗә ясый Лев Николаевич. Аның бу сүзләреннән Боратынская югалып кала, әмма үзе тукталган танышларына кайткач, әкрен-әкрен генә яңа бурычына ияләшә төшә. Икенче көнне ул Толстой белән хушлашырга килгәч, язучы аны күреп сөенә һәм болай ди: «Бүген төнлә сезгә әйткән сүзләремне уйлап яттым... Әгәр сез үзегездә кешеләргә хезмәт итәр өчен җитәрлек көч сизәсез икән, кияүгә чыкмагыз – алай яхшырак булачак».

«Мин сезнең киңәшне дә, үземнең вөҗданымны да тыңламадым һәм кияүгә чыктым...» – дип яза Ксения Лев Николаевичка шул ук 1907 елда. Кыска, әмма бәхетле никахтан Ксения белән Архип Алексеевларның өч баласы туа. Аннан соң революция була, һәм ул Боратынскийларның тормышын җимерә. Архип Алексеев 1920 елда Себердә аклар ягында сугышканда тифтан вафат була. Хатыны аннан соң 38 ел яши әле. Гомеренең ахырына кадәр ул укытучы булып эшли. Алексеевларның кызы Ольга пианист һәм педагог була. Уллары исә Бөек Ватан сугышы фронтларында сугышачак, аннан соң фәнгә хезмәт итәчәк. Матвей, физиолог, – яшерен космос өлкәсендә, Иван – техника өлкәсендә. «Минем хатирәләрем» китабында Ксения карары өчен беркайчан да үкенмәвен яза. Кайчак хәтта даһилар да ялгыша, ә йөрәк – беркайчан да.

ИКЕНЧЕ ТАРИХ
эпистоляр

Свияжск тарихы музее архивында Артемьев-Слободскойлар гаиләсенең бер-берсенә язган бик күп хатлары сакланып калган

Автор:
Алсу Троицкая

Аларның Никольский урамындагы 10 нчы санлы йортының безнең көннәргә кадәр саклануы могҗизага тиң – Иделдә сусаклагычлар төзелү сәбәпле, Свияжскидагы торак йортлар юкка чыгарыла диярлек. Артемьев-Слободскойлар йортыннан музейга балалар ясаган рәсемнәр дә, революциягә кадәр уйналган уеннар да югалмыйча килеп җитә алган. Иң мөһиме – Казанның Мариинск гимназиясендә укыган Елизавета Слободскаяның кияве – Казандагы сукырлар өчен училищеның яшь мөгаллиме Александр Артемьев белән бер-берсенә язган хатлары.

Алар бер-берсе белән берничә ел дәвамында хат аша аралаша, соңыннан өйләнешәләр, ләкин аерым торырга мәҗбүр булалар. Шул вакытта да алар берничә генә юл булса да, хат язып салырга вакыт таба. Архивта аларның якынча 30 ел дәвамында язышкан хатлары саклана! 200 хат...

Бер-берсен өзелеп сөйгән, «шатлыкта да, кайгыда да бергә» булган пар. Аларның хатлары – чын мәгънәсендәге мәхәббәт тарихы, гомернең олы һәм бик тә мөһим бер өлеше. Назлы, хисле хатлар еракта калган елларның бик күп нечкәлекләрен күз алдына китереп бастыра. Ике яшь кеше арасында йөргән хатларда көчле, самими хисләр генә түгел, сагыш та, көнләшү дә, кавыша алмаудан өметсезлеккә бирелү дә... Төрле чорда аларның көнделендә әле берсе, әле икенчесе өстенлек ала. Мөнәсәбәтләренең башында ук әле яшьләр үкенеч белән ачу арасында аерманы эзли, чөнки очрашуларның берсендә Елизавета Александрның үзенә карата ачуын түгел, ә үкенечен сиземләп кала...

Елизаветаның Александрга язган менә бу хатыннан алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең ни дәрәҗәдә дулкынландыргыч булуы аңлашыла: «Кадерлеләрдән кадерле, сөекле егетем минем!

Язар сүзем булмаса да, сиңа бер сүз әйтәсем килгәнгә генә, синең исемеңне тагын бер кабатлыйсым килгән өчен генә дә хат язарга утырдым...»

«Санечка, күгәрченем минем. Сез шундый кызганыч миңа, Сезнең янда була алмавым шундый үкенечле, шундый ачы, сезне тынычландыра да алмыйм бит, сөеклем минем...»

Әйтергә кирәк, өйләнешкәнчегә кадәр алар бер-берсенә хатларны яшерен төстә генә язалар, чөнки «Дөньяда, өйдә һәм ишегалдында» этикеты кагыйдәләре бу җәһәттән төгәл инструкция бирә: «Яшь кыз ир-егеткә беркайчан да, хатта әти-әнисе исеменнән дә хат язмый; иң яхшысы – аңа туган булмаган яки бик карт булмаган ир-егетнең кулында ул язган бер генә юл хат та булмау». Революциягә кадәрге Россиядә өйләнмәгән ир-егетләр һәм кияүгә чыкмаган хатын-кызлар бер-берсе белән иркен аралаша алмаган: бу әхлаксызлык билгесе саналган.

Нәкъ менә Елизаветаның хатлары аша Свияжск тарихы музеенда аларның йортларындагы җиһазларга кадәр торгызу мөмкин була. Ул вакытта менә нинди хатлар яза торган булганнар!

...Елизавета белән Александрның ак кәгазьгә чыгарып алынган хатлары төрле озынлыктагы җепләрдә түшәмнән асылынып тора. Актерлар алар янында тукталып кала да кирәкле хатны алып укый. Басып та, өстәл янына утырып та, идәнгә ятып та... «Мәхәббәт. Диалоглар. Хатлар» спектакле документаль материалга – Артемьев-Слободскойлар гаиләсе хатларына нигезләнгән. Куючы режиссер Татьяна Лядованың спектаклендә Казан театр училищесы студентлары уйный. Алар узган гасырның башын гәүдәләндерә. Ул вакытта ир-егет белән хатын-кыз бер-берсенә ничек мөрәҗәгать иткән, ул ихтирам, ул сүзләр – болар барысы да күптән онытылган инде.

Елизавета 48 яшендә вафат була, Александр аннан соң тагын егерме ел яши. Ул башкача өйләнми.

ӨЧЕНЧЕ ТАРИХ
мистик

Узган гасыр башында Долгая Поляна дигән җирдә Молоствовлар гаиләсе төзегән йорт әлегә кадәр аларның мәхәббәте турындагы хәтерне саклый.

Автор:
Ольга Туманская

Гасыр белән бер яшьтәге Себер карагайларының ботаклары, бер-берсенә орынып, яшел төстәге мәһабәт тоннельне хасил итә. Туп-туры өй каршына алып килә торган аллея – мәхәббәтнең мәңгеләштерелгән билгесе һәм туй бүләге. Владимир Молоствов үзенең яшь кәләше Елизаветаны әнә шулай каршылый. Ул сөйгәненең кайсы маршрут белән киләсен белми – су юлы беләнме, җир өстеннәнме – шуңа да берьюлы ике аллея утырта. Һәм һәркайсында – 460 ар агач! Бу безнең илдә карагайлардан сузылган иң озын тоннель, диләр. Аның гомуми озынлыгы – дүрт чакрым. Елизавета утарга кич белән эңгер-меңгер төшкәндә килеп җитә, әмма бүләкне бәяли ала – мәхәббәт аллеясен «барин» кушуы буенча керосин лампалары белән яктырталар.

Бу гашыйк җаннарны сөю хисләре генә түгел, ә карашлар, принциплар, мәнфәгатьләр уртаклыгы да берләштерә. Егет – Пажлар корпусын тәмамлап, Преображенский полкында лейб-гвардиядә хезмәт иткән, Тәтеш өязендәге беренче кеше, дворяннар башлыгы. Мәгърифәтче, тәрәккыяткә йөз тоткан хуҗалыкчыл шәхес. Кыз – Италиядә, Франциядә укыган, берничә телдә иркен сөйләшә, фән белән кызыксына, гимназиядә укыта.

«Ирем хезмәттә әле, әмма авыл хуҗалыгы белән кызыксына, авылга күчеп кайтырга хыяллана. Шулай итәрбез дә», – дип яза Елизавета Владимировна хатларының берсендә. Әйе, алар бу җәһәттән дә – Казаннан ераккарак, табигатькә якынрак китү карарында да уртак фикердә булалар! Хыяллары 1904 елда тормышка аша – Молоствовларның Тәтеш калкулыкларындагы Озын Аланда урнашкан утарлары яшь гаиләнең даими яшәү урынына әйләнә. Биредә Владимир Германович готика стилендә соңгы техник мөмкинлекләрне кулланып, таштан йорт салдыра. Йорт уникаль система белән җылытыла, анда динамо-машина була. Ул шулай ук Идел аръягында электр уты белән яктыртыла торган беренче бина да, хәтта кайнар суы да бар! Йортның әйләнәсендә исә аннан да ким булмаган гаҗәеп манзара – керкә (форель) балыклары һәм аккошлары йөзеп йөргән, шарлавыклы күлләре, зур җимеш бакчалары, роза бакчасы, сирәк үсемлекләр үскән оранжереясе бар...

Бу күркәм пар игелекләрне үзләре өчен генә кылмый. Алар гади кешеләр өчен дә бик күпне эшли – уртак хыяллары да илгә һәм җәмгыятькә файдалы, кирәкле булу иде бит. Мәктәпләр, дәваханәләр, даруханәләр, уку йортлары төзиләр... Владимир Германович уңыш алу буенча яңа рекордлар куя, шәраб ясау һәм күкерт чыгару заводлары төзи, аның катгый таләбе белән күперләр төзелә, ерымнар нычытыла. Планда – Тәтешкә кадәр тимер юл төзү! Елизавета Владимировна да фәнгә үзеннән өлеш кертергә омтыла. Ул биредәге үсемлекләр дөньясын тикшерү эшләрен алып бара, академик Вавилов җитәкчелегендә чәчүлек орлыкларны тикшерә, җирле метеорология станциясендә эшли... Алар кайлардан бетмәс-төкәнмәс көч ала да нинди илһам чишмәләреннән туена соң? Бүген кайберәүләр бу урынны Татарстан картасындагы иң мистик нокта дип расларга тырыша. Иделнең куе агачлыклы ярында ачык яшел төстәге, япан бер турыпочмаклы бер мәйдан күренә. Имештер, биредә төрле могҗизалар була, җиһазлар эшләүдән туктый, сәгатьләр вакытны дөрес күрсәтми башлый, ә ял итәргә туктаган кеше үзенә каяндыр көч инүен тоеп ала.

Тәтеш төбәге тарихы музее хезмәткәрләре тагын да зуррак могҗизаларның шуннан ерак түгел бер йортта булуы турында сөйли. Ул исә хисләр мистикасы була.

...1930 елның мартында була әлеге хәл. Елизавета кайсыдыр бер җирле чиновникның кулыннан документ ала. «Тәтеш волосте башкарма комитетының кулаклаштыру турындагы карары». Әйләнә-тирәсендә ниндидер кешеләр ыгы-зыгы килә. Аның җанына кадерле булган йорттан җиһазларны чыгаралар, савыт-сабаны, китапларны... Туй бүләге, клавишаларына Балакирев үзе орынган ак рояльгә чират җитә... Шундый озак вакыт дәвамында утарларын фәкыйрьлектән коткарырга тырыша ул! Зур китапханәләрен, уникаль гербарийны, фәнни һәм әдәби хезмәтләрне. Владимир 1918 елда вафат була. Елизавета тагын унсигез ел яши әле.

Әлеге парның кабере янәшә – Идел ярында, утардан ерак түгел генә урнашкан. Имештер, Елизаветаның рухы аларның Владимир белән мәхәббәт аллеясе буйлап әле дә йөри.

МӨХӘММӘТҖАН ХӨСӘЕНОВ – БЕРЕНЧЕ МӨФТИ

Автор: Илдус Заһидуллин

Кара репродуктор-тәлинкә, «Ватан-Ана чакыра!» дигән җанөшеткеч плакат һәм Левитанның боздай салкын тавышы. Аны ишеткәч, бүген дә каз тәннәре чыга: «Советлар Союзы гражданнары! Бүген иртәнге сәгать 4 тә, сугыш игълан итмичә, Германия кораллы көчләре Советлар Союзы чикләренә һөҗүм ясады. Совет халкының немец-фашист илбасарларына каршы Бөек Ватан сугышы башланды...»

Империя чорының Оренбург мөфтиләре арасында Мөхәммәтҗан Хөсәенов шәхесе игътибарны аеруча җәлеп итә. XVIII гасырның икенче яртысында аның кебек рус хакимиятенә хезмәттә дини белемен карьера ясау өчен оста файдаланып, югары дәрәҗәгә ирешкән башка шәхес булмаган, дип әйтергә мөмкин.

Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен бине Габдерахман (1756–1824) гыйлемле нәселдән чыккан. Шиһабетдин Мәрҗани сүзләренчә, аның бабасы Мансур – Идел буеннан Бохарага барып укыган беренче шәкерт, иленә кайткач, фарсы телендә дини хезмәт язган голәмә булып танылган.

Мөхәммәтҗан Хөсәенов Борындык авылында туган, башлангыч белемне туган ягы мәктәпләрендә алган. Заманында алдынгы мәдрәсәләр белән дан тоткан Оренбургтан ерак түгел генә урнашкан Каргалыга барып, Кавказдан килгән Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстани исемле галимнән һәм башка голәмәләрдән сабак ала.

Ул заманнарда тирән дини белемгә һәм шөһрәткә омтылган татар яшьләре Бохарага барып гыйлем җыйган. Урта Азиягә белем эстәргә киткән Мөхәммәтҗанның, хәзергечә әйтсәк, Россиядә хәләл икмәк стандарты кертергә тырышлыгы игътибарга лаек. Мәрҗани язганча, егет сыра яки шәраб эшләүдән калган калдыкларны кушып пешергән икмәкнең хәләл булмавы хакында өч Бохара голәмәсеннән фәтва ала. Бу хакта Каргалы галимнәренә хәбәр итә. Фәтва шәһәрләргә таралгач, татарлар арасында шактый җәнҗал чыга. Күрәсең, икмәк пешереп сатучылар рецептларын үзгәрткәннәр яки татарлар үзләре хәләл икмәк пешерә башлаганнар.

«Мулла йортының эчке күренеше». Рәссам К.Ф. Гун рәсеме. 1862 ел.

Мөхәммәтҗан Бохарадан туган иленә 1777 елда әйләнеп кайта һәм мөдәррис булып эшли, аннары Кабулга барып белем эсти, кайткач шәехлек кыла. Мөхәммәтҗан Бохарага да, Әфганстанга да, белем туплаудан тыш, Чит ил эшләре коллегиясе кушуы буенча разведчик буларак мәгълүмат җыярга да җибәрелгән була.

КАЗАХ ДАЛАСЫНДА

1785 елда Сембер һәм Уфа генерал-губернаторы итеп барон Осип Игельстром билгеләнгәч, Мөхәммәтҗан Хөсәенов Казах даласын тыныч юл белән Россиягә кушу планын тормышка ашыручы төп фигурага әйләнә. Ул Оренбург чик буе комиссиясе штатына офицер итеп эшкә алына, мөселманнар арасында аны Оренбург чик буе комиссиясе ахуны дип беләләр. Россиянең Кече һәм Урта казах җөзләренә карата сәясәте шушы институт аша тормышка ашырыла. Мөхәммәтҗан Хөсәенов шул ук елда Екатерина II рескрипты буенча Оренбург төбәгенең «беренче ахун»ы итеп тә раслана.

Бу вакытта Кече җөздә Байбакты ыруы старшинасы Срым Датов Нуралы ханга каршы сугыш алып бара. Игельстром, аның өстенлеген күреп, Срым батырны яклаган кара сөяк бәкләр, нойоннар ягында солтаннарга, гомумән аксөякләргә каршы чыгып, Даланы империягә тыныч юл белән ныклап беркетү сәясәтен үткәрә башлый. Нуралы хан, үтерелүдән куркып, 1786 елны Оренбургка килеп сыена, аны, 5 елга мең сум жалованье билгеләп, гаиләсе һәм хезмәтчеләре белән бергә Уфа каласына җибәрәләр.

Мәчет фасады. Шушы 1781 елгы проект буенча Оренбург һәм Троицкида казна хисабына таштан мәчетләр салынган.

Кече җөз хансыз кала. Игельстромның максаты – хакимиятне, шул ук елны Оренбургта ачылган Чик буе мәхкамәсенә, аңа буйсындырылган Кече җөздәге өч ыру өчен аерым-аерым төзеләчәк мәхкамә советларына тапшыру була.

Мөхәммәтҗан арадашчы сыйфатында 1785 елның көзендә 208 старшина катнашындагы җыенда хан хакимиятен юкка чыгару турындагы төп сүзне Срым батырдан әйттереп, барысын да Екатерина II гә тугры булырга шәригатьчә ант иттерә. Әби патша исә 1787 елда казахларга тарату өчен Коръәнне типографиядә махсус бастырып җибәрә. Мөхәммәтҗанның бер айдан артыкка сузылган миссиясе моның белән генә тәмамланмый, ул җәйләүләрдә Игельстромның Далада тынычлык урнаштырырга өндәгән хатларын тарата. Кайткач, рапорт язып, генерал-губернаторга сәясәтен камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәрен җиткерә.

1886 елның май аенда баруында Мөхәммәтҗан Хөсәенов җиде солтанны һәм 108 старшинаны ант итәргә күндерә. 1787 елның апрелендә тагын 214 старшина патшабикәгә тугрылыкка ант итә. Шулай итеп, Кече җөзнең идарә катламын Россиягә ант иттерү уңышлы тәмамлана, ә Мөхәммәтҗан җәйләүләрдә рус хакимиятенең ислам динен яхшы белүче вәкаләтле вәкиле буларак таныла.

Күрәбез, Мөхәммәтҗан куелган бурычны җиренә җиткереп башкарып чыга. Аның хезмәтенең хакы үсә: 1786 елны ике тапкыр арта (елга 300 сум), төбәкнең «беренче ахуны» вазыйфасы өчен тагын 200 сум өстәлә.

Чыннан да, Далада тынычлык урнаша, хакимият солтаннар кулыннан китә. Империя хакимияте, җәйләүләрдә үз йогынтысын арттыру өчен, татар муллаларын, сәүдәгәрләрен киңрәк файдалана башлый. Таш мәчетләр төзелә, татарларга, җәйләүләргә барып, вак сәүдә белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирелә.

МӨФТИ БУЛЫП БИЛГЕЛӘНҮ ТАРИХЫ

Мөхәммәтҗанның мөфти итеп билгеләнүе Россиянең Көнчыгышта уздырылган сәясәсәтенә турыдан-туры бәйле. 1787–1791 елгы рус-төрек сугышы барышында Госманлы дәүләте Россиягә каршы Урта Азия ханлыкларын һәм казахларны җәлеп итәргә тырыша. Екатерина II Игельстромга Россия мөселманнарын чит ил йогынтысыннан араларга һәм хөкүмәткә каршы баш күтәрүләрне булдырмаска боера.

Шушы уңайдан, Уфа наместнигы идарәсе киңәшчесе Дмитрий Мертваго төбәктәге мөселман руханиларын күзәтүдә тоту өчен махсус хөкүмәт органы проекты тәкъдим итә. Шунысын да әйтергә кирәк: 1783 елны, Кырым ханлыгын Россиягә кушкач, Мертваго һәм Игельстром беркадәр вакыт Госманлы дәүләтендә яшиләр һәм ислам институтлары турында мәгълүматлы булалар. Шулай итеп, Екатерина II нең 1788 елның 22 сентябрендәге «Муллаларны һәм башка мөселман дини чиннарындагыларны билгеләү һәм Уфада Россиядәге барлык рухани чинындагылар белән идарә итү өчен Мәхкамәи шәргыя оештыру турындагы» указы империядә мөселманнарның ислам дәүләтләре йогынтысыннан саклауга юнәлдерелгән чара була.

Яңа оешма 1789 елның декабрендә тантаналы шартларда ачыла. Мөхәммәтҗан Хөсәенов башта аны дипломатик оешма дип белеп, хатларын да «Кыргыз-кайсак мөфтие» дип имзалый. Бу вакытта җәйләүләрдә Урта Азия ягыннан да руханилар күп булып, Далада ике як

муллалары арасында күчмәннәрне үз йогынтыларына алу өчен идеологик көрәш бара. Татарлар җиңеп чыга. Яңа оешманың рәисе һәм барлык мөселманнарның мөфтие итеп Мөхәммәтҗан Хөсәенов билгеләнә. Яңа институт составына өч елга сайланган өч казый да керә. Мөфти белән казыйлар барлык эшләрне бергәләп хәл итәргә тиеш була.

Моңарчы авыл мәхәлләләрендә дини ритуалларны халык тарафыннан сайлап куелган абызлар башкара. Хәзер имам-мөәзиннәр барысы да, Мәхкамәи шәргыя Ырынбургыйдә имтихан тотып һәм дини дәрәҗә алып, полиция идарәсендә императорга чиновниклар кебек үк ант бирәләр. Муллаларның хакимият алдындагы бурычлары чиновниклар һәм православие руханилары бер дәрәҗәгә куела. Дәүләт алдындагы төп бурычлары – императорга лояль һәм тугры мөселманнар тәрбияләү, мәхәлләдә җәмәгать тәртибен саклау һәм күзәтү, канун бозу очраклары турында вакытында хәбәр итеп тору.

1797 елда Уфа наместниклыгы Оренбург губернасы итеп үзгәртелгәч, Мәхкамәи шәргыя, башка дәүләт оешмалары белән бергә, Оренбургка күчерелә. 1803 ел башында алар белән кабат Уфага кайтарыла.

1788 елгы Указ Россиянең Европа һәм Азия өлешендәге мөселман руханиларын, шул исәптән 1868 елга кадәр казахларны да, бер дини идарәгә буйсындыра, үзара якынаю, мәдәни аралашу өчен хокукый нигез шулай барлыкка килә. Иң мөһиме – Россия хөкүмәте мөселман руханиларын рәсми рәвештә танып, алар белән хезмәттәшлек итүгә күчә. Дини белем бирү системасы, руханилар, мөселманнарның дини хокуклары Мәхкамәи шәргыя Ырынбургыя канаты астына туплана. Ул руханилар билгеләүдә, мәчетләр төзүгә рөхсәт бирүдә, мәчетләр янында мәктәп-мәдрәсәләрне ачуда катнаша.



Казах даласында мәчетләр янында татар мәктәпләре ачу турында язу.

АРАДАШЧЫ-ДИПЛОМАТ

Казах даласында Осип Игельстром ачкан мәхкамәләр ныклап эшләп китә алмый. 1790 елда Срым батыр, бәхәсле сорауларны килешеп хәл итү өчен, мөфтине Далага махсус чакыртып ала. Моңа Мөхәммәтҗанның Казах җөзләрендә идарә традицияләрен яхшы белүе һәм оста дипломат булуы ярдәм итә. Казахларда хакимият солтаннар, ягъни чыңгызыйлар кулында була. Игельстром реформасы шушы тәртипне боза. Солтанчыңгызыйлар үзләренең «гади кешегә» буйсынырга теләмәүләрен әйтәләр. Мөхәммәтҗан мөфти аларга болай дип җавап кайтара: «Патша галиҗәнаплары Срымны, хезмәтләрен бәяләп, барча халык өчен беренче итеп билгеләде, сез, солтаннар, аңа буйсынмасагыз буйсынмагыз, ләкин биргән антыгызга тугры калыгыз һәм рус җирләренә барымтага йөрмәгез». Шулай итеп, мөфти солтаннарга, әгәр биргән антларына тугры калсалар, тәртипләр үзгәрергә мөмкин, дигән өмет бирә.

Оренбургка кайткач, Мөхәммәтҗан Хөсәенов рус хакимияте каршында казах халкын яклаучы сыйфатында чыгыш ясый. Бу елларда Урал казаклары күчмәннәрне ык җәберли башлау сәбәпле, казакларга карата чара күрүне һәм әсирлеккә алган казахларны иреккә җибәрүне үтенә. Уфа наместниклыгы җитәкчесе Александр Пеутлинг мөфтигә мондый яклау сәясәте өчен кисәтү белдерә.

Пеутлинг барон Осип Игельстром урынына билгеләнгәч, Мөхәммәтҗан Хөсәеновка Далага чыгуны тыя, ә 1791 елда хан хакимияткә кире кайтара. Срым тархан яңа ханга каршы көрәш башлый.

1796 елда Оренбург генерал-губернаторы итеп кабат Игельстром билгеләнгәч, мөфти тагын арадашчы-дипломатка әйләнә. 1797 елда хан үтерелгәч, Мөхәммәтҗан тырышлыгы белән Кече җөз белән идарә итү өчен ханы булмаган Хан советы оештыра. Беренче вакытта Хан советын мөфти үзе җитәкли.

XIX гасыр башында мөфтинең дипломатик эшчәнлек географиясе тагын да киңәя. Ул Кавказда, кабардалар кулындагы рус әсирләрен азат итүдә катнаша, кабардаларга ыру мәхкамәләре оештырып бирә, аларны Россия кул астына керү өчен ант иттерә. 1805 елда, хакимият кушуы буенча, Кече җөздә сәүдәне үстерү проектын әзерли. Александр I гә Казах даласында идарә реформалары әзерләү буенча баш эксперт һәм дипломатик миссияләрнең җитәкчесе булырга әзер икәнлеген әйтә. Шул ук елда Каспий диңгезенең көнчыгыш яры буенда яшәүче төрекмәннәр эшләре буенча дәүләт комиссиясе эшендә катнаша. 1806 елны Әстерхан янындагы казах солтаннары белән сөйләшүләр алып бара.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ШӘРӘФЛЕ ӘГЪЗАСЫ

Мөхәммәтҗан Хөсәенов Коръән сүзе катыштырылган халыкара дипломатиянең Россия дәүләте өчен никадәр әһәмиятле булуын, үзенең арадашчылык өлкәсендә алыштыргысыз шәхес икәнен аңлап эш итә. Кыенсынмыйча, императорлардан кат-кат матди ярдәм һәм яклау сорый. Һәм ала. Аның үтенеч-теләкләрен, бигрәк тә, Екатерина II һәм Павел I берсүзсез үти. Әйтик, 1786 елны ул сәүдәгәрләр түли торган салымнан азат ителә, 1893 елны мөфтинең элекке 1500 сумлык еллык жалованьесы тагын 1000 сумга арта, шуңа өстәп ул бриллиантлар белән бизәлгән медаль, төлке һәм кеш тиресеннән туннар белән бүләкләнә. Екатерина II Мөхәммәтҗанга башкортларның җирләрен, крепостнойлар сатып алырга рөхсәт бирә.

Мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов 1816 елның 14 февралендә Казан император университеты Советының шәрәфле әгъзасы итеп кабул ителә. Бу исемлектә ике генә мөселман бар. Икенчесе – аның кияве, генерал-майор, Эчке кыргыз урдасы ханы Җиһангир Букеев.

Мөхәммәтҗан Хөсәенов мөселман җәмгыятенең киләчәген урта һәм югары уку йортларын тәмамлаган шәхесләр катламы формалашу белән дә бәйли. Мөфти, беренчеләрдән булып, хакимияткә дин кардәшләренең белем бирү системасына реформа кирәклеген хакында хәбәр итә, Аның проекты нигезенә Уфада губернатор карамагында мөселманнар өчен махсус урта белем



бирә торган уку йортлары (гимназияләр) ачып, аларны тәмамлаган кешеләргә университетта уку мөмкинлеге булдыру фикере салынган була. Әмма проект кәгазьдә генә кала.

Мөфти гарәп һәм төрки кульязма китаплардан бай китапханә туплый. Китап җыюга хирыслык аның гыйлемгә омтылуын раслаучы мөһим дәлил булып тора. Шулай да мөфтинең иң көчле сыйфаты – вәгазьләү куәсе, сөйләгән сүзенең тәэсир көченә ия булуы. Мәрҗани үзенең әтисе Баһаветдин һәм башка өлкән яшьтәге голәмәләрнең – Мөхәмммәтҗанның замандашларының – сүзләренә таянып, аны зур белемгә ия шәхес итеп танулары хакында яза.

Татар сәүдәгәре йорты. Билгесез рәссам. XIX гасыр.

ГАИЛӘСЕ ТУРЫНДА

Мөфти гаиләсендә балаларына татарча һәм Европача тәрбия бирергә тырышкан. Аның 1824 елны 15 яшендә Бөкәй Урдасы ханы Җиһангиргә (1801–1845) тормышка чыккан Фатыйма исемле кызы татар, гарәп, француз, инглиз телләрендә иркен сөйләшкән, Коръәнне һәм Европа этикетын яхшы белгән 1826 елда, ире белән Николай I нең тәхеткә утыру тантанасына баргач, балларда вальс әйләнгән. Санкт-Петербургтан кайтышлый Казанда тукталгач, бу гаилә белән очрашкан Казан университеты профессоры Карл Фукс Фатыйманың русча сөйләшүеннән аның башка милләт кешесе булуы тоелмый дип язган. Хан хатыны буларак, Фатыйма Бөкәй иле белән Оренбург (татарлар. – И.З.) арасында дини һәм мәдәни элемтәләрнең ныгуына зур көч куя, фәкыйрь һәм мохтаҗларның балаларын үз хисабына, бай казахларныкын үз ризыклары белән Эстәрлетамак һәм Эстәрлебаш мәдрәсәләрендә укыттыра. Шушы татар мәдрәсәләрендә гыйлем туплаган малайлар бераздан танылган казах мөдәррисләре һәм галимнәре булып танылa. Җиһангир ханның Хан ставкасында мәчет салдыруы, һәр ыруг-кабиләгә имамнар билгеләве, аларга хокук кәгазьләрен бирү тәртибен кертүе, казах балаларын укытуны оештыруы да Фатыйманың уңай йогынтысы нәтиҗәсе.

Мөфтинең 1815 елда тутырылган хезмәт итү формулярыннан күренгәнчә, аның 19 яшьлек Мирзаәхмәт исемле улы Санкт-Петербургта чит диннәрне күзәтә торган Департаментта хезмәттә булган. Татарлар, гомумән мөселманнар арасында империя чорында башка беркем дә мондый дәрәҗәле урында эшләмәгән.

Мирзаҗан исемле 1850–1860 елларда вафат булган улы да хөкүмәт хезмәтендә, Оренбургта офицер була. Аның Хөсни исемле улы мөфтинең нәселен дәвам итүче бердәнбер оныгы булып чыга.

Мөфтинең ничә хатыны булуы турында төгәл мәгълүматлар юк.

Мөфти Казанда Гайшә исемле тол хатын белән никахлаша. Кәримә исемле хатынын Кара диңгез буендагы Анапа шәһәреннән ала.

Мөфти ханнар белән дә туганлашырга омтыла. 1800 елның 1 августында Оренбургта аның элекке Хива ханы Карай солтанның кызы Каракүз белән никахы мәҗлесендә бөтен губерна түрәләре кунак була.

Суфия исемле хатыны, чиркәс кызы булып, мөфтигә ике малай алып кайтып бирә. Ире вафат булгач, Атҗитәр авылында 110 яшькә кадәр яшәп, 1866 елда вафат була.

«Гомеренең азагында халык арасында абруе сүнгән» мөфти, хатыны Суфия, улы Мирзаәхмәт Атҗитәр авылы янында үзләренең җирләрендә урнашкан зиратта күмелә. 1902 елда Р. Фәхретдин мөфти хәзрәтләренең каберен зыярат итәргә Атҗитәргә баргач, җимерелеп баручы бер төрбәдән һәм бер зур кабер ташыннан башка игътибарга лаек әйбер күрми.

PRESSA

ТАТАРСТАН СӘЯХӘТЛӘРЕ

Кешелеккә ябырылган коронавирус зәхмәте гадәти әйберләрне гайре табигыйгә әйләндерде. Бигрәк тә туризмга кагылышлы вазгыять үзгәрде. Ерак илләргә сәяхәтләр тукталды, туристлар шәһәр читендәге бакчаларыннан башка җиргә баруны планлаштырмый, ял сезонынданиләр көткәне әлегә билгесез.

Әмма кайгырырга кирәкми, ниндидер Симилан-Мальдив-Маврикийларга караганда, йөрәкләренә һәрвакыт үзебезнең табигать якынрак булган Татарстаныбыз сәяхәтчеләре ярдәмгә ашыга... Алар, туган республикабыздан читкә чыкмыйча да, матур һәм сыйфатлы ял итеп, күңелләрне хушландырып була, дип ышандыра. Мәсәлән...



1

«СӘЙЯР» КОМАНДА

Мәгарәдә динозавр яшьтәшләре компаниясендә ял иту

2

ДМИТРИЙ АДКИН

Танкеевкадагы гыйбадәтханә. Югарыдан күренеш

3

НИЯЗ ГАТАУЛЛИН

Чатыр-тау өстеннән очу

4

АЛЕКСЕЙ УШАКОВ

«Ташландык Россия» ничек итеп Татарстанга китерде

Фото: Александр Ефремов; геройларның шәхси архивыннан

ТАТАРСТАН (ҺӘМ БАШКА ҖИРЛӘР) БУЙЛАП СӘЯХӘТ ИТҮЧЕЛӘР

Автор:
Александр Ванечкин

12 июньдә «Сәйяр» команда (команда «Кочующих») үзенең 27 нче туган көнен билгеләп үтте. Эш юбилейга якынлаша. «Сәйяр» команданың күчмә тормышы 1993 елда башлана. Казан финанс-икътисад институты студенты Әхәт Хафизов курсташларын үзенең туган ягы – Мари Илендәге Глухое күленә барырга күндерә. Шуннан башлана инде...

1

Институттан соң, гаилә корып, эшле һәм йортлы-җирле булгач та, КФИИның хисап-икътисад факультетын тәмамлаучы белгечләр, шулай ук аларга кушылган башка һөнәр һәм конфессия вәкилләре бүгенге көнгә кадәр Россия урман-кырлары, елга-күлләре буйлап сәяхәт итә. Чит илләр аларны бөтенләй кызыксындырмый. Бәлки, шуңа да аларны берничә коронавирус та куркытмый.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘН ШӘБРӘК

– Бездә барыбер әллә кайдагы чит илләргә караганда шәбрәк, – дип ышандыра «Сәйяр» команданың алыштыргысыз капитаны Әхәт Хафизов. – Без универсаль туристлар – җәяү дә, чаңгыда да, юлсыз җирдә автомобильдә дә, атта да, салда да, дельтапланда да сәяхәт итә алабыз... Безнең өчен иң мөһиме – гомерне шәһәр ыгы-зыгысында түгел, күбрәк табигать кочагында үткәрү. Безнең яклардагы табигать исә бик төрле, теләсә кемнең күңеленә хуш килерлек җирләр бик күп.

«Сәйяр» команданың үз сайты, үз концепциясе һәм үзенең яшәеш фәлсәфәсе бар. Шунлыктан, әгәр хәләл җефетләре җирле сәяхәтләр белән мавыгуны аңламый икән, бу бернинди дә киеренкелек тудырмый:

– Хатыны – Төркиягә, ире – Сарманга... Рәхим итсеннәр! Бернинди буйсындыру яки үгетләү юк. Күчмә тормыш сиңа охшарга тиеш, югыйсә җанга бернинди дә ләззәт бирмәячәк. Әмма безнең сафларда туган як матурлыгыннан ләззәт алмаучылар күп түгел. Гадәттә гаилә белән сәяхәт итәбез, командада балалар, яшьләр күп. Һәр сәфәргә 20–30 ар кеше җыйналабыз. Отпуск вакытын, ял көннәрен, каникулларны җайлап туры китерәбез... Һәм тулысынча туристларча киенепҗыенып, иксез-чиксез ватаныбызның әле кеше аягы басмаган урыннарын өйрәнергә юнәләбез.

«МӘГАРӘЛЕ» ЯЛ

«Сәйяр» команда сайты бүлекләреннән күренгәнчә, алар инде бөтен Россияне диярлек аркылыга-буйга йөреп чыккан. Әмма туган Татарстаннарын алар аеруча үз итә.

– Биредә сезнең иң яраткан урыннарыгыз нинди? Кая барырга киңәш итәсез? – дип кызыксынабыз Әхәттән.

– Миңа бигрәк тә Кама Тамагы мәгарәләре һәм Сарман шахталары ошады. Мөгаен, мин «мәгарәле» ял яратамдыр, – дип елмая капитан.

Без мәгарәләрдә төшкән фотосурәтләрне карыйбыз һәм Сармандагы «Бакыр базына» сәяхәтне бергәләп хәтергә төшерәбез.

ҖИР АСТЫ ПАТШАЛЫГЫ

Әхәт безгә иске рудникның «Бакыр базы» дип аталуын сөйли. Бакыр биредә борын-борыннан чыгарылган, рудник үзе исә XVIII гасырда пәйда булган. «Сәйяр» команда аның төзелү тарихы хакында җирле халыктан берничә төрле фараз ишеткән. Кемдер аны XVIII гасыр башында Төньяк сугыш барганда әсирлеккә төшкән шведлар төзегән, дип саный. Кемнәрдер, үзләренең серле йолаларын кеше күзеннән ераграк яшерү өчен, иске диндәге христианнар бу рудникны казыткан, дип ышандыра.





– Бу төрләр Кызыл китапка кертелгән. Көрән озын колаклы ярканат һәм төньяк зур ярканаты көндез баштүбән асылынган килеш йоклыйлар, әмма телефон яки фонарь яктысыннан уянулары да мөмкин…

– Ә бакалар?

– Бу – очлыбаш бакалар, башка җирдә алар очрамый да. Вакыт-вакыт бакылдап алалар… Һәм бу инде 250 миллион ел буе шулай дәвам итә – галимнәр ышандыруынча, барлык бу таш кантарлар нәкъ шул яшьтә, динозаврларның караңгылыкны яратучы кечкенә яшьтәшләре дә шул гомердән бирле алар арасында яши.

Сәяхәтебез турында сайтка мәкалә язганда, кызыклы мәгълүматка тап булдык: спелеология һәм спелестология буенча Татарстанда үткәрелгән халыкара фәнни-гамәли конференция вакытында галимнәр бу рудникта булган. Катнашучылардан берсе, Италиядән килгән профессор Ивон Джовани рудник турында: «Мин спелеология белән кырык ел шөгыльләнәм инде, әмма Сарманда күргәннәрем миңа иң көчле тәэсир итте. Әлеге рудникка төшү бик кызыклы сәяхәтнең бер өлешенә әйләнергә мөмкин. Бу гади урын түгел, ул тарихи мәгълүматка бик бай һәм кайбер дөньякүләм турлардан кызыклырак та була ала. Бирәдә коммерциягә мөнәсәбәтле туристик комплекс төзергә кирәк, ул борынгы заманнар атмосферасын тою һәм тау токымнары сәнәгате үсешен күзәтү мөмкинлеген бирер иде», – дигән фикер калдырган.

Гомумән, ватаныбызның җир асты тарихы белән танышканда алган тәэсирләрем әле һаман хәтеремдә. Сарман рудниклары кебек гаҗәеп урын башка беркайда да юк. 30 елга якын сәяхәт итүчегә ышанырга буладыр инде.

Тагын берничә фараз бөтенләй дөрескә охшамаган, шунлыктан Әхәт аларны исендә дә калдырмаган. Ни булса да, белгечләр фикеренчә, Сармандагы бакыр базы тау токымнары чыгару эше ядкәре булып тора.

– Анда салкын, караңгы һәм юеш, – дип санап китә Әхәт сәяхәтнең җитешсезлекләрен. – Әмма бу тәэсирләрне көчәйтә генә, – дип, чын финансистларча минусны плюска бик оста әйләндерә ул шул ук арада. – Әлбәттә инде, базга ялланган эшче булып түгел, кызыксынучан турист сыйфатында төшкән очракта. Урамда эссе булса да, җылырак киенергә кирәк. Һәм юл күрсәтүчедән башка мәгарәгә төшмәвең хәерлерәк – адашырга мөмкин, анда җир астында тулы бер лабиринт, тирәнгә ничә метр төшүеңне бер Аллаһ кына белә… Аеруча тәэсирләнүчән хатынкызларны җитәкләп барырга киңәш итәм, югыйсә куркып кычкырудан башлары чыкмас. Мәгарәдә бит ак һәм йомшак җан ияләре түгел, бәлки шомлы ярканатлар һәм сирәк очрый торган бакалар яши.

– Бездә ярканат һәм бака болай да күп бит, нигә әле алар кинәт кенә сирәк очрый торганга әйләнде?



ТАТАРСТАН. ЮГАРЫДАН КҮРЕНЕШ

Автор:
Алёна Кутыркина

2

Түбән Камада техник контроль инженеры булып эшләүче Дмитрий Адкин Татарстанны туган ягы Волгоград өлкәсенә караганда күпкә яхшырак белә. ‹‹Нәкъ менә биредә мин үзем өчен автосәяхәтләрне ачтым һәм дөньяны башка ракурстан күрергә өйрәндем››, – ди сәяхәтче.

– 2014 елда эшем белән бәйле рәвештә мин Татарстанга Волгоградтан күченеп килдем. Моңа кадәр биредә беркая да барганым юк иде, шунлыктан Интернетны ачтым да, республикада нинди кызыклы, истәлекле урыннар булуын эзли башладым.

Әлбәттә инде, беренче максат Казан иде – бу гүзәл кала турында һәркайда сөйлиләр. Аннары исемлектә тарихи Болгар һәм Зөя урын алды. Иң популяр җирләрне карап чыккач, рульдә барганда, юл буенда күргәннәремә игътибар итә башладым. Ә мин сәфәргә күп йөрим – йә өйгә, йә командировкага, йә дуслар белән...

Мин шулай ташландык чиркәүләргә игътибар итә башладым. Биредә алар шактый күп һәм еш кына кыр уртасында калкып тора. Эш буенча бара торган булсам, геопозицияне билгеләп куям да, аннары шул урын турында «Татмитрополия» һәм «Соборы.ру» сайтларыннан укыйм.

Сирәк очрый торган бик матур урыннарның берсе – Татарстан белән Ульяновск өлкәсе чигендәге Танкеевка авылындагы Изге Троица гыйбадәтханәсенә барырга киңәш итәм. Бик истә кала торган гыйбадәтханә. Мин бу чиркәүне өйгә – Волгоградка кайтканда күреп алдым. Өченче тапкыр үткәндә, якынрак барып карарга булдым. Аннары җәен һәм кышын тагын берничә тапкыр булдым.

Мин һәрвакыт фотога төшерү белән мавыктым – нindидер мизгелләрне мәңгеләштереп калу ошый үземә. Дусларым мине «папарацци» дип тә йөртә иде кайчандыр... Сәяхәт итә башлагач, квадрокоптер сатып алдым. Ул гүзәл манзараларны югарыдан күрү һәм гадәти булмаган ракурслардан төшерү мөмкинлеге бирә.

Кама Тамагын, кайбер ташландык чиркәүләрне һәм урбанистиканы квадрокоптер белән төшердем. Түбән Камадагы сәнәгать зонасында төнге утларны төшергәндә, югалттым үзен. Артык еракка җибәргәнмен, күздән югалттым, аның сигналы килми башлады, кире әйләнеп кайта алмады. Бу миңа сабак булды, тик очу теләге беркая да китмәде, шунлыктан яңа квадрокоптер сатып алырга ниятлим. Татарстанда искиткеч гүзәл урыннар бик күп бит әле.

РЕСПУБЛИКА БУЕНЧА ТУРИЗМ – БИК ШӘП НӘРСӘ!

Автор:
Алёна Кутыркина

3

Төрле илләрне күп күргән Нияз Гатауллин Татарстанны Җирдә үзенең иң яраткан урыны дип атый. Икенче урында – Кырым.

– Элегрәк мин фриланста эшләдем. Шунлыктан һәрвакыт сәяхәт итү мөмкинлеге булды. Әмма хәзер дә җәй көне атнасына ике тапкыр мин кая да булса барам.

Сәфәрләр өчен төп рухландыручым – парапланда очу. Мин инде республикадагы һәм Россиядәге бик күп җирләрдә булдым. Шунлыктан минем өчен Татарстан хәзер бик зур тоелмый.

Барлык сәяхәтләрем диярлек кинәт башлана һәм аларга әзерләнү өчен бик аз вакыт китә. Еш кына ниндидер проектлардан да баш тартам, сәяхәт азагында акчам да бетәргә мөмкин, әмма болар барысы да алган тәэсирләр белән чагыштырганда – чүп кенә. Иң мөһиме – эштә кыенлык тудырмау, кайткач, яңа проектка керешергә була.

Машинадан башка сәяхәт итүне күз алдыма да китерә алмыйм. Озын сәфәрләрдә еш кына автомобиль минем өчен хәрәкәт чарасы гына түгел, бәлки ял итү урыны да. Төрле җиргә барып, күңелең булганчы тора аласың.

Яңа урынга килеп җиткәч, әйләнә-тирәне өйрәнергә тырышам. Парапланда очарлык урыннар эзлим. Кышын Татарстанда моның өчен иң әйбәт урын – Зөя таулары. Җәен – искиткеч Кама Тамагы, анда яр күренми һәм чын диңгез өстеннән очкандай буласың. Шулай ук Югары Ослан һәм Печищи дә мәгълүм урыннар. Азнакайдагы Чатыртау, республиканың иң биек ноктасы, алар кадәр үк популяр түгел. Анда байбаклар колониясе яши. Таң калырдай урын!

Шәһәргә якынрак локация кирәк булса, Камай шәһәрлеге яки Иске Казанны атап була. Анда борынгы шәһәрлек, зират, изге чишмә һәм зур дага сыман сөзәклек бар, астыннан Казансу елгасы ага. Һәм ул шәһәрдән бик якында, Биектау районында гына. Бу урыннарны спортчылар – парапланерчылар һәм велосипедчылар үз итә, анда шулай ук бик матур трекинг маршрутлары да бар.

Мин Татарстанны бик яратам һәм без барыбыз да биредә тууыбыз белән бәхетле, дип саныйм. Башка илләрдә һәм төбәкләрдә булганнан соң, мин моны бигрәк тә яхшы аңладым. Табигатебез искиткеч безнең, ә мөмкинлекләр күпме! Бар кешегә дә республика буйлап сәяхәткә чыгарга киңәш итәм. Бездә күз явын алырдый урыннар бик күп.

ҮТКӘНГӘ... БАРЫП КАЙТЫЙК ӘЛЕ!

Автор:
Ольга Туманская

Юкка чыгып барган авыллар романтикасы. Сәяхәт өчен мондый идея ошыймы сезгә? Туристлык маршруты гасырлар аша салына бит. Картадагы шундый нокталарның берсе – Лениногорск районындагы Кузайкино авылы. Мондый сәфәрдә компания дә шуңа ярашлы булырга тиеш – без һәвәс сәяхәтче, «Ташландык Россия» проекты авторы Алексей Ушаковны юлдаш итеп алдык.

КҮҢЕЛЛЕ ЯШӘГӘННӘР...

...Марияне таңнан төрле көтелмәгән хәлләр сагалады бүген. Иртән утын алырга чыккан иде, абынып егыла язды – кемдер пүләннәрне бөтен сарайга таратып ташлаган иде. Мич ягарга тотынды – бөтен төтен өйгә тулды. Морҗаны томалап куйганнар! Ачуы чыкты, ире Николай исә, көлеп, исенә төшерде: «Түз, кодагый, Федорны өйләндерәбез бит!»

Кияү туганнарының йортында кәләшнең якыннары һәм дуслары рәхәтләнеп шаяра ала – туй йоласы шундый. Утынны ишү генә нәрсә, төнлә капканы да сүтеп алып китәргә мөмкиннәр хәтта! Гомумән, мордва туе – берничә көнгә сузылган, билгеле бер кануннар буенча уйналган чын спектакль ул. Кузайкино авылы халкы туйларда нәкъ менә шулай күңел ачкан! Әле күптән түгел генә авыл үзенең күңелле көнкүрешенә күмелеп гомер сөргән, беркем дә бу ияләшкән тормышның әкренләп юкка чыгасын күз алдына да китермәгән...

Бу авылны тиз генә табып та булмый. Гүзәл калкулыклар арасына бик оста яшеренгән ул, Татарстанның Лениногорск районында мондый күркәм үрләр исә –бихисап! Тик бу безнең сәяхәтне мавыктыргычрак кына итә. Беренче тапкырдан Кузайкинога эләгә алмадык – навигатор су юып ашалган грунт юлдан алып китте. Аннан барырга шикләндек, кире борылдык, ышанычлырак юлны таптык, нәтиҗәдә ватылып беткән асфальт юл авылның нәкъ үзәгенә – борынгы гыйбадәтханә янына ук китереп җиткерде. Сүз уңаеннан, маршрутның нәкъ менә шул ноктасы «Ташландык Россия» ютуб-каналы командасы белән очрашу урыны булырга тиеш иде. Әмма алар нигәдер соңарды. Кузайкинода мобиль элемтә бик начар, шунлыктан, ничек кенә тырышсак та, аларга һич тә шалтырата алмагач, әйләнә-тирәне үзебез генә өйрәнә башладык.

4

Фото: Александр Ефремов

Мукшы гореф-гадәтләре турында миңа шул авылның кешесе Анатолий Кондратьев сөйләде. Кайчандыр Лениногорскиның «Заветы Ильича» газетасын җитәкләгән Анатолий Арсентьевич, журналистларча образлы фикер йөртү сәләтен эшкә җигеп, Кузайкинодагы элекке көнкүрешне бик оста тасвирлады. Шунлыктан мин, тып-тын яшел калкулыкларга карап торсам да, аларны түгел, җырлый-җырлый печәннән кайтып баручы арыган, әмма шат күңелле чабаталы кыр хезмәтчәннәрен күз алдыма китердем. Әйе-әйе, юкә чабата Кузайкинода 1960 елларга кадәр аяктан төшмәгән, диләр.

Җирле халык әйтүенчә, кайчандыр Кузайкинода 350 ләп хуҗалык исәпләнгән – йортларны хәтта тауларда да салганнар! Бүген исә нибары егермеләп кеше кыш чыга, калганнары – бакчачылар гына. Биредә медпункт та, кибет тә юк. Күршеләргә генә таянырга кала. Ә бит кайчандыр Кузайкинода җайлы авыл тормышы өчен кирәкле бөтен нәрсә дә булган: кышын күрше-тирә авыл балалары укырга чаңгыда килгән җидееллык мәктәп, берничә кибет, хәтта үз фольклор ансамбле эшләгән клуб, китапханә, медпункт, почтага кадәр… Ә икътисад нинди алга киткән булган биредә! Җирле «Восход» колхозы нык хуҗалыгы – дуңгыз һәм сыер фермалары, ат абзары, умарталык, тавыклары белән мактана алган. Кузайкино кыярлары исә бөтен тирә-якта данлыклы булган. Биредә хәтта карбыз да үстергәннәр! Үзләре үстергән көнбагыштан май сыкканнар – авылда кечкенә генә цех эшләгән.

Гомумән, эш бөтен кешегә җиткән, аннары исә, күпсанлы үзгәртеп коруларга түзә алмыйча колхоз таркалгач, эш беткән. Нәтиҗәдә көтүләр, кырлар һәм башка байлыклар Кузайкинодан башка авылларга күчкән, биредәге тормыш әкренләп сүнгән. Үткеррәк, өлгеррәк егетләр нефть чыганакларына юл токтан – хәтта паспортсыз килеш тә китеп эшкә урнаша алганнар.

2011 елда авылда нибары 53 кеше калган, бүген исә инде тагын да кимегән. Бакчачылар гына хәлне бераз җиңеләйтә – җәен авылга җан керә. Балалары туган нигезләренә җәйге ялга алып кайткан әбиләр эскәмияләргә кунаклашып гәп кора. «Авылга бабайга» каникулга җибәрелгән бала-чага йөгереп уйнап йөри. Авыл юлында әллә нигә бер булса да кемнеңдер автомобиле пәйда була. Әйләнә-тирәдәге табигать исә – искитәрлек! Төрле үлән-чәчкәләр хуш ис тарата, әллә ничә җирдә чылтырап чишмә агып ята, кошлар сайрый, Кузайкино калкулыклары белән исә, тауларга караган кебек, бик озак хозурланып утырырга була.

ЯШЕРЕН УРЫН

Кузайкиноны без генә түгел, «Ташландык Россия» командасы да тиз генә тапмаган, алар бөтенләй Әлмәт районына ук барып чыккан. Анда да Кузайкино авылы бар икән! Анысы да мордва авылы. Бәлки, бу авыллар туганнардыр?

– Әйе, бик мөмкин! – ди биредә яшәүче Григорий Анатольевич. – Бабайлар сөйли иде, элек тауда XVIII гасыр белән тамгаланган ташлар табылган. Әлмәттәге Кузайкинодан бертуганнар килеп, безнең авылга нигез салган, дип тә сөйлиләр иде. Хәер, кайберәүләр, киресенчә, Әлмәт районына бездән күчеп китеп нигез салганнар, дип раслый. Һәрхәлдә, бу атама борынгы эрзя теленнән, чөнки авылга нигез салучы кеше Кузай исемле булган. Бу җирләр гел аулак саналган – һәр авыл тау арасында яки урманда урнашкан. Биредә крепостнойлык вакытында хуҗаларыннан качып китүчеләр килеп яшеренгән, аннары яшәп калган. Аларны беркем дә таба алмаган…

Бүген Кузайкинодагы борынгы заманнар турында ялган рус стилендәге матур таш чиркәү генә хәтерләтеп тора. Ул XX гасыр башында салынган. Гыйбадәтханәнең тарихы – Кузайкиноның үзенең тарихы кебек үк – тулы бер табышмак. Кайбер мәгълүматлар буенча,



чиркәү төзелеп бетмәгән һәм изгеләштерелмәгән. Икенче мәгълүмат буенча, чиркәү эшләгән, җирле халык арасыннан Семен Петров дигән хор җырчысы авыл халкына чиркәү йолаларын үткәрүдә ярдәм иткән.

– Чиркәүне безнең ата-бабаларыбыз салган! – дип сөйли безгә гомере буе Кузайкинода яшәгән Таня әби. – Измәсен аттан таптатканнар. Ничек икәнен белмисезме? Комга балчык кушып, үсмер малай атланган атны шуның өстеннән әйләндереп йөрткәннәр. Нык булсын өчен, элек измәгә йомырка да кушканнар, диләр. Тик мин Кузайкинода болай эшләгәннәрдер, дип уйламыйм, чөнки халык бик зур салымнар түләгән, измәгә салырлык артык йомырка булмагандыр.

Кузайкинода борынгы заманда техникасыз килеш шундый биек гыйбадәтханәләр төзү серен дә белеп була.

– Беренче катын төзегәндә, материалны атларда ничек тә югарырак күтәрү өчен янәшәдә туфрак та өя барганнар, – дип шул серне ача безгә Григорий Анатольевич. – Чиркәү белән бергә янәшәдәге җир өеме дә үскән. Соңыннан аны ишеп таратканнар. Чаңны исә манарага соңыннан катлаулы чыгыр белән күтәрткәннәр.

Бүген чиркәү чаңсыз боегып тора. Гөмбәз урынына – яшел чирәм. Биредә, могҗиза белән сакланып калган чиркәү капкасы янында, без Алексей Ушаков белән очрашабыз.

– Ачыкмы? – дип өметләнеп сорый ул.

– Юк шул.

– Аһ, нинди баскычлар! Ә ишеге! Чүкеп ясалган ишекләр бик аз очрый, биредә исә сакланган. Иске рәшәткәләре дә урынында...

Сатылмас бертуганнар, гаҗәеп эшләр эшләүче һәм имче Косма белән Дамиан хөрмәтенә салынган матур таш чиркәү хәзер аяныч хәлдә. Җирле халык бу Аллаһ оныткан бинаны йозак белән бикләп куйган, түбәсеннән кар һәм яңгыр үтмәсен өчен толь белән каплаган, һәм хәтта төзекләндерү өчен акча да җыя башлаган, әмма эшне ахырга кадәр җиткезергә картларның хәленнән килмәгән.

Совет елларында чиркәүдә склад булган. Башта анда колхоз ашлыгын, аннары инвентарь һәм химикатларны саклаганнар.

– Аны талаучыларның, чаңын кисеп төшерүчеләрнең, тәреләрен алучыларның берсе дә үз үлеме белән үлмәгән, дип сөйлиләр, – дип дәвам итә Анатолий Арсентьевич. – Кемдер асылынган, кемдер суга баткан... Чиркәү бинасы исә барысына да түзгән, исән калган. Нигезен килеп караган белгечләр әле тагын биш йөз ел торачак, дип ышандырып киткән.

УРЫН ЭНЕРГИЯСЕ, КЕШЕЛӘР ҖЫЛЫСЫ

Кузайкино сыман җирләр маҗара эзләүчеләрне үзенә тартып, ымсындырып тора. Алексей Ушаков – шундыйларның берсе.

– Миңа бар нәрсә дә кызык! Иң мөһиме – шәһәрдән чыгып китү һәм авылга барып җитү! – дип елмая ул.

Алексейның ташландык авылларга мәхәббәте тарихны яратуыннан һәм үз балачагын сагынудан башланган. Орел өлкәсендәге хәзер инде юкка чыккан диярлек туган авылы йөрәгенә бигрәк тә якын. Ул ел саен анда кайта һәм кайчан да булса барыбер торгызырга өметләнә. «Ташландык Россия» каналы шул идеядән башланган да инде.

– Кызганыч, илебездә ташландык авыллар бик күп, әмма Татарстан башка төбәкләрдән аерылып тора

Иван Григорьевич Фадеев белән хатыны Мария – Кузайкино авылының иң карт кешеләре. Җирле халык белән аралашу – авыл маршрутлары буенча сәяхәт итүчеләр өчен үзенә бер ләззәт.

кебек. Сездә, киресенчә, нык, төзек авыллар күп – әллә төбәгегез баерак, әллә халык гореф-гадәтләрне санлап яши.

Мондый сәяхәтләрдә әллә нинди хәлләр булырга мөмкин, дип сөйли Алексей. Бервакыт ташландык пансионатта аны түбәдә йөрүче кешенең аяк тавышлары ишетелеп шомландырган. «Хулиганны» берничек тә күрә алмаган. Видеоны каналга йөкләтеп куюга ук, андагы әрәкләр турында хәбәрләр килә башлаган! Тагын бер юлы ташландык авылдагы бер йортта эшләп торган телевизорга тап булган. Әйләнә-тирәдә исә беркем дә юк икән! Гомумән, мондый маршрутта нәрсә көтүен беркайчан да алдан белеп булмый, ди ул.

Менә без дә кычыткан һәм балтырган әрәмәлеге аша туп-туры җимерелгән йортка якынлашабыз. Эчтә – кайчандыр кайнаган тормыш эзләре. Баз капкачы ачык, анда – төлке. Тавык аулау шулай аяныч тәмамланган. Ватык савыт-саба, өстәл, сәке. Узган гасырдан сәлам биргән сыман сәндерә тора...

Ә бит авыл мәктәбенә өстәп салынган бу янкормада кайчандыр тормыш гөрләп торган! Тәмле аш исе бала-чаганы үзенә ымсындырган. Тәрәзә төбендә алмагачлар чәчәк аткан, карлыган, крыжовник, чия, кура җиләге, бәрәңге үскән. Мәктәп балалары биредә практика үткән. Үстерелгән яшелчә һәм җиләк-җимешне сатудан кергән акчага мәктәп печенье һәм конфетлар сатып алган, бәйрәмнәрдә укытучылар сабыйларны шул тәм-том белән сөендергән... Бу турыда кайдан белдегез, дисезме? Җирле халык сөйләде әлбәттә!

– Бервакыт исә без бер сәер бабайны очраттык. Ул үз авылын шулкадәр яраткан ки, үзеннән нинди дә булса бер хатирә калдырырга булган, – дип сөйли Алексей. – Күз алдыгызга китерәсезме, ул бик күп чыршы агачы утырткан!

Бәлки, без мондый сәфәрләрдә урыннар һәм кешеләр аша әнә шул үткән көннәр хатирәсен тою мөмкинлеген эзлибездер? Аларга орынасыбыз киләдер безнең...

PRESSA

КИТАП К



ИШТӘСЕ

Фотолар: mybook.ru, www.livelib.ru сайтларыннан

Автор: Луиза Янсуар

ЕРАКТАГЫ ЯКЫН ЯЗМЫШЛАР

Агымдагы елда CORPUS нәшрияты күңелгә хуш килерлек яңа басмалары белән сөендерүен дәвам итте. Бу санда шуларның берсенә тукталып узабыз.

НИДЕРЛАНД ӘЛМӘНДӘРЕ

Китап үзенең кәефе, атмосферасы белән Фредрик Бакманның Уве исемле карт турындагы әсәрен хәтерләтә. Хендрик Грун да, Уве шикелле үк, киребеткән, үзсүзле, тыштан циник булып күренергә тырышса да, асылда бик нечкә күңелле, романтик рухлы картлач.

Хендрик Грун турындагы әсәрен автор көндәлек язмалары рәвешендә тәкъдим итә. Бу – бик уңышлы алым, шул рәвешле, без сукранучан картның тормышын үтә вак, әмма бик тә әһәмиятле детальләр аша бербөтенгә җыябыз. Аның караш ноктасы аша дөньяга, Грунны әйләндереп алган мохиткә, чынбарлыкка карыйбыз, һәм инде колачлырак ракурс алып, иҗтимагый яссылыкка чыгабыз.

Сүз уңаеннан, Хендрик Грун турындагы романнарның гаять зур популярлык казануында нәшриятлар белән авторының сер тудыруы да зур роль уйнагандыр, дип фаразларга урын бар. Ләкин эш анда гына түгел, әлбәттә, чөнки бу әсәрләр һәр кешене тирәннән торып уйланырга һәм үзенә янә бер мәртәбә күз ташларга мәҗбүр итә: тукта, минем дә яшисем, картаясым бар, алда ни көтә...



Хендрик Грун – Питер де Смет исемле Нидерланд язучысының псевдонимы. Ул картлар йортында яшәүче 83 яшьлек Хендрик Грун исемен кулланып, роман яза. Әлеге китап чын мәгънәсендә ажиотаж тудыра. 2014 елда чыккан басманың уңышыннан соң, 2016 елда Питер де Смет шаян карт турында икенче китабын язып тәмамлый. Бүгенге көндә беренче китап 36 телгә тәрҗемә ителгән, икенчесе – 16 телгә. Нидерландта бу роман буенча спектакльләр куела һәм 24 эпизодтан гыйбарәт 2 сезонлы сериал төшерелә. 2016 елда әсәр Hebban Best Novel премиясенә лаек дип табыла. Хендрик турындагы маҗаралар рус теленда 2019, 2020 елларда басылып чыкты. Тагын бер кызыклы факт: Питер де Смет, китабы дөнья күргәннән соң, озак вакыт үзенең автор булуын ачмый. 2016 елда Нидерландның 2 газетасы авторның 62 яшьлек Питер де Смет булуы хакында язып чыга, әмма язучы үзен борчымауларын үтенә: «Миңа дан-шөһрәт белән бәйле мәтавыклар бөтенләй кирәкми», – ди ул.

Нидерландтагы 60 нчы елларда төзелгән бер картлар йортында гомер кичерүче картларның яшәү принциплары нәкъ безнең Туфан абый тудырган Әлмәндәренекечә: соңгы мизгелгәчә үз тормышыңа һәм зиһенеңә хуҗа булып калу. Грун аларны мондыйрак рәвештә билгели:

– үзеңә үзең юаныч табарга өйрән, күңелеңне ачар өчен клоун килгәнен көтмә;

– шәхси бәхет сине 83 яшьтән соң да эзләп табарга мөмкин;

– борынын салындырып йөргән кешене берәү дә сөйми һәм дөрес эшли;

– теләсә нинди очракта да үз дәрәҗәңне саклап калырга тырыш.

Әлеге принциплар Хендрикны иң өметсез чакларда да рухын төшермәскә өнди. Без аның белән бергә картлар йортындагы башка картлар һәм карчыклар, шулай ук персонал белән танышабыз, көләбез, шаярабыз, моңаябыз, кайгырабыз, шукланабыз, уйланабыз…

Әсәр Хендрикның башына яңа идея килүдән башланып китә. Ул да булса: картлар йортында хөкем сөргән кануннарга яраклашып кына яшәүне күңелсез дип тапканга күрә, үз клубларын булдыру. Бу идея даими процедураларга йөреп, тышкы дөнья белән бәйләнештән мәхрүм булып яшәгән иптәшләренең күңеленә дә хуш килә, аларны дәртләндереп җибәрә. Клубка исем дә шунда ук табыла: СНОНЕМ. Ягъни, картлар, әмма әле үлеләр түгел дигәнне аңлата ул (Старые, Но Не Мертвые). Шулай итеп, клуб әгъзалары үз кануннары буенча яши башлый һәм… тормышның шушы яшьтә дә дарулар, ялгызлык кебек күңелсез нәрсәләрдән генә түгел, ә бик тә кызыклы мавыгулардан торуын ачалар үзләре өчен.

СНОНЕМ әгъзаларының төп конфликт объекты – картларны бер аягы белән кабер якасында тора, шуңа күрә ябылуда сакларга кирәк дип тапкан авторитар рухлы директриса. Әнә шул директрисага каршы тору йөзеннән, аквариумдагы балыкларны пирог ашатып агулаудан башланган шуклыклар акрынлап колачлырак масштаб ала. Әмма «инкыйлаб»ка әверелүдән бигрәк, һәркем өчен файдага әйләнә: әйтик, Грун яңа дуслар, фикердәшләр таба, тирәлегендәге картлачларның шактый кызыклы шәхесләр булуын ачыклый, айподны үзләштерә, 79 яшьлек искиткеч гүзәл Эфье белән аралашып китеп, гомере буена көтеп җиткерә алмаган мәхәббәтен таба. Һәм хәтта балачакта ук һәлак булган кызы турындагы кайгысын да онытып җибәрә…

Безнең приют 60 нчы еллар азагында – балаларның картайган әти-әниләрен үзләрендә асрар өчен вакыты бөтенләй калмаган чорда төзелгән. Хәер, кем белә, бәлки, вакыты булса да, теләге калмаганга… Кемнәрдер аларны гаепли, минем мондый фикер уемда да юк. Озын сүзнең кыскасы, 40 ел элек картлар йортлары бездә яңгырдан соң гөмбәләр үсеп чыккандай күбәйгән.

Ә бит, уйлап карасаң, менә дигән ният! 24 квадрат метрлы кетәклекләр, санузел белән кухнясы да – үзендә. Парлы картларга гомумән балда-майда йөзәрлек: аларга йокы бүлмәсе өчен өстәмә 8 метр бирелә. Егерме ел эчендә йортка хәтта косметик ремонт та ясалган! Шунысы гына яман: тәгәрмәчле транспортны йөртү каралмаган. Лифтта берьюлы 2 скутмобиль белән 4 ходунок сыярлык кына урын бар. Аларны кертү-чыгару өчен дә бер гомер вакыт китә… Шуңа лифтлар янындагы чиратның иге-чиге юк…

Мин соңгы вакытка кадәр баскычтан йөрүне кулай күрә идем. Әмма хәзер, хәлем бик тиз беткәнгә, башкалар белән бергә лифтка чират торырга мәҗбүрмен. Шулай көтеп торган сәгатьләрнең берсендә башыма уй килде: алай-болай янгын чыга калса, бирелә барыбыз да тереләй яначак. Персоналдан кала, безнең ишеләргә эвакуация ясарга өлгермәячәкләр…

Менә шушындый акыллы-зирәк уйланулар, күзәтүләрдән гыйбарәт көндәлекләрне уку – моңсу да, бернигә карамастан, күңелле дә. Хендрик карт бер генә җирдә дә зарланмый, пошынмый, берәүне дә гаепләми. Бәя биргәндә дә, үзенә генә хас булган янып торган ирония, сарказм белән эш итә ул.

Китапның башыннан ахырына кадәр бу картларның маҗаралары белән яшисең, һәм ике романны да бер сулышта укып чыгуыңны сизми каласың. Әйтерсең, әле генә мушкетерлар турындагы Дюма романын укып чыккансың…

Грун каһарманына хас булган үзирония, яшьме син, картмы, үзеңә булган карашны да яңадан күздән кичерергә әйди. Менә ничек бәяли ул үзен:

Минем исәпләрем буенча, коридорлардагы уртача тизлек сәгатенә 2 километрны тәшкил итә. Ә мин кыска дистанциядә әле дә 4 километрны ваклыйм. Пенсионерлар арасында мин – чын гепард.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 54нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Рәис Хисамов, «Татнефть» ГАҖ генераль директоры урынбасары – баш геологы, Татарстанның атказанган геологы, Россиянең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре, август аенда 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Шамил Яһудин,
«Татнефтепром-Зузэйнефть» АҖ генераль директоры, VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты

Татарстан нефть сәнәгатенең абруйлы кешесе

– Бу истәлекле көндә шәхсән үз исемемнән һәм компаниябез хезмәткәрләре коллективы исеменнән иң ихлас котлауларны кабул итегез!

Республика файдасына кылган хезмәтегез өчен бүген Сезгә хөрмәт һәм ихтирам сүзләрен җиткерәсем килә. Сез гаять мөһим эш – Татарстан сәнәгатен үстерүгә бөтен көчегезне юнәлттегез һәм үз һөнәрегездә зур уңышларга ирештегез. Скважина операторыннан башлап, җитәкче вазыйфаларга кадәр озак һәм мактаулы хезмәт юлы үтеп, менә инде 20 елдан артык Сез Татарстанның иң эре нефть компаниясендә генераль директор урынбасары, «Татнефть» ГАҖнең баш геологы булып эшлисез. Сез зур җаваплылыкка, осталыкка, тирән белемгә, аналитик фикер сөрешенә, республика территориясендә кара алтын чыгару эшендәге зур гамәли тәҗрибәгә ия булуыгыз белән аерылып торасыз.

Татарстан Республикасының атказанган геологы, Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре, «Татнефть» ГАҖнең Мактаулы нефтьчесе кебек күпсанлы исемнәр һәм бүләкләр – югары дәрәҗәгезнең, шиксез абруегызның, туган йортыгыз – Татарстан каршындагы казанышларыгызның иң яхшы дәлиле. Мин Сезгә зур ихтирам белән карыйм, теләсә кайсы мәсьәләне хәл итүдә ышанычлы эш йөртүегезне һәм һөнәри осталыгыгызны зур соклану белән телгә алам.

Хөрмәтле Рәис Салихович! Сезгә ният-планнарыгызны тормышка ашыруда яңадан-яңа уңышлар, җиңүләр һәм якты тәэсирләр телим! Үзегезгә һәм гаиләгезгә бәхет, иминлек, уңышлар, нык сәламәтлек насыйп булсын!

Фото «Татнефтепром-Зузэйнефть» АҖ тарафыннан бирелде

Марат Насыйбуллин,
«Кара Алтын предприятиесе» ЯАҖ генераль директоры

Республика масштабындагы хезмәт

– Хөрмәтле Рәис Салихович!

Шәхсән үз исемемнән һәм предприятие хезмәткәрләре коллективы исеменнән иң ихлас котлауларны кабул итегез!

Гомер юлыгыздагы әлеге истәлекле көн белән котлап, Сезгә, республика үсеше өчен күп көч куйган кеше буларак, хөрмәтемне белдерәсем килә. Татарстанның кара алтынын чыгару, нефть ятмаларын тикшерү – максатчан кешеләр һәм кыю романтиклар өчен туры килә торган һөнәр. Сезне һичшиксез нәкъ менә шундыйлар исәбенә кертә алабыз. Сез үз тормышыгызны юмарт төбәгебезнең табигый байлыкларын өйрәнүгә багышладыгыз, республиканың нефть сәнәгатен үстерү һәм модернизацияләү эшенә бөтен көчегезне бирдегез. Бай тәҗрибә, шәхси абруй һәм мактауга лаек шәхси сыйфатлар Сезгә «Татнефть» ГАҖ структурасында зур нәтиҗәләргә һәм җитәкче вазыйфаларга ирешергә мөмкинлек бирде. Компаниянең генераль директоры урынбасары, баш геологы вазыйфасында Сез мөһим эш – нәтиҗәле, керемле рәвештә нефть чыгару өчен ятмалар эзләүне стратегик планлаштыру белән шөгыльләнәсез.

Сезне республика олуг остаз, чын ватанпәрвәр һәм үткен акыллы җитәкче буларак белә. Нефтьчеләрнең профессиональ берләшмәсе тәҗрибәгезне, зирәклегегезне һәм ышанычлы хезмәтегезне чиксез хөрмәт итә.

Хөрмәтле Рәис Салихович! Юбилей көнендә эшегездә уңышлар, Сезгә һәм якыннарыгызга күңел күтәренкелеге, бетмәс-төкәнмәс энергия, ныклы сәламәтлек телим!

КАРА АЛТЫН

Реклама
Фото «Кара Алтын предприятиесе» ЯАҖ тарафыннан бирелде

Татьяна Ларионова, VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «ТР Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен торгызу республика фонды» КБО башкарма директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, июльдә үзенең юбилеен билгеләп үтә.

Фото «Казан Гипронииавиапромы» АҖ тарафыннан бирелде Реклама

Борис Тихомиров, «Казан Гипронииавиапромы» АҖ генераль директоры

Казанский Гипронииавиапром

Татарстан үсеше хакына

– Хөрмәтле Татьяна Петровна!

Шәхсән үз исемемнән һәм предприятие хезмәткәрләре коллективы исеменнән иң ихлас котлауларымны кабул итегез!

Бу истәлекле көндә Татарстанны һәм аның дәүләт институтларын үстерүгә керткән өлешегез өчен Сезгә олы рәхмәтемне җиткерәсем килә. VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары сыйфатында Сез хакимият вертикален ныгыту, икътисадны һәм сәнәгатьне модернизацияләү, җәмгыятебезнең мөһим проблемаларын хәл итү юнәлешендә мөһим эшләр башкарасыз. Хезмәтегез нәтиҗәсе буларак, республикада иҗтимагый инициативалар һәм хәйрия акцияләре актив рәвештә гамәлгә ашырыла. «ТР Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен торгызу республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасының башкарма директоры вазыйфасында исә Сез республикабызның тарихи мирасын киләчәк буыннар өчен саклау юнәлешендә зур эш алып барасыз. Сезне тирән белем һәм аралашучанлык, җаваплылык һәм шәхси мөлаемлык аерып тора.

Хөрмәтле Татьяна Петровна! Татарстан өчен мөһим вазыйфагызда Сезгә киләчәктә дә уңышлар юлдаш булсын! Үзегезгә һәм туганнарыгызга сәламәтлек телим!

Фото «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ тарафыннан бирелде Реклама

Илшат Ганиев, «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры

Гаделлек һәм кешелеклелек

– Хөрмәтле Татьяна Петровна!

Сезне чын күңелдән үземнең һәм комбинатыбыз хезмәткәрләре исеменнән юбилеегыз белән котлыйм!

Бүген без Сезне – чып-чын эшсөяр хатын-кызны хөрмәтлибез. Дәүләт хезмәтендә ирешкән уңышларыгыз һәм социаль эш тәҗрибәгез, VI чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары буларак республика парламентындагы закон чыгару эшчәнлегегез һәркемгә яхшы билгеле. Күпләр сезне аралашучан һәм зирәк, гадел һәм максатчан шәхес кенә түгел, ә игелекле йөрәк иясе буларак та белә. Сез аз керемле гражданнар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен хәйрия чараларын арттыру һәм аларга ярдәм итүгә аеруча игътибар бирәсез. Сез шулай ук Татарстанның бай тарихи мирасын саклау белән дә мәшгуль: «ТР Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен торгызу республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасының башкарма директоры вазыйфасында башкарган эшләрегез бихисап.

Татарстанның экологик чиста яшелчә продукциясе җитештерү буенча алдынгы предприятиеләренең берсе буларак, без республиканың азык-төлек иминлеген тәэмин итүчеләргә – авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә ярдәм итү эшенә керткән өлешегез өчен дә рәхмәтле без Сезгә.

Хөрмәтле Татьяна Петровна! Җаваплы эшегездә алга таба да яңа үрләр яуларга һәм иң колачлы, кыю планнарны тормышка ашырырга насыйп булсын! Сезгә һәм якыннарыгызга уңышлар, бәхет һәм сәламәтлек телим!

Шамил Яһудин,
«Татнефтепром-Зузәйнефть» АҖ генераль директоры, VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты

Лаеклы юл

– Хөрмәтле Татьяна Петровна!

Шәхсән үз исемемнән һәм компаниябез хезмәткәрләре коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм!

Бу истәлекле көн аерым әһәмияткә ия, чөнки ул ирешкәннәрне күздән кичерергә мөмкинлек бирә һәм алданиләр көткәнлеге турында уйланырга этәрә. Талантлы һәм тәҗрибәле белгеч, республикабызга хезмәт итү өчен бөтен көчен биргән оста оештыручы буларак, тормыш юлыгыз мактауга лаеклы. Сез – уңыш казанган дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, депутатлык эшендә һәм законнар чыгаруда танылган белгеч, республика масштабындагы күренекле сәясәтче. Сезгә лидерлык сыйфатлары, гаделлек һәм җаваплылык, аралашучанлык һәм алдан күрүчәнлек кенә түгел, ә табигый хатын-кыз мөлаемлыгы һәм сизгерлеге дә хас.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы буларак, Сез республикада хакимият вертикален ныгыту һәм парламентаризмны үстерү өчен күп эш башкардыгыз. Сезнең белән якыннан аралашып торуыбызга һәм күптәнге танышлыгыбызга ихлас куанам, шәхси һәм һөнәри сыйфатларыгызны чиксез ихтирам итәм.

Хөрмәтле Татьяна Петровна! Җаваплы эшегездә Сезгә һәрвакыт уңышлар юлдаш булсын, ә оптимизм, бетмәс-төкәнмәс энергия һәм күтәренке рух Сезне һәрвакыт озата барсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек һәм күңел тынычлыгы телим!

Фото «Татнефтепром-Зузәйнефть» АҖ тарафыннан бирелде

Рөстәм Нуриев,
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башлыгы

Эшлекле хезмәттәшлек өчен рәхмәт!

– Хөрмәтле Татьяна Петровна!

Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм!

Дәүләт һәм җәмәгать эшчәнлеге өлкәсендә күпкырлы хезмәтегез Татарстан Республикасы җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнде. Сез җаваплы, белемле җитәкче һәм тәҗрибәле оештыручы буларак лаеклы рәвештә зур абруй казандыгыз. Республиканың җаваплы вазыйфаларында ихлас бирелеп эшләвегез һәм алга куелган мәсьәләләрне чишкәндә даими рәвештә нәтиҗәле юллар эзләвегез коллегаларыгызның һәм Сезнең кул астында хезмәт куючыларның лаеклы хөрмәтен казанды.

Сез күп еллар җитәкче вазыйфалар башкарасыз, бай тәҗрибәгезне уртаклашып, иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр үсешенә актив ярдәм күрсәтәсез. Андый оешмалардан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар иҗтимагый берләшмәсе белән җитәкчелек итүегезне искә алу урынлы.

Алабуга муниципаль районында сезнең бу юнәлештәге һәрьяклы ярдәмегез социаль яктан авыр хәлдә булган гаиләләргә ярдәм күрсәтүне активлаштырырга һәм Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан аеруча актуаль «Сугышның хатын-кыз йөзе юк» проектын гамәлгә ашырырга булышты.

Сезнең эшлекле киңәш-ярдәмегез белән алабугалылар тормышының төрле тарафларын яхшыртуга юнәлтелгән күп кенә мөһим социаль проектлар чынга ашырыла. Алабугада көндәшлеккә сәләтле мәгариф үзәге булдыруны күздә тоткан полилингваль мәктәп һәм өлкән буын вәкилләренең тормыш сыйфатын яхшырту өчен гериатрия кабинеты ачу – шуларның ачык мисалы.

Алабуга муниципаль районы тормышында актив катнашуыгыз өчен без Сезгә ихластан рәхмәтле һәм киләчәктә дә нәтиҗәле хезмәттәшлеккә өметләнәбез.

Сезгә чын күңелдән иҗади уңышлар, барлык уй-ниятләрегезнең тормышка ашуын, нык сәламәтлек, бәрәкәт телим! Сезгә хас, тормыш энергиясе һәм рух күтәренкелеге беркайчан да төкәнмәсен, барлык изге ният-гамәлләрегез киләчәктә дә югары бәяләнсен!

Фото Алабуга муниципаль районы хакимиятеннән алынды

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖнең
генераль директоры

Фото «Грань» ҖЧҖннән алынды Реклама

– Хөрмәтле Татьяна Петровна!

«Грань» ҖЧҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Югары дәүләт вазыйфасында Сез бөтен көчегезне белемнәрегезне, бай тәҗрибәгезне республика өчен әһәмияте зур булган бурычларны хәл итүгә бирәсез. Сезнең кебек үз эшенә тугры һөнәр осталарының тырышлыгы белән Татарстан алга бара һәм чәчәк ата: республиканың тарихи мирасын саклау буенча зур эшләр башкарыла, киңкүләм проектлар тормышка ашырыла һәм халыкның тормыш-көнкүрешен яхшырту өчен шартлар тудырыла.

Без Сезне кыенлыклар алдында югалып калмый, иң кыю проектларга да курыкмыйча алына торган кеше буларак беләбез. Сезнең оештыру сәләте, таләпчәнлек һәм тәвәккәллек кебек сыйфатларыгыз тирән хөрмәт хисләре уята, ә инде кешеләрне берләштереп, аларны үзегезнең фикердәшләрегез итә белүегез Сезнең абруйның нигезендә ята.

«Грань» ҖЧҖ коллективы Сезгә озак еллар дәвамында уңышлы хезмәттәшлек, «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» белән «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» проектларын тормышка ашырганда, һәрьяклап күрсәткән ярдәмегез һәм текләктәшлек итүегез өчен чын күңелдән рәхмәтле. Без уртак эшебезне бик югары бәһалибез!

Чын күңелдән Сезгә эшчәнлегегездә һәрвакытта да бетмәс-төкәнмәс көч һәм иҗат илһамының юлдаш булуын телим! Эшегездә фидакарьлегегез барлык максатларга ирешү мөмкинлеге бирсен, ә инде тормышка аек акыл һәм күтәренке күңел белән каравыгыз алга таба да уңышларга гына китерсен!

Үзегезгә һәм гаиләгезгә ныклы сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим!

Илнур Сәгъдиев, «Казанкомпрессормаш» ГАҖнең (ГМС төркеме) идарәче директоры, июль аенда үзенең 45 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Ышанычлы лидер

Игорь Бабушкин,
«ЭРА» Яшел Үзән предприятиесе» АҖ генераль директоры

Фото «ЭРА» Яшел Үзән предприятиесе» АҖннән алынды Реклама

– Хөрмәтле Илнур Илдарович!

Шушы истәлекле көнне безнең предприятиенең хезмәткәрләр коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән котлыйм!

Сезгә зирәк акыллы җитәкче, үз һөнәренең остасы булуыгыз, кешелеклелек сыйфатларыгыз өчен үземнең тирән соклануымны белдерәсем килә. «Казанкомпрессормаш» ГАҖнең идарәче директоры вазыйфасында Сез республиканың машина төзү сәнәгатен үстерү белән шөгыльләнәсез, коллективны яңа нәтиҗәләргә юнәлдерәсез, җитештерүгә яңа технологияләр кертеп җибәрәсез. Сез ышанычлы, нәтиҗәле итеп җитәкчелек итә беләсез, практик тәҗрибәгез, эшкә сәләтлелегегез һәм хезмәттә шәхси үрнәк күрсәтүегез белән аерылып торасыз. Сезгә лидер булу өчен кирәкле сыйфатлар – максатчанлык һәм еракка карап эш итә белү хас.

Сез озак еллар Яшел Үзән мотор заводының компетентлы белгече, соңрак җитәкчесе булдыгыз, аннан соң Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль район Советы депутаты буларак, Яшел Үзән территориясендә көндәлек тормышны яхшыртуга керткән саллы өлешегезне аерым билгеләп үтәм. Без, суднолар төзү тармагының иң ышанычлы предприятиесе вәкилләре, Сезнең Татарстан иминлеге хакына башкарган эшегез өчен рәхмәтле. Танышь булуыбыз һәм тыгыз аралашуыбыз өчен бик шатмын.

Хөрмәтле Илнур Илдарович! Һөнәри эшчәнлегегездә зур уңышлар телим! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет, иминлек һәм сәламәтлек телим!

Нурислам Сюбаев, «Татнефть» ГАҖ генераль директорының стратегик үсеш буенча урынбасары, август аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Һөнәри осталык – принцип буларак

Марат Насыйбуллин,
«Кара Алтын предприятиесе» ЯАҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Нурислам Зиннәтович!

Юбилей уңаеннан предприятиебез хезмәткәрләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән җылы котлау сүзләрен кабул итеп алыгыз!

Бу истәлекле көн Сезгә Татарстан халкы иминлеге хакына башкарган эшләрегез һәм сирәк очрый торган кешелеклелек сыйфатларыгыз өчен ихтирам һәм хөрмәт сүзләрен җиткерү өчен менә дигән форсат. Сез язмышыгызны финанслар белән бәйләгәнсез, базар шартларында танылу алган эксперт булып торасыз, дөрес карарлар кабул итә беләсез һәм аналитик фикерләү сәләте белән сокландырасыз. «Татнефть» Гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының стратегик үсеш буенча урынбасары вазыйфасында Сез илнең иң уңышлы нефть компанияләренең берсе – Татарстанның нефть сәнәгате флагманында иң мөһим мәсьәләләрне хәл итәсез. Сезнең банк тармагындагы кредит-финанс учреждениеләрендә олы тәҗрибәгез бар, бизнеста эшлеклелекне һәм иҗадилыкны нәтиҗәле итеп куллана беләсез. Сезнең ни дәрәҗәдә киң эрудицияле, эшкә сәләтле булуыгыз, җаваплылыгыгыз турында бик күпләргә мәгълүм.

Безнең кече нефть компанияләре арасында иң эреләрдән саналган предприятие Нурлат, Әлмәт, Түбән Кама районнарында нефть чыганакларын эшкәртә, нефть чыгаруның барлык җитештерү-технологик циклын башкара. Без Сезгә Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе тармагын үстерү юнәлешендәге эшчәнлегегез өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Хөрмәтле Нурислам Зиннәтович! Ихлас йөрәктән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм һәм Сезгә һөнәри эшчәнлегегездә зур уңышлар телим! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет, уңышлар, сәламәтлек юлдаш булсын!

Реклама
Фото «Кара Алтын предприятиесе» ЯАЖ нан алынды

Сүз һәм эш кешесе

Александр Бабынин,
«ИНКО-ТЭК» ЖЧЖ директоры

– Хөрмәтле Нурислам Зиннәтович!

«ИНКО-ТЭК» ҖЧҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Җитәкчелек итү, һәр кылган гамәле, башкарган эше белән игътибар үзәгендә торган шәхес, үз сүзенең хуҗасы булу җиңел түгел! Яраткан эшегезнең алга таба үсеше һәм чәчәк атуы күп яклап Сезнең нинди каралар кабул итүегездән тора!

Ирешелгән уңышлар яңа казанышларның нигезе булсын, ә башлангычларыгыз һәрвакытта да хезмәттәшләрегез һәм дусларыгыз тарафыннан аңлау, хуплау тапсын, дип телим!

Үзара дустанә мөнәсәбәтләр безнең уртак максатларыбызны озак вакытлы, нәтиҗәле һәм файдалы хезмәттәшлеккә китерер дип өметләнәм!

Сезнең өчен шушы истәлекле көндә яхшы кәеф, күңел күтәренкелеге, уңышлар һәм оптимизм, ныклы сәламәтлек, иминлек, бәхет һәм яңа иҗади очышлар телим.

Һәрбер эшегезгә уңыш юлдаш булсын! Тормышыгызның һәр яңа көне игелектә һәм бәхеттә үтсен, Сезгә иҗади һәм һөнәри җиңүләр өчен көч һәм егәр бирсен, барлык планнарыгызны һәм ниятләрегезне гамәлгә ашырсын!

Сезгә ныклы сәламәтлек, нәтиҗәле хезмәт, шәхси тормышыгызда иминлек һәм киләчәккә күңел күтәренкелеге телим!

Реклама
Фото «ИНКО-ТЭК» ЖЧЖ ннан алынды

Радик Хәсәнов, «Серго исемендәге завод» Җитештерү берләшмәсе» АҖнең генераль директоры, ТРның атказанган машина төзүчесе, РФнең мактаулы машина төзүчесе, июль аенда үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Фото «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖнең алындан   Реклама

Рафинат Яруллин, «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖнең генераль директоры

ТАТНЕФТЕХИМИНВЕСТ ХОЛДИНГ

– Хөрмәтле Радик Шәүкәтович!

Бу истәлекле көндә «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ хезмәткәрләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз уңаеннан иң җылы котлауларны кабул итеп алыгыз!

Сез нефть химиясендә эшли торган хезмәткәрләр алдына җитештерелүче продукциянең сыйфатын яхшыртуны, эшләнмәләрнең үзкыйммәтен киметүне төп бурыч итеп куя белгән машина төзүчеләрнең берсе. Сезнең кул астында җитештерүчеләрнең көчле командасы тупланган, уку йортлары һәм яшьләр белән эшләү буенча бай тәҗрибәгез бар.

Сезнең Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының үсешенә керткән өлешегез дә зур. «Серго исемендәге завод» Җитештерү берләшмәсе» АҖнең генераль директоры буларак, Сез районны эш урыннары белән тәэмин итәсез, район халкы өчен оештырылган иҗтимагый һәм хәйрия акцияләрендә даими катнашучы булып торасыз.

Хөрмәтле Радик Шәүкәтович! Сезгә Татарстан иминлеге хакына җаваплы вазыйфагызда яңада-яңа һөнәри уңышлар телим! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет, күңел күтәренкелеге, уңышлар һәм ныклы сәламәтлек юлдаш булсын!

Ышанычлылык һәм һөнәри осталык

Фото ТР Яшел Үзән МР Башкарма комитетыннан алынды

Михаил Афанасьев, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

– Хөрмәтле Радик Шәүкәтович!

Яшел Үзән муниципаль районы хакимиятенең барлык хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Бүген Сезгә бөтен илдән котлау телеграммалары килә, Сезнең хөрмәткә җылы сүзләр яңгырый, мин аларның барысына да кушылам. Яшел Үзән җире Сезнең кебек ватанпәрвәр, булдыклы, республика дәрәҗәсендәге җитәкче улы белән горурлана. Сез бөтен гомерегезне эшче һөнәрләргә, Татарстанның һәм Россиянең машина төзү тармагын үстерүгә багышлагансыз. «Серго исемендәге завод» Җитештерү берләшмәсе» АҖнең генераль директоры вазыйфасында Сез район икътисады үсешенә, район халкының тормыш сыйфатын яхшыртуга зур өлеш кертәсез, кешеләрне эш урыннары белән тәэмин итәсез.

Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе буларак, район мәнфәгатьләренә карата игътибарыгызны, Яшел Үзән иминлеге хакына нәтиҗәле хезмәттәшлегегезне аерым билгеләп үтәсем килә. Сезнең белән үзара тыгыз аралашуыбызга шатмын, талантлы җитәкче, олы һөнәр остасы һәм ышанычлы шәхес булуыгызга сокланам.

Хөрмәтле Радик Шәүкәтович! Һөнәри эшчәнлегегездә алга таба да уңышлар, үзегезгә һәм гаиләгезгә ныклы сәламәтлек телим!

Өзлексез хезмәт һәм камилләшү үрнәге

Илшат Ганиев,
«Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖнең генераль директоры

– Хөрмәтле Радик Шәүкәтович!

Безнең теплица комбинаты коллективы хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Бүген Сезгә, башкарган эшләрегез, кешелеклелек һәм һөнәри сыйфатларыгыз өчен ихтирам сүзләрен әйтеп, намуслы кеше булуыгызга соклануымны белдерәм. Сез туган Татарстаныбыз иминлеге хакына бөтен көчегезне бирәсез, республиканың Яшел Үзән муниципаль районы үсешенә күркәм эшләр башкарасыз. Сезнең дәүләт хезмәтендәге, машина төзелеше тармагындагы олы тәҗрибәгез, оештыру сәләтегез турында бик күпләргә мәгълүм. Тормыш юлыгыз – өзлексез хезмәт, максатчанлык һәм ватанпәрвәрлек үрнәге. Эшче һөнәрен сайлап, Сез язмышыгызны машина төзелеше сәнәгатен үстерүгә багышлагансыз, яшьтән үк шушы юлга басып, һөнәр баскычлары буйлап югарыга күтәрелгәнсез. Белемле яшь инженер буларак, Сез участок мастеры вазыйфасында эшкә тотынгансыз, аннан соң цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы булгансыз. Тәҗрибә туплап һәм тиешле дәрәҗәдә квалификациягә ия булып, эшлеклелек сыйфатларыгыз ярдәмендә автотранспорт предприятиесендә җитәкче булып эшләгәнсез. Сезнең тырышлыклар нәтиҗәсендә Яшел Үзәннең автотранспорт предприятиесе тотрыклы оешмага әверелә, шәһәрне, районны, шәһәрара элемтәләрне транспорт белән өзлексез тәэмин итү системасын җайга сала.

Республика җитәкчелеге перспективалы җитәкчене Яшел Үзән заводының директоры вазыйфасына тәкъдим итә. Сез тукталып бара торган җитештерүне яңадан торгызып, фикердәшләр коллективын туплап, заводны торгынлыктан чыгару стратегиясен кабул итәсез һәм аны яңа биеклеккә күтәрәсез. Компаниянең соңгы егерме елдагы уңышлары турыдан-туры Сезнең исем белән бәйле. Сезне лаеклы рәвештә Россия дәрәҗәсендә уңыш казанган POZIS суыту җиһазлары брендын барлыкка китерүче дип йөртәләр. «Серго исемендәге завод» Җитештерү берләшмәсе» АҖнең генераль директоры вазыйфасында Сез эре көнкүреш техникасын, югары технологияле медицина суыту җиһазларын җитештерү һәм сәнәгать инжинирингы белән шөгыльләнәсез, коллективыгызны яңадан-яңа үрләргә күтәрәсез. Үз көченә ышанган, булдыклы директор буларак, Сез һәрвакытта да яңалыкларга һәм инновацион технологияләр кертүгә әзер, бу исә завод продукциясенең эре көнкүреш техникасы җитештерүчеләр арасында лаеклы урынын яуларга, яңа юнәлешләрне актив үстерергә, җитештерү күләмнәрен арттырырга, чит илләрдәге алдынгы җитештерүчеләр белән көндәшлектә уңышларга ирешергә мөмкинлек бирә.

Югары сыйфатлы экологик яктан чиста продукция җитештерүче һәм район өчен бик күпне эшләүче предприятие буларак, Сезнең яшелүзәнлеләрнең тормышын яхшыртуга, эш урыннары булдырып, перспективалар ачуга керткән саллы өлешегезне дә билгеләп үтәм. Яхшы күңелле кеше буларак, Сез һәрвакыт иҗтимагый һәм хәйрия чараларында катнашасыз, мохтаҗларга ярдәм итәсез.

Хөрмәтле Радик Шәүкәтович! Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм һәм җаваплы хезмәтегездә уңышлар телим! Һәр көн изге хәбәрләр генә китерсен, ә якыннарыгыз уңышлары белән сөендерсен! Үзегезгә һәм якыннарыгызга иминлек, яхшы кәеф, бәхет һәм ныклы сәламәтлек телим!

Реклама
Фото «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖнән алынды

Заводлар эшләп торганда, ил яшәячәк

Лев Уваров, «Сигнал» АҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Радик Шәүкәтович!

Предприятиебез хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән Сезне шушы истәлекле көнегез белән ихлас күңелдән тәбрик итәм!

Юбилей көнендә Сезнең хөрмәткә яңгыраган барлык җылы теләкләргә кушылам һәм Сезнең белән бергә эшләгән эшләр өчен рәхмәтемне, кешелеклелек сыйфатларыгызга карата тирән ихтирамымны белдерәм. Хезмәт биографиягез – ил һәм республика мәнфәгатьләренә хезмәт итү, эш сөючәнлек һәм максатчанлык, күпьеллык тәҗрибә һәм булдыклылык үрнәге. Ростех дәүләт корпорациясенең «Техмаш» фәнни-җитештерү концерны составына керүче «Серго исемендәге завод» Җитештерү берләшмәсе» АҖнең генераль директоры сыйфатында Сез җитештерү күләмнәрен арттыру һәм гражданнар өчен кирәкле булган төрледән-төрле – төп өлеше бөтен Россиягә танылган көнкүреш суыту техникасы булган – продукция эшләп чыгару буенча бурычларны уңышлы үтәп барасыз.

Сез предприятие белән менә инде 20 елдан артык җитәкчелек итәсез. Шушы вакыт эчендә POZIS бренды Татарстан сәнәгатенең сыйфат һәм уңыш символына әверелде. Сезнең тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә бүгенге көндә предприятие илебезнең машина төзү комплексында әйдәп баручыларның берсе булып тора. Компания җитештергән продукциягә Европада да, Азиядә дә ихтыяҗ булуы очраклы түгел. Предприятиенең соңгы биш елдагы эшчәнлегенең уңышлы нәтиҗәләре Сезнең тарафтан кулланылган стратегиянең дөреслеген раслый. Еллар дәвамында машина төзү тармагында тир түгеп куйган хезмәтегезне бәяләп бирелгән күпсанлы югары дәрәҗәдәге титуллар һәм бүләкләр Сезнең казанышлар турында сөйли – ТРның атказанган машина төзүчесе (2000 ел), РФнең мактаулы автотранспортчысы (1995 ел), Россиянең иң яхшы менеджеры (2002 ел), Яшел Үзән районының мактаулы гражданины (2005 ел), РФнең мактаулы машина төзүчесе (2005 ел) һ.б.

Сезне лаеклы рәвештә төбәктәге иң компетентлы җитәкче, киң күңелле һәм югары әхлаклы шәхес дип йөртәләр. Бизнесның социаль җаваплылыгын аңлап, Сез мохтаҗларга ярдәм итүне үзегезнең бурычыгыз дип саныйсыз, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы халкына һәрдаим булышлык итеп торасыз. Сезнең җитәкчелек итү стилегә үз-үзенә ышанганлык һәм кабул итә торган карарларның тизлеге кебек сыйфатлар хас, Сез гадел, принципларга тугры, ватанпәрвәр һәм тормышка аек акыл белән карыйсыз. Үзе артыннан иярта ала торган шәхес булуыгыз һәм оештыру сәләте нәтиҗәсендә, Сез коллективны яңа һөнәри казанышларга, нәтиҗәле итеп эшләргә һәм шәхси үсешкә рухландырасыз.

Чиләбенең 75 елдан артык илнең оборонага сәләтлелегенә өлеш керткән эре химия-машина төзү тармагы предприятиесе җитәкчесе буларак, мин Сезнең югары һөнәри осталыгыгызны, эшлеклелегегезне һәм уңышлы хезмәттәшлеккә, теләсә кайсы мәсьәләне хәл итүдә нәтиҗәләргә йөз тоткан командагызның ышанычлылыгын билгеләп үтәм. Сезнең белән таныш булуыма шатмын, Сезнең шәхси сыйфатларыгызны югары бәялим һәм алга таба да партнерлык элемтәләребезнең дәвам итүенә ышанам.

Хөрмәтле Радик Шәүкәтович! Бүгенге күркәм бәйрәмегез көнендә Сезгә җаваплы вазыйфагызда уңышлар телим, барлык уй-ниятләрегез тормышка ашсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга күтәренке кәеф, уңышлар, ныклы сәламәтлек юлдаш булсын! Юбилеегыз белән!

Фото «Сигнал» Акционерлык җәмгыятеннән алынды

Реклама



КАРАКИТӘ: ҖИРДӘМЕ, МАРСТАМЫ?

«Көндез карап китә, кичен алып китә...» Чүпрәле районы Каракитә авылында, уенын-чынын бергә кушып, шулай дип сөйләшәләр. Кем карап китә, нәрсәне урлыйлар? Әлеге авылга баргач, шушы һәм башка кызык та, кызганыч та хәлләр турында ишеттек.

КАРАКИТӘ

Автор:
Руфия Фазылова



Фото: Лилиана Валитова

«КИЛЕР БЕР ЗАМАН, КЕШЕЛӘР ГАЛӘМГӘ ОЧАРЛАР...»

Каракитә авыл җирлеге Марс дип атала, урта мәктәп тә шул исемне йөртә. Моның сәбәбе берәр кеше исеме белән бәйледер дип уйлаган идек, ялгышканбыз икән. Моның тарихы тагын да тирәндәрәк ята. Атаклы нәселнең дәвамчысы, РСФСРның мәгариф отличнигы Мансур Рәимов бу хакта менә нәрсәләр сөйләде:

– Гата бабам Каракитәнең бик абруйлы кешесе була. 1915 елда Грозныйга барып, нефть чыгаруда катнаша ул. Гражданнар сугышы башлангач, кире туган ягына кайта. Тирә-якның укымышлы кешеләреннән санала, динне, дөньяви фәннәрне дә яхшы белә. Коръән Хафиз исемен йөртә. Гражданнар сугышыннан соң Гата бабай Каракитәдә мәктәп ача. Үзе директор була. Ул вакытта ук табигать, күк җисемнәре белән кызыксынган мөгаллим, укучыларга да шуны өйрәтә. Балаларга мәктәптә астрономия укыта. Хәтта укучыларны кичен дә үзе янына җыеп, галәм серләренә өйрәтә. «Бу җиргә иң якын планеталар: әнә анда кызыл янып тора торганы – Марс планетасы, әнә анда – Венера... Килер бер заман, кешеләр галәмгә очарлар. Сез ул чорны күрерсез, дип уйлыйм, тик мин булмамын», – ди. Авыл балалары чын-чынлап галәм белән җенләнә башлый. Моны аңлаган Гата бабам, мәктәпкә Марс исемен бирә. Һәм авыл җирлеге идарәсен дә Марс исеменә үзгәртәләр. Шулай итеп йөз елдан бирле безнең авыл белән Марс планетасы «идарә итә».

Кызганыч, Гата бабайны 1937 елда репрессияләләр. 1941 елның кышында аның исемен аклыйлар. Ләкин ул исемен аклаучы указның чыкканын көтеп җиткерә алмый, ун көн алда лагерьда вафат була. Шулай да бабамның гаиләсе җиңел сулап куя: балалары халык дошманының дәвамчылары исемен йөртүдән туктый. Әти, сөенеп, сугышка китә.... – дип сүзен дәвам итә Мансур Рәимов.

Марс авыл җирлегенә 3 авыл: Түбән һәм Югары Каракитә, Татар Бизнәсе керә. Хәер, «3 авыл» дию бик үк дөрес булмас – Түбән Каракитә белән Югары Каракитә гомергә икесе бер авыл булып йөргән, аларны бары бер юл гына аерып тора. Ике очта булганга күрә, халык аны югарыга, түбәнгә бүлгән. Шуңа күрә аны хәзер күбрәк Каракитә дип кенә йөриләр.

Атаклы нәсел дәвамчылары – Рәимовлар гаиләсе

– Көзен тагын күбрәк җиләк утыртырга уйлыйбыз, – ди Илмаз Ильясов.

ШАХТЕРЛЫКТАН – БАКЧАЧЫЛЫККА

Каракитәдә 450 хуҗалык бар, 700 гә якын кеше яши. Урта мәктәп сакланган, быелгы уку елын йөздән артык бала тәмамлаган. Ә менә балалар бакчасында нәниләр саны аз – унбишкә дә тулмый. Ни кызганыч, кайчандыр 1 100 йортлы Каракитәдә бүген хуҗалык саны бермә-бер азайган, халык саны исә өч-дүрт тапкырга кимегән.

– 90 нчы еллар башында авылдан күпләп кеше китте, – дип сөйләде Марс авыл җирлеге башлыгы Рафыйк Җамалетдинов. – Һәм ул бүгенгәчә дәвам итә. Узган ел бер пар өйләнеште, алары да авылда калмады. Әле ярый урта яшьтәге кешеләр күп, бүген авылны яшәтүчеләр – шулар.

Озак еллар Каракитәдә бер күренеш күзәтелгән – армиядә хезмәт итеп кайткан егетләр, җыелышып, Воркута шәһәренә – шахтага эшкә киткәннәр. Унунбиш еллап эшләгәч, кире туган якларына әйләнеп кайтканнар. Бүген Каракитәдә Воркутадан кайткан шундый иллеләп гаилә бар. (Аларны «яшь пенсионерлар» дип йөриләр. Авыр эштә булганга, ирләр 45 яшьтә пенсиягә чыккан). Элеккеге шахтерларның йортлары төзек, тормышлары түгәрәк. Шундыйларның берсе – Ильясовлар. Гаилә башлыгы Илмаз акча эшләү нияте белән Воркутага 1988 елда киткән булган.

– Без Каракитәдән берьюлы сигез егет эшкә чыгып киттек, – диде Илмаз абый. – Ике ел эшләгәннән соң, монда кайтып өйләндем. Хатыным Сәкинәне дә алып, янәдән Воркутага киттек. Шахтада эшләгәндә бик күңелле яшәдек. Безнең авылдан гына да дистәләгән яшь гаилә шунда яши иде.

Чит җирдә ун ел эшләгәннән соң, 1998 елда Ильясовлар туган якларына әйләнеп кайта. Яңа йорт җиткерәләр. Аннан тагын ике балалары туа. Бүген олылары Казанда яши, ә кече улары Ирек, үзләре янында, Марс урта мәктәбендә укый.

Узган ел ир белән хатын кызык өчен генә җиләк үстерә башлаган. Уңыш әйбәт булгач, сатканнар да. Аннан көзен җиләк мәйданын арттырганнар. Нәтиҗәдә, быел җиләк тагын да күбрәк.

Без килгәндә хуҗабикә өйдә түгел иде. Сәкинә апа Каракитә балалар бакчасында эшли икән. Бакчалары белән Илмаз абый таныштырды.

– Җиләкне Сәкинәнең әнисе гомер буе үстерә, – диде ул. – Тик сату өчен түгел. Узган ел кызык өчен генә җиләкне бәрәңге бакчасына да утырттык. Уңыш әйбәт булгач, килосын 150 сумнан саттык. Быел исә килосын 200 сумнан куйдык. Күрәсең, авылда сүз таралган, сораучылар күп, җиткереп булмый.

– Алайса җиләкнең мәйданын тагын да арттырырга кирәк инде, – дим.

– Әйе, андый план бар. Көзен тагын күбрәк утыртырга уйлыйбыз. Рәтен белгәч, әллә ни авырлыгы юк.

– Ә «рәте» нинди?

– Көзен яңа үсентеләрне кисәсең, кышка салам белән каплап калдырасың – бөтен сере шул. Без ашлама сипмибез. Яшь үсенте болай да әйбәт уңыш бирә, җиләкләр эре була.

«АЙГА 210 МЕҢ КРЕДИТ ТҮЛӘДЕМ»

Каракитәдә бер эре фермер бар – Шәүкәт Аймәтов. Азу ярган фермер дип тә әйтергә кирәктер. 2012 елда КФХ булып теркәлгән ул. Сиксән биш баш мөгезле эре терлекнең 45е савым сыерлары икән. Сиксән гектар җире бар, аның күп өлеше авылдашларыннан арендага алынган.

Фермер безгә ихаталарын күрсәтте: кайчандыр колхоз фермасы булган иске бинаны төзекләндереп чыккан. Бүген монда пөхтәлек. Савылган сөт туптуры ике тонна сыйдырышлы зур савытка, махсус суыткычка килә икән. Көн саен иртән машина килеп, сөтне алып китә, ди.

– Сыер савучыгыз, малларны караучыгыз бардыр? – дим фермерга.

– Сыерны хатыным сава, малларны карашырга бер кешебез бар. Ул да сезон вакытында гына килә. Җәен хайваннар көтүдә бит.

Фермер әле печәннең беренче катын урнаштырып бетермәгән. Без барганда, басуда трактор чабылган үләнне әйләндереп йөри иде. Шәүкәт абый 2013 елда дәүләт биргән грант акчасына «Беларусь» тракторы алган. Тракторда күршесе эшли икән. Тагын бер комбайны бар. Урып-җыю вакытында читтән дә кеше чакыра.

– Быел печән әйбәт, сөенәсездер, – дим Шәүкәт абыйга.

– Сөенәсең дә, көенәсең дә. Менә бу печәнне чапканга ике атна инде, әле һаман җыеп алып булмый, көне юк. Ул читтән караганда гына рәхәт: үзеңә эшләүнең җаваплылыгы бик зур. Әле малың авырый, әле техникаң ватыла, яки суыткыч эштән чыга. Шуңа өстәп һава торышы да килеп кушыла. Сөйли китсәң, күп инде...

Шулай да Каракитә фермеры хәзер җиңелрәк сулый башлаган, ниһаять, кредитлардан котылган. Эш башлаганда, аңа әле бер, әле икенче кредит алырга туры килгән.

– Банкларга аена 210 мең сум акча түләгән вакытлар бар иде, – диде Шәүкәт абый. – Сауган сөт белән генә бурычларны каплап бетереп булмады, мал да суйдым, туганнардан, дуслардан әҗәткә дә акча алып тордым.

Тик, ничек авыр булса да, фермер артка чигенмәгән. Бүген ул үз-үзенә хуҗа, ике улына ярдәм итәргә дә мөмкинлеге бар. Дөрес, уллары да хуҗалык эшләрендә аңа нык булыша икән.

Бу очракта тагын бер нәрсә кызык тоелды – Шәүкәт Аймәтов та заманында Воркутада эшләп кайткан кеше. Гаиләсе белән бергә күченеп кайткач та, үзенә шөгыль эзли башлаган. Ә авыл җирендә нишлисең? Күмер чыгарып булмый бит.

– Без гаиләдә сигез малай идек, кечкенәдән эшләп үстек, – диде әңгәмәдәшем. – Шуңа да белгән эш, дип, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә уйладым. Авырлыклар күп күрсәм дә, бу юлдан киткәнемә үкенмим. Исәнлектә, шушы булган тормышыбызның ямен күреп яшәргә язса иде, дип телим...

– Авырлыклар күп күрсәм дә, бу юлдан киткәнемә үкенмим, – ди фермер Шәүкәт Айматов.

Әниле-кызлы матурлык тудыручылар.

ӘНИ СУКМАГЫ

Авыл җирлеге башлыгы: «Хәзер мин сезне бер урамга алып барам, шаккатырсыз», – диде. Шәйдуллиннар йортына юл тотабыз икән. Узган елда район буенча алар иң ямьле бакча булып танылган. Махсус бүләк тә алганнар.

Шәйдуллиннар йортына килеп туктагач, чынлап та шаккаттык. Капка төбеннән генә түгел, урамга кадәр чәчәкләр утыртылган. Яхшылабрак карасам, күрше йортка илтүче сукмакка күзем төште. Сукмакның ике як-ягына чәчәкләр утыртылган, хәтта җиләкләр дә пешеп утыра.

– Күршедә кем яши соң? Ике йорт шулай дус яшиме әллә? – дим Рафыйк Җамалетдиновка.

– Хуҗабикәнең әнисе...

– Әнигә илтүче сукмак! Кара, ничек гүзәл! Хикмәт бит бу! – дим.

– Әйе, без дә сокланабыз.

Ул да булмады, балкып хуҗабикә үзе чыгып җитте. Фәридә Шәйдуллина тормыш иптәше Камил белән 2004 елда Воркута шәһәреннән күченеп кайтканнар.

– Бу урын буш иде, – диде Фәридә апа. – Әнигә якынрак булырбыз, дип, биредә йорт салырга ниятләдек. Воркутадан кире туган якка әйләнеп кайтканда миңа – 42, иремә 43 яшь иде.

– Бу чәчәкле сукмакны кем ясады? – дим.

– Дөресен генә әйткәндә, эшнең башында әни тора. Биш ел элек җир астындагы су торбаларын алмаштырдылар. «Урамны бозалар инде», – дип, әни бик борчылды. Аллаһның рәхмәте, су кертүче егетләр туфракны матурлап кына өеп калдырды. Әни алар белән уртак тел тапты, чәйләр дә эчерде. Су кертүче егетләр китеп, берничә көн үткәч, карасам, әни үзенең йорт каршысын матурлап куйган. Һәм, ике яктан түтәл ясап, безгә таба килеп бара. «Әнисе уңган, кызы булмаган», – дип әйтерләр дип, мин дә көрәк күтәреп чыктым. Минем артан Камил дә чыкты. Түтәл булгач, чәчәк тә утырттык. Шулай итеп сукмак елдан-ел чәчәккә күмелде. Узган ел хәтта җиләкләр дә утырттык.

Безне күреп, «чәчәкләр патшабикәсе» Нурхания апа да чыкты. Әбекәй тиздән 81 яшен тутыра. Биш кыз үстергән. Бүген ялгызы яши икән. Гомер иткән тормыш иптәше сигез ел элек мәрхүм булган.

– Кияү алдында оят та, – ди, Нурхания апа. – Ашаталар, мунча кертәләр. Үземне бер дә ялгыз тоймыйм. Балалардан күргән игелекне сөйләп бетерә торган түгел. Алланың рәхмәтләре булсын... (Нурхания апа күз яшьләрен сөртте. – Авт.)

– Элек тә чәчәкләр утырта идегезме? – дим.

– Яшь чагында аның белән утырырга бик җай тимәде. Ә менә олыгая башлагач, гел шулар белән яши башладым. Иртә яздан тәрәзә төбемә орлыклар утыртам, аннары күчерәм. Шулар белән сөйләшеп йөрим. Матур булгач, рәхәт бит.

...Каракитә төрле фикер тудырды: килгәч тә, аның зурлыгына шаккаттык, аннан ташландык йортларның шактый булуына игътибар иттек. Йортлар болын арасындагы кебек утыра. Моның сәбәбен аннан соң гына аңладык – авыл чыннан да бик зур булган. «Бүген монда кимендә 500 йорт салырлык урын бар», – диде авыл җирлеге башлыгы. Йортлар сүтелгән, урыны-урыны белән әрәмәлекләр барлыкка килгән. Бу кадәр җирне карап, тәртипләп бетерүе бик авыр, монысы аңлашыла. Биредә юллар каралган, шунысы сөенечле. Ә иң кыйммәтлесе – халык бердәм, ачык. Әнә узган елны мәчетне яңартканнар. Авыл уртасына ял мәйданы ясарга планлаштыралар. Бер генә теләк – Марс исемен йөрткән авылның күгендә гел якты кояш булсын...

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН:

Мансур Рәимов, РСФСРның мәгариф отличнигы:

– Авыл атамасының килеп чыгышына бәйле берничә вариант бар. Василий Магницкийның «Список селений мишарей в Буинском уезде Симбирской губернии» исемле хезмәтендә: «Кара катта, чуашча «хура катта» – кара агачлык, дип, чуаш теленә бәйләп аңлата. Чынлап та, башка чыганаклар да элек биредә чуашлар яшәгән дип күрсәтә. Авыл исеме шуннан калырга бик мөмкин.

Икенче вариант – «Каракитә, көндез карап китә, кичен урлап китә» дигән әйтем безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Россиянең атказанган укытучысы, Марс урта мәктәбенә илле ел гомерен биргән атаклы укытучыбыз Зәки Азизов болай дип әйтә иде: «Каракитә Ульяновск, Чувашия белән чиктәш. Якындагы рус авыллары, рус алпавытлары бай булганнар. Алар янына Шәкүр карак та килеп йөргән. Шул исәптән атаклы карак безнең авылга да кергән. Аның монда әшнәдәшләре дә булган. Моны тирә-як авылларда да белгәннәр. «Ишекне бикләдеңме, Каракитә караклары килер», – дип әйтә торган булганнар.

Аерым чыганаклардан күренгәнчә, Каракитәгә безнең бабаларыбыз XVI гасырда килеп урнашкан. Т

– ШУЛАЙ БУЛДЫМЫ?

– **ШУЛАЙ БУЛДЫ!**



Фотограф Рамил Галиевны күптән инде фоторәссам дип атыйлар — мизгелне матур итеп эләктереп алу дигән сүзләр нәкъ менә аның турында. Мондый мизгелләрне ул инде күп еллар «аулый». Фотограф тозагына эләккән килеш алар үз сәгатьләрен көтеп ала да күргәзмәгә эләгә һәм шунда ук күп тамашачының игътибарын җәлеп итәләр. Шундый күргәзмәләрнең берсе «Татмедиа»ның беренче катындагы фотогалереяда ачылды.

...Аклы-каралы сурәтләрдәге үткәннәргә чумып, кемдер ул елларны искә ала, ә кемдер үзе өчен яңалык ача.

— Шулай булдымы?

— Шулай булды!

Шаян йөзләр, шат күзләр, кызыклы, көтелмәгән хәлләр — Рамил Гали кадрларына эләккән һәр нәрсә, һәр мизгел аның ярдәме белән мәңгелеккә кала.

ТАССР

Празднование 100-летия
Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ